Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 8 (1424) 3 март 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

12

Татарстанның атказанган артисты, җырчы Илүсә Хуҗина татар опера сәнгатен Европада таныту теләге белән иҗат итә.

14

Санкт-Петербургта яшәп иҗат итүче милләттәшебез Винера Абдуллина тупланмасында М.Җәлил, И.Шакиров, Г. Баязитов кебек күренекле шәхесләребезнең сыннары бар.

24

Рәссам Аделина Акбирова укучыларын заманча технологияләр, чималлар кулланып рәсем ясарга өйрәтә.



Гүзәлкәйләрне алкышлап, Яз керде күңелләргә!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Бөтендөнья татар конгрессы быел, Татарстан Хөкүмәте һәм Мәдәният министрлыгы белән берлектә, 59 төбәктә һәм 37 чит илдә 388 Сабан туе уздыруны планлаштыра.

- Казан кооператив институтының Дәрдемәнд исемендәге Татар мәдәнияте үзәгендә драматург Туфан Миңнуллин истәлегенә атап уздырылган «Туган телем» конкурсы җиңүчеләрен бүләкләделәр.

- Ульяновск татар мәдәният үзәгендә Казан, Чабаксар, Саранскидан килгән тел белгечләре, галимнәр катнашында ана теле укытучылары форумы узды.

- Төмән өлкәсендә узган Татар мәдәнияте көннәре кысаларында Тубыл шәһәрендә төрки телле халыкларның «Таң йолдызы» һәм «Халык сәнгате» үзешчән сәнгать осталары бәйгесе үтте.

- Яңа Чишмә районы Зирекле авылында 1903-1905 елларда салынган мәчет төзекләндерүдән соң ачылды.

- Роберт Миңнуллин исемендәге фонд Республика балалар китапханәсе белән берлектә «Шигъриятькә сәяхәт» иҗади бәйгесен игълан итте.

- Баулыда Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фәнис Яруллинның тууына 85 ел тулу уңаеннан «Язмышларга буйсынмас җан…» дип аталган хәтер кичәсе булды.

- Беларусь Республикасының Минск шәһәрендә Советлар Союзы Герое Муса Җәлилгә багышланган кичә оештырылды.

- Свердловск өлкәсенең Березовский шәһәрендә «Милли йорт» музее ачылды.

- Язучы, журналист, Башкортстан Язучылар берлеге каршында татар әдипләре секциясен җитәкләгән Рәшит Сабит 85 яшендә вафат булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Нәҗибә САФИНА, шагыйрә:

«Чикләүләрдән дә татарның сәнгатенә, рухи дөньясына, безнең белән бергә башка барлык кечкенә халыкларга да зур зыян киләчәк. Нәрсәдер коелып үлеп калачак, шуның аркасында бик күп авыр югалтулар булачак. Без бик күп төрле бәйгеләрдә катнаша алмаячакбыз. Дөньякүләм аренага татар йөзен чыгару, үзебезне таныту дигән хыял да югала хәзер. Тик чикләүче шушы гамәлләре белән (дәүләт) үзен дә чикләвен аңлап бетерми. Аның да сәнгате башка халыкларныкын юкка чыгару исәбенә ярлыланачак бит».

СЫНАМЫШЛАР

Март башында чыпчык эчәрлек су булса, ел яхшы була ● Март башында тамчы тамса, җәй яхшы килә ● Җил берничә көн рәттән көнбатыштан иссә – яңгырлар башлана ● Һава коры булса – җылыта. ● Яз иртә килсә, ашлык уңар ● Мартта яуган кар – бакча җимешенә бик ярар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 32 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 21 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 49 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **10 мартта 11 сәгать 21 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

3 март – шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Нәҗип Гәрәй улы Мадьяровның тууына 95 ел (1928-2002).

4 март – гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Айрат Сәлимулла улы Шәмсетдиновка 60 яшь (1963).

5 март – драматург һәм театр эшлеклесе Әнәс Галиәсгар улы Камалетдинов тууына 115 ел (1908-1978).

7 март – драматург, тәрҗемәче Зәйни Әхмәт улы Шаһиморатовның (Шаһиморат Зәйни) тууына 110 ел (1913–1980).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 5-7 март.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(27 февраль – 7 март)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 11 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рүзәл ЮСУПОВ, академик

АСЫЛ ЗАТЛАР

Күркәм бәйрәм – Халыкара хатын- кызлар көне җитә. Бу көнне без гүзәл затларыбызга хаклы рәвештә ихтирамыбызны, якты хисләребезне белдерәбез, изге теләкләр телибез. Бу бәйрәмгә әзерлек көннәрендә безгә, аналарыбызны, апа-сеңелләребезне, хатыннарыбызны хөрмәтләү, аларга мәдхия уку белән бер үк вакытта, хатын-кызларның җәмгыятьтәге роле, аларның тормышыбызны имин, ямьле, мәгънәле итүдә, яшәешне уңышлы дәвам иттерүдә ифрат әһәмиятле асыл затлар булуы һәм чын мәгънәсендә цивилизацияле, культуралы тормышка хатын-кыз матур, игелекле һәм мәһабәт булганда гына ирешергә мөмкин икәнлеге турында җитди уйланырга кирәк.

Хатын-кызларыбызның бөеклеген, җәмгыятьтә лаеклы урын тотуын яшь буынның зиһененә сеңдерә бару зарур, ягъни балаларны, яшьләрне тәрбияләү аналар, әбиләр, апа-сеңелләр, хатыннарны иң күркәм затлар итеп күрсәтү җирлегендә булырга тиеш.

Инануымча, ир-атның хатын-кызга тиешле дәрәҗәдә игътибарлы, илтифатлы, мәрхәмәтле булуы җәмгыятьнең югары культуралылыгын күрсәтә.

Әле әйтелгән фикер коры сүз генә булып калмасын өчен, хатын-кызларның табигатьтән бирелгән олы миссиясен һәм гаиләне саклауга, җәмгыятьнең прогрессына керткән зур өлешен, фидакярлеген расларлык кайбер фактларны бәян итү мәгъкуль.

Беренчедән, бала табып үстерүдә, аны лаеклы кеше итеп тәрбияләүдә, гаилә учагын саклауда ананың роле, хезмәте искиткеч зур. Күренекле татар шагыйре Һади Такташ, тәэсирле итеп, «Ана булу – бөек исем» дип, бик дөрес язган. Ана, баласын тапканнан алып аягына бастырганчы, кеше иткәнче, күпме йокысыз төннәр үткәрә, күпме көч түгә, кирәк булганда, үзенең авызыннан өзеп баласын тукландыра, аны, үстереп җиткереп, мөстәкыйль юлга чыгарганчы, нинди генә авырлыклар күрми, борчу-мәшәкатьләр кичерми.

Узган гасырдагы дәһшәтле Ватан сугышы елларында искиткеч фәкыйрьлек, ачлык-ялангачлык шартларында ялгыз калган аналарның дүртәр-бишәр яки аннан да күбрәк баланы үстерү газапларын искә төшергәндә, йөрәкләр сыкрана, күңелләр тула.

Безнең Юсуповларныкы кебек гаиләләр илдә күп меңнәрчә булуын истә тотып, ул чактагы хәлләрне кыскача гына үзебез кичергән вакыйгалар мисалында искәртеп китү урынлы булыр. Әтиебез сугышта, фронтта. Без бер яшьлектән алып ун яшьлеккә кадәр дүрт малай әниебез карамагында. Шундый көннәр була иде: кышын әни, кул чанасына салып, 30 чакырымлы Арчадан колхозга бер капчык чәчүлек орлыгы алып кайтырга чыгып киткән була. Ике абыебыз, мичкә ягу өчен, су буеннан тал чыбыклары җыеп яки басудагы эскертләрдән салам йолкып алып кайту белән мәшгуль. Мин, өч яшьлек малай, бер яшендәге энем белән көннәр буе салкын өйдә ач килеш утырабыз. Ул вакыттагы төп ризыкларыбыз – бәрәңге һәм сепаратордан (аерткаппан соң) чыккан сөт белән пешергән аш, аерткан сөттән оеткан катык. Ипи юк, бер-ике сарыкның налог итеп түләүдән калган итен һәм атланмайны базарда сатып җыйган акча көчләп алдыра торган заем түләүгә, кием-салым алырга китә, ләкин җитми. Әниебез ертык киемнәрне, төннәр буенча утырып, ямап киертә...

Көннәрдән бер көнне әниебезне районга (Әтнәгә) алып киттеләр. Аңа анда хөкем оештырганнар. Баксаң, кесәсенә салып, кайдандыр безгә ашарга бер-ике уч колхоз орлыгын алып кайткан булган икән. Моны күрше абзые күреп, хакимияткә әләкләгән. Без, малайлар, көне буе, әниебезне зарыгып көтеп утырдык. Бәхетебезгә, судья мәрхәмәтле кеше булып чыккан: әтиләре фронтта михнәт чигеп йөргән балаларны кызганып, бер-ике уч орлык өчен ананы төрмәгә утыртырга намусы кушмаган, әнине кайтарып җибәргән.

Бер көнне әни өйгә елап кайтып керде. Үкси-үкси: «И, балалар, атагыз үлгән бит!», – диде. Без дә елашырга керештек... Ярый әле, әтиебез үлмәгән булып чыкты, немецларга һөҗүм итеп барганда, бик нык яраланып, аңын югалтып, яу кырында ятып калган булган. Ялгыш, ул үлгән дип уйлап, безгә аның һәлак булуы турында хәбәр җибәреп өлгергәннәр. Әти, аңына килеп, госпитальдә хәле бераз рәтләнгәч, үзе безгә хат язып салган.

Әти, сугыштан яраланып кайткач та, бер хезмәт көне языла торган җиңел эштә генә йөрде. Ә көзен колхозчыларга ашлыкны, дәүләткә тапшыру планын үтәгәннән соң калса, бер хезмәт көненә 600-700 граммнан гына, уңыш яхшырак булган елны бер килограммнан бирәләр иде: шулай итеп, ел буе эшләгән эшкә түләү 4-5 яки 5-6 капчык арышка тиңләшә иде. Сугыштан соң да әле шактый күп еллар ачлы-туклы яшәдек. Хәтта сабын да юк: көлдән ясалган селте белән юыналар иде. Безнекелэр 50 нче еллар башында, атнасына ике зур чиләк бәрәңге уып, шуңа бераз гына он кушып, ипи сала башладылар. Ул тәмсез, ләкин җан сакларга ярый... Хәзер, уйлаганда, гаҗәпләнәм: җиде кешенең (сугыштан соң гаиләдә бер энебез артты) киемнәрен юып, ертык киемнәрен ямап, юклы-барлы ризыктан ашарга әзерләп, шуның өстенә, колхоз эшендә эшләп, ул әни ничек чыдады икән?! Балаларымны ничек туйдырыйм икән дип, аның йөрәге авыртмагандыр дип кем әйтә алыр!

Сугышка киткән ир-егетләрнең яртысыннан күбрәге әйләнеп кайтмады. Күпме тол хатыннар, кияүгә чыкмый калган кызлар!.. Бөтен авыр эшләр алар җилкәсендә булды.

Безнең яшь-яшь татар кызлары Мәскәү тирәсендәге сазлыклардан кышкы салкыннарда, ачлы-туклы килеш, начар өс киемнәрендә торф чыгарды, зур электр станциясе төзелү сәбәпле су басасы урманнарны кул пычкысы белән кистеләр. Тагын нинди генә авыр эшләр башкарырга туры килмәде аларга! Нәфис, затлы кызлар эшли торган эшләр идеме соң болар? Ул чакларда хатын-кызларыбыз җилкәсенә төшкән газапларны хәзерге яшьләр белми. Әмма алар бу хәлләрне белергә тиеш. Әлеге михнәтләр турында мәктәптә сөйләргә, матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында мәгълүмат бирергә кирәк.

Асыл затларыбызның күбесенең тормышы хәзер дә рәхәт түгел. Балаларын да тәрбияләргә, күп санлы өй эшләрен дә, хезмәт хакы өчен, өйдәгедән тыш вазыйфалар башкарырга да туры килә аларга. Югыйсә, ана кешегә, балаларын тәрбияләп, йорт хуҗалыгын тәртиптә тоту да зур хезмәт. Кешеләрнең матди хәлләре җитешле, алга киткән илләрдә шулай бит, ләбаса. Ә бездә күпчелек гаиләләрдә ирләре эшләгәнгә генә яшәү мөмкин түгел шул.

Димәк, безгә 8 нче март – Халыкара хатын-кызлар көне бәйрәм генә була алмый. Ул, күркәм затларыбызны котлау, аларга матур хисләребезне белдерү датасы булу белән бергә, аларның җәмгыятьтәге зур ролен, казанышларын күрү һәм күрсәтү, шул ук вакытта аларның проблемалары, тормышыбызга ямь бирүче, ирләрне игелекле гамәлләр кылуга дәртләндерүче, көч биреп, ярдәм итеп торучы күркәм затлар булып, бәхетле яшәүләре өчен аларга тиешле шартлар тудыру ихтыяҗы турында фикер алышу, шуңа багышлап планнар кору көне дә булырга тиеш.

Күркәм хатын-кызларыбызның бу зур бәйрәменә әзерләнү һәм бәйрәм итү көннәрендә хөрмәтле татар аналарына, укытучы ханым һәм кызларга ирештерәсе бер бик әһәмиятле мәгълүматны игълан итү зарур. Хәзер туган телебез бетүгә юл тота. Төп сәбәбе – милли мәгарифнең таркатыла баруы. Бу хәл – кайчандыр дәүләтле булган, алдынгы мәдәниятле, югары әхлаклы, тырыш, уңган халыкның цивилизацияле милләт буларак юкка чыгуына китерә торган иң зур хәвеф. Бу хәтәр күренештән котылып калуның бердәнбер юлы, беренчедән, аналарның, барлык чараларны кулланып, балаларына үз – ата-аналарның, әби-бабаларының телен өйрәтү, иң мөһиме –мөмкин булганда укырга татар мәктәпләренә бирү һәм рус мәктәпләрендә укыганнарын андагы татар теле дәресләренә йөртү. Ә инде кайсыдыр уку йортында бу изге эшкә аяк чалучылар, каршы килүчеләр була икән, Россия һәм Татарстан конституцияләренә, башка төрле законнарга таянып, мәгариф органнарыннан, дәүләт җитәкчеләреннән балаларга туган телләрен яхшылап укытуларын таләп итү.

Укытучы һәм мәгариф җитәкчеләре вазыйфаларын башкарган ханымнарга, һәм кызларга мөрәҗәгатебез: татар балаларына һәм яшьләренә туган телләрен өйрәтү өчен, үзегезне аямыйча, көчегезне кызганмыйча, барлык мөмкинлекләрдән файдаланыгыз: укыту-өйрәтүгә татар балаларының барысын да җәлеп итәргә тырышыгыз, ә татар телен өйрәнүнең, белүнең әһәмиятен аңламаган ата-аналарга, туган телнең һәркем өчен иң мөкатдәс нәрсә икәнлеген һәм туган тел бетсә, татар милләтенең дә юкка чыгачагын аңлатыгыз. Бу – хәзер барыбызның да иң мөһим бурычы, изге гамәле. Ата-аналарыбыздан, әби-бабаларыбыздан кадерле мирас булып бирелгән телебез һәм мәдәниятебезне, димәк, милләтебезне дә саклыйк.

Ләкин төшенкелеккә бирелеп, кул кушырып утырырга ярамый. Бөтен көч-куәтебезне биреп, акылыбызны җигеп, үз телебездә иркен аралашып, мәдәниятебезнең игелеген күреп, иркен, имин яшәрлек җәмгыять төзү өчен иҗтиһат итәргә кирәк. Шуңа ирешсәк, алдынгы мәдәниятле дәүләттә күркәм хатын-кызларыбызның бәхетле, матур яшәве өчен мөмкинлекләр җитәрлек булыр.

Уңган, тәрбияле, сөйкемле хатын-кызларыбызны – олысын да, кечесен дә – матур яз бәйрәме – 8 Март көне белән ихлас күңелдән тәбриклик һәм изге теләкләр телик. Алар зур хөрмәткә, мәләем карашка лаеклы.

Мәдәни җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Хакыйкатьтән качып булмый

Хәвефле еллык уңаеннан дөньякүләм дәрәҗәдә үткәрелгән кайбер чаралар турындагы сүзебезне дәвам итик. Ә алар арасында иң саллысы – мөгаен, БМО Генераль Ассамблеясенең (ГА) 22 февральдә Украина буенча эшен яңарткан 11 нче гадәттән тыш махсус сессиясеңдер. Украинадагы хәлләрнең берьеллыгы алдыннан (23 февральдә) анда бу илдә тотрыклы, гадел һәм гомумколачлы тынычлык урнаштыруны максат иткән һәм нигезенә узган ел G20 саммитында Украина президенты В.Зеленский тәкъдим иткән «тынычлык планы» салынган резолюция кабул ителгән. Дөньяның 141 иле бу документны яклап тавыш биргән. Каршылар – 7 ил (Россия, Беларусь, КХДР, Мали, Никарагуа, Сүрия һәм Эритрея), ә 32 ил тавыш бирүдән тыелып калган. Соңгылары арасында – Кытай, Һиндстан, Иран, Эфиопия, Вьетнам, Пакьстан, Куба кебек илләр, шулай ук БДБ илләренең дә бер өлеше (Әрмәнстан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан). Ә резолюцияне яклап тавыш биргәннәр арасында Сербия, Венгрия һәм Молдова да бар. Документның эчтәлегенә килгәндә, анда ГА Украинаның бердәмлеген яклавы турында әйтелә; БМО әгъзаларына һәм халыкара оешмаларга исә Украинада БМО Уставы нигезендә гомумколачлы, гадел һәм тотрыклы тынычлыкка ирешү юлында дипломатик тырышлыкка ярдәмне икеләтә арттырырга тәкъдим ителә. Әлеге резолюциядә БМО принципларына һәм халыкара хокук нормаларына нигезләнгән таләпләр Россиягә карата да куела.

Хактыр ки, соңгы вакытларда Россия мәгълүмат чараларында ГА резолюцияләре киң яктыртылмый. Нигәдер аларны рәсми сәясәт кысаларында шәрехләү һәм үтәү өчен мәҗбүри булмауларын искәртү белән генә чикләнәләр. Әйе, БМО КШ резолюцияләреннән аермалы буларак, ГА резолюцияләре юридик яктан үтәү өчен мәҗбүри түгел. Юкса, резолюцияләрне БМО ГА сессиясендә кабул иткәндә, һәр ил үзе өчен үзе тавыш бирә, димәк, кабул ителгән документ та дөнья халыклары ихтыярын һәм хакыйкатьне тулырак чагылдыра булып чыга. БМО КШ утырышында исә резолюция 15 әгъза (5 есе – даими, 10 ысы – вакытлы әгъзалар) тарафыннан гына кабул ителә. Ә даими әгъзалар (АКШ, Бөекбритания, Кытай, Россия һәм Франция, алар һәммәсе дә атомтөш коралына ия) әле вето хокукына да ия (ягъни алар, үз ихтыяҗларыннан чыгып, теләсә нинди карар яки резолюцияне кабул иттермичә кала ала). Шулай итеп, БМО нигезенә хокук көче түгел, ә көч хокукы салынган булып чыга. Мондый хәл БМОны көчлеләр кулында дөнья тотучылар файдасына эшли торган сәясәт механизмы итә һәм геосәясәттәге бүгенге кризисны өлешчә шуның да нәтиҗәсе дип карарга кирәктер.

Хәлбуки, БМО Куркынычсызлык Шурасын реформалау – зур сәясәттә инде өлгергән проблема. Тәкъдимнәр дә гел булып тора. Әйтик, Европа Шурасы башлыгы Шарль Мишель БМО КШ да әгъзалыкны туктатып тору механизмы булдыру тәкъдиме белән әле декабрьдә үк чыккан иде. Ә февральдә инде, Россияне халыкара хокук нормаларын бозуда гаепләп, аны халыкара оешмаларда (БМО КШны да кертеп) изоляцияләү тәкъдимен Европа парламенты күтәрде. Әмма БМО ГА рәисе Чаба Кёрёши, РФ халкына һәм лидерларга мөрәҗәгать итеп, Россия милләтләр берлегенең мөһим әгъзасы булып кала, дип белдерде. Мәгәр, Россиядә ГА резолюциясенең әһәмиятен төшереп күрсәтү тенденциясе дә яши. Имеш, АКШ күп илләргә басым ясап тавыш бирдергән, дигән ялган да – шундыйлардан. Әйе, 5-6 илгә ничектер басым ясап буладыр да әле. Әмма 140 илгә карата моны инде берничек тә эшләп булмый. Чөнки һәр ил – үз иркендә (әйтик, 13 ил соңгы тавыш бирүдә бөтенләй дә катнашмаган). Димәк, ГА резолюциясе чынбарлыкны тулырак һәм реаль чагылдыра булып чыга. Хәер, моны Мәскәүдә дә аңлыйлар кебек. Тик, караны – ак, акны кара итеп күрсәтергә омтылу анда әлегәчә яши.

Соңгысы җәһәтеннән гыйбрәтле мисалны хәтта БМО КШ утырышы дәрәҗәсендә дә китерергә була. Әйтик, Россиянең БМО дагы даими вәкиле В.Небензя, гадәттәгечә, язганын кәгазьдән аерылмыйча укып чыкканнан соң, чыгыш өчен чират оппонентларына җиткәч, беренче урынбасары Д.Полянский белән залдан чыгып китте. Мондый хәлләр элегрәк тә булгалады. Миңа калса, хикмәт монда әлеге затларның БМО КШ утырышын һәм башкаларны хөрмәт итмәвендә генә дә түгел. Әмма хакыйкатьтән алай гына качып булмый шул. Мәгәр, мәсьәләнең әле икенче ягы да бар: Җирдә дөреслек юк икән, димәк, яңа дөньяви тәртип урнаштыру турында сүз дә була алмый.

Фоат УРАЗАЙ.

Парламентта җылы очрашу

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республика парламентында танылган казах драматургы Мөхтәр Ауэзовның улы дипломат, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе Мурат Ауэзов белән очрашты.

Мурат Ауэзов җитәкчелегендәге, составында иҗат интеллигенциясе, фәнни һәм эксперт җәмгыяте вәкилләре булган Казахстан делегациясе Татарстанга фәнни-гамәли конференциядә катнашу һәм казах язучысы һәм драматургы Мөхтар Ауэзов әсәрләре җыентыгын тәкъдим итү өчен килде.

Очрашуны ачып, Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан белән Казахстан арасында тыгыз дустанә элемтәләр, шул исәптән гуманитар элемтәләр дә урнашуына басым ясады. Парламент җитәкчесе милләтара тынычлыкны һәм татулыкны саклау мәсьәләләренә аерым тукталды. Күпмилләтле республикада Татарстан халыклары ассамблеясе эшчәнлеген оештыру үз нәтиҗәләрен бирде. Казахларның милли-мәдәни автономиясе Ассамблея эшчәнлегендә актив катнаша, ә бу иҗтимагый оешманың беренче рәисе, Фәрит Мөхәммәтшин искә төшергәнчә, Казахстан автономиясе җитәкчесе Сәгыйть Җаксыбаев булган.

«Мин һәр вакыйгага лаеклы бәя бирергә тырышам, ләкин бу очракта мин шат һәм бәхетле, – дип басым ясады Мурат Ауэзов, әңгәмәдә яңа китапны тәкъдим итүне шәрехләп, – бу вакыйга һәрберебезнең субъектив дөньясына караганда күпкә киңрәк. Ул казахларны да, татарларны да берләштерүче уртак әйбер. Без барыбыз да зур трансформацияләрнең яңа тарихи чорына кердек, һәм монда бер-беребезнең, тарихи яктан якын булган халыкларның үзара тәҗрибәсе бик мөһим. Безнең тарихи тамырлар ким дигәндә 2,5 мең еллар исәпләнә. Сезнең республика тәҗрибәсе Казахстан кебек яшь бәйсез дәүләт өчен бик кирәк».

Парламентта узган очрашуда шулай ук республиканың мәдәният министры Ирада Әюпова, Татарстан халыклары дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов, Казахстанның Казандагы Генераль консулы Ерлан Искаков катнашты.

Шагыйрь бәйрәме

Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында күренекле шагыйрь, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Мөхәммәт Мирзаның (Илфак Ибраһимовның) 70 яшьлегенә багышланган «Мәңгелек юлында» исемле әдәби-музыкаль кичә узды.

Иң башта ук маэстро Р.Абязов җитәкчелегендәге La Primavera оркестры һәм Казан музыка көллиятенең татар хоры, М.Мирза сүзләренә композитор Р.Мөхетдинова иҗат иткән «Идел-йорт» кантатасын башкарып, кичәнең югары сәнгати рухын билгеләп куйды. Юбилярны Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, республикабызның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла тәбрикләде. Һәр икесенең әйтер сүзләре күп җыелган иде, чөнки шагыйрь М.Мирза Мәдәният министрлыгында урынбасар, Язучылар берлеге җитәкчесе һәм каләм осталарыбызның төп журналы «Казан утлары»ның мөхәррире булып хезмәт итте.

Казан Федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы Нурфия Юсупова үзенең чыгышында юбиляр шагыйрьнең иҗатында жанр төрлелеген билгеләп үтте. Шәрык әдәбияты традицияләрендә иҗат ителгән робагый, газәлләрнең тәрбияви әһәмиятенә, поэмаларындагы милләт язмышы өчен әрнүенә игътибар юнәлтте. М.Мирзаны башка шагыйрьләрдән аерып торган кыска язу осталыгы турында әйткәндә биш юллыклардан торган чичәннәр стилендә иҗат ителгән, нечкә ирония, киная, афоризм булырдай гыйбарәләргә бай «Адәм баласы» шигырьләр шәлкемен мисал итеп китерде. Мөхәммәт Мирза шигырьләренә иҗат ителгән җырларны кичәдә күренекле җырчыларыбыз Г.Мурзиева, И.Хужина, С.Кыямова, А.Ганиев, А.Кәримова, Л.Муллагалиева, Л.Хөсәенова башкарды. Г.Камал театрыннан И.Хәйруллин һәм Ф.Мөхәммәтҗанов юбиляр шагыйрьнең якташы

бөек артист Мохтар Мутинга багышланган «Мохтар. XX гасыр трагедиясе» поэмасын укыганда, канлы дәвер куркыныч булып тамашачы күзалдында яңарды.

М. Мирза татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен актив пропагандалаучы, яшьләрне иҗатка тартучы күренекле шәхес буларак та күпләргә билгеле. Ул Актаныш районында «Агыйдел дулкыннары» исемле әдәби иҗат берләшмәсен җанландырып җибәрә, аның җитәкчесе була. Бераз соңрак Татарстан китап нәшрияты әлеге берләшмә әгъзалары әсәрләреннән төзелгән «Агыйдел дулкыннары» исемле күләмле җыентык бастырып чыгара. Юбилей кичендә М.Мирзаның шәкертләрен яшь каләм әһелләрен сәхнә түрендә күрү нур өстенә нур булды.

Талантлы якташларын тәбрикләргә Актаныш районы башлыгы Л.Зарипов, Казандагы Актаныш якташлар җәмгыяте рәисе В.Вахитов та килгән иде. Аларның һәр әйткән сүзендә шагыйрьнең иҗатына соклану, районның данын үстергән гаилә белән горурлану сизелә иде. Әтисе Мирза абый Бөек Ватан сугышында ике аягын өздереп кайткач та, ясалма аякларда егерме ел мәктәп директоры булып эшли. Әнисе унбер бала тәрбияләп үстерә. Юбилярның бертуганы Фаил Ибраһимов Минзәләдә баш режиссер булып эшли, Чаллыда театр оештыра, шул рәвешле татар театры үсешенә зур өлеш кертте.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Кирәкле белгечлек

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында 2023-2024 уку елыннан «Татмедиа» белән берлектә «Нәшрият эше. Мәгълүмати тирәлек дизайны» программасын булдырырга ниятлиләр.

«Күптән түгел Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда булдык, аның белән дә әлеге темага сөйләштек. Шунысы куанычлы: әлеге белгечлеккә федераль бюджеттан урыннар бүлеп бирелмәде, ләкин республика хөкүмәте бу белгечлекне актуаль дип таныды. Рөстәм Нургали улы 20 бюджет урыны бирү турында карар кабул итте» – диде институт директоры Рәдиф Җамалетдинов.

Аның әйтүенчә, студентлар график дизайн, иллюстрация һәм анимация, график бренд-коммуникация, газета-журнал версткасы, китап басмасы, полиграфия продукциясе һәм тышкы реклама өлкәсендә югары квалификацияле билингваль белгечләр булачак.

1 нче биттә – КФУның «Бәйрәм» вокаль-инструменталь ансамбле җырчысы Сәрия Мәрданова рәссам Р. Сәлахов күргәзмәсенең ачылыш тантанасында чыгыш ясый. Р.Гали фотосы, «Татар-информ».

Каһарманнарга һәйкәл

Казан югары танк команда училищесы территориясендә Россия Геройлары – училищены тәмамлаучылар бюстлары ачылды. Тантанада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Училище Геройлары аллеясында барлыгы 11 яңа бюст барлыкка килде: генерал-майор М.М.Шәйморатов, генерал-майор Р.А.Шадрин, өлкән лейтенант И. Н.Ахпашев, өлкән лейтенант В.Н.Горин, майор С.В. Кустов, кече лейтенант К.В. Ситкин, майор Т.О.Мусалаев, өлкән лейтенант М.И. Михайлов, өлкән лейтенант И.Л.Насыйбуллин, өлкән лейтенант Д.Э.Шәймәрданов, майор С.А.Панов.

Генерал Шәйморатов Казанга «килде»

Милли китапханәдә генерал Миңлегали Шәйморатовка кагылышлы документларның күчермәләре тәкъдим ителде. Экспозицияне Татарстан Милли архивы үзләрендә сакланган документ күчермәләре буенча эшләгән. Киләчәктә бу күргәзмә киңрәк итеп эшләнергә мөмкин.

Күргәзмә Радик Кудояровның башкорт дивизиясенең легендар командирына багышланган «Генерал» документаль фильмын күрсәтү өчен махсус ясалган иде. Фильмны Казан көллиятләреннән килгән студентлар карады.

«Бу документлар республикада беренче мәртәбә күрсәтелә. Безгә аларның күчермәләрен фильмның режиссеры Радик Кудояров тапшырды», – диде Милли архив директоры урынбасары Людмила Кузнецова. – Игътибар итсәгез, документларда «рассекречено» дигән гриф тора. Бу шактый сирәк очрый торган хәл. Документларны шәхси заттан алуыбыз да игътибарга лаек. Ул аларны үзе эзләгән, тапкан – зур эш башкарган».

Л.Кузнецова 2020 елда шушы документлар нәтиҗәсендә легендар Шәйморатовка үлгәннән соң Россия Федерациясе герое исеме бирелгәнлеген искәртте. Документларда аның Казанда укыганлыгын искәрткән, татар икәнлеге билгеләнгән язулар да бар.

«Бүген төп максат – кино күрсәтү. Гадәттә китапханәдә барган чаралар вакытында вакытлы күргәзмәләр куела, бу да шундый. Архив белән документларның оригиналларын китертү буенча сөйләшәсебез килә, ул теләкне җиткердек», – дип, Милли китапханә директоры урынбасары Тәбрис Яруллин күргәзмәнең кыска вакытлы булуын аңлатты.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

«Китап» – төньяк башкалада

«Китап» радиосы Санкт-Петербург шәһәренең «Пулковец» яшьләр үзәгендә «Питер-Казан арасы» дип исемләнгән яңа проектын милләттәшләребезгә квартирник форматында тәкъдим итте.

«Әлеге проект бер ай эчендә Санкт-Петербургның «Мирас» яшьләр үзәге белән әзерләнде. Квартирник форматында үткәрүебез исә тамашачы белән бер сулышта булып, якынрак аралашасы килүдән. «Китап» радиосында даими рәвештә яңгырап торган даһи шагыйрьләребезнең шигырьләре белән бербәттән татар халык моңнары да, мәгънәле җырларыбыз да башкарылды», – диде әлеге проектның идея авторы, «Китап» милли радиосының тапшырулар мөхәррире, шагыйрә Гөлинә Шәйхи.

Санкт-Петербургта тамашачы бик җылы кабул итте, ди мөхәррир. «Китап» радиосын кушымта аша еш тыңлыйлар икән. Хәтта нинди әсәрләр укыганыбызга кадәр беләләр. Анысы аеруча сөендерде. Иң олы тамашачыбызга 87 яшь иде. Яныбызга килеп безгә рәхмәт әйтте. Зал Әбри Хәбриевны да, Зәринә Хәсәншинаны да зал алкышлап туймады. Махсус кунак итеп Ярамир Низаметдиновны чакырганны белгәч, ул апаларның ничек сөенгәнен күрсәгез икән сез!» – дип, Гөлинә Шәйхи Питердан алган тәэсирләре белән уртаклашты.

Күптән көтелгән китап

Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре XIX гасырда Татарстанның көнчыгышында яшәгән кайбер татарларның башкорт сословиесендә булу үзенчәлеген аңлатты.



«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә «Көнбатыш Урал буе татарлары. Минзәлә өязе» китабы тәкъдим ителде. Тарих институты Минзәлә өязе буенча 1795-1859 еллардагы җанисәп материалларын китап итеп чыгарган.

«Китапта бирелгән материаллар архив чыганакларына нигезләнә. Басмада Минзәлә өязенә кергән дүрт йөздән артык татар авылы буенча мәгълүмат бирелә. Китап нәсел шәҗәрәсен тикшерүчеләр, авыллар тарихын язучылар өчен төп чыганак була ала», – диде Тарих институты директоры урынбасары М. Гыйбатдинов.

Минзәлә өязенә Татарстанның бүгенге Минзәлә, Түбән Кама, Тукай, Зәй, Мөслим, Сарман, өлешчә Актаныш, Әлмәт һ.б. районнар кергән.

«Китапта күрсәтелгән сылтамалар ярдәмендә кызыксындырган авыллар буенча архивтан тулырак мәгълүмат табарга мөмкин. Җанисәп материалларының оригиналлары Уфа архивында саклана. «Башархив» сайтында аларны бушлай күчереп алу мөмкинлеге булдырылган. Безнең китап ярдәмендә архивтан кирәкле документларны эзләү җиңелрәк булачак», – диде Тарих институтының Идел буе һәм Урал буе тарихы бүлеге мөдире Радик Исхаков.

Китапта күренгәнчә, халыкның иң зур өлеше ясаклы татарлар сословиесенә кергән. Сан буенча икенче урында башкорт һәм өченче урында бобыль сословиеләре тора. Тарихчылар аңлатканча, биредә сүз фәкать сословие турында бара. Монда милләтнең катнашы юк.

«Китапның кереш өлешендә без сословие милләт төшенчәсен бутарга ярамаганын тәфсилләп аңлаттык. XIX гасырда җанисәп халыктан салым җыю ниятеннән оештырыла. Дәүләткә кешенең милләтен ачыклауга караганда, сословиесен белү мөһимрәк була, чөнки салым күләме сословиегә бәйле була», – диде Р. Исхаков.

Тарихчы сүзләренчә, кешеләр бер сословиедән икенчесенә күчә алган. Төрле елларда үткәрелгән җанисәп нәтиҗәләре моны ачык дәлилли.

«Бер үк авыл кешеләре беренче ревизияләрдә (искәрмә – җанисәптә) ясаклы татарлар дип язылган. Бераздан алар типтәр булган, ә соңгы ревизияләрдә башкорт сословиесенә кергән. Монда бер үк кешеләр турында сүз бара», – диде Радик Исхаков.

Кешеләр бер төбәктән икенчесенә күченеп киткән очракта да аларның сословиесе үзгәргән. «Мәсәлән, Казан төбәгеннән Уфага күчкән кешеләр, татар, чуваш, удмурт милләтеннән булуларына карамастан, башкорт сословиесенә кергән. Уфадан башка төбәккә күчкән кеше закон буенча башка сословиегә күчә торган булган», – диде М.Гыйбатдинов.

Әлегә «Көнбатыш Урал буе татарлары. Минзәлә өязе» китабы 100 данә белән бастырылган. Киләчәктә яңа тиражлар көтелә. Директор урынбасары, китапка ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен, барлыгы өч мең данә кирәклеген әйтте. Әлегә аның электрон вариантын Тарих институты сайтыннан йөкләп алырга мөмкин.

Рифат КАЮМОВ.

● Дәүләттәге демократия дәрәҗәсе буенча Economist Intelligence Unit журналы төзегән рейтингта Россия 167 ил арасында 146нчы урынга куелган – 2022 ел эчендә ул 22 урынга аскарак төшерелгән. Иң демократик илләр – Норвегия, Яңа Зеландия һәм Исландия. Исемлектә иң азакта исә КХДР, Мьянма һәм Әфганстан килә.

● РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясе әзерләгән исемлектән күренгәнчә, Россиягә 97 төрле медицина препараты, шул исәптән ибупрофен, парацетамол, аспирин, каптоприл, нитроглицерин, активлаштырылган күмер, водород перекисе һәм йод кытлыгы яный икән. Соңгы өчесе XX гасырның беренче яртысындагы иң гади технологияләр буенча эшләнә, моның өчен бернинди суперзаводлар да кирәк түгел бит инде югыйсә. Өлкән сыйныф укучылары химия түгәрәгендә ясый ала үзләрен. Ә Россия, мәсәлән, 2020 елда 51 мең тонна водород перекисен (барлык экспортның 85 процентын) Финляндиядән керткән, калган өлешен Швейцария һәм Бельгиядән кайтарткан.



XX йөз башында һәм Советлар берлегенең башлангыч чорында иҗат иткән һәм татар әдәбиятының күренекле әдипләре һәм галимнәре Гали Чокрый, Мәҗит Гафури, Галимҗан Шәрәф, Гали Рәхимгә багышланган китаплар шушы көннәрдә укучылар кулына килеп ирешә.

● *Әлфәт Закирҗанов, Разил Вәлиев, Айгөл Ганиева, Нуридә Насыйбуллина.*

Рухи мирас байый

Шушы уңайдан Татарстан Фәннәр академиясендә «Милли яңарышка юл күрсәтүчеләр» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы узды. Китаплар берьюлы тәкъдим ителсә дә, алар ике сериядә басылып чыккан. Гали Чокрый (төзүчесе – И.Гомәров) һәм Мәҗит Гафурига (төзүчеләре – А.Ганиева, А.Хасавнех) багышланган җыентыклар «Шәхесләребез» сериясендә «Җыен» фонды тарафыннан әзерләнеп дөнья күрсә, Гали Рәхим (төзүчеләре – Л.Гарипова, Г.Ханнанова) һәм Галимҗан Шәрәф (төзүче һәм текстларны әзерләүчеләр – Э.Галимҗанова, Г.Зәйниева, Ф.Фәйзуллина, Г.Хөснетдинова) иҗатын барлаган басмалар Тел, әдәбият һәм сәнгать инитутының «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» проектын дәвам итә. Хезмәтләрнең уртак ягы: алар институтның кульязмалар һәм музыкаль мирас үзәгендә саклаган, җәмәгатьчелеккә әлегә кадәр мәгълүм булмаган кульязма материалларга, документларга нигезләнеп әзерләнгән.

Татар мәдәнияте һәм әдәбияты XX йөзнең беренче яртысында,аеруча 20-30 елларда гаять катлаулы каршылыклы үсеш кичерә. Бу чорда әдәбиятка һәм сәнгатькә, журналистикага талантлы яшьләр күпләп килә. Алар арасында Гали Рәхим һәм Галимҗан Шәрәф тә бар, икесе дә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Бай гаиләдә туып-үскән Г.Рәхим Мәскәү сәүдә институтын тәмамлый, Г.Шәрәф исә Петербург тимер юл инженерлар институтында өч ел гына булса да укып кала, революция булгач, белем алуы туктала. Алар икесе дә шактый еллар Шәрык педагогика институтында укыта. Г.Рәхим язучы, әдәбият галиме булып танылса, Г.Шәрәфне тел галиме, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче буларак беләбез. «Фаҗигале язмышлы шәхесләрнең үз чорында иҗатлары зур яңгыраш ала, алар бүген дә әһәмиятен җуймаган. Аларның мирасын ачу, яңа кыйммәтләрне җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү зур әһәмияткә ия. Моннан тыш Г.Рәхим белән Г.Шәрәфнең иҗаты 1920 елларның кырыслыгын, кешелексезлеген ачарга ярдәм итә», – диде Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов. Төрле өлкәдә халкыбызга хезмәт куйган бу шәхесләр коточкыч репрессиягә дучар була. Озак еллар төрмә камералары аша үтеп, сәламәтлекләрен югалтып кайталар һәм бик яшьли бакыйлыкка күчәләр. Г.Рәхимгә – 51, Г.Шәрәфкә 54 яшь була. Г.Рәхимнең китапта тәкъдим ителгән мәкаләләре аның искиткеч тирән фикерле, киң колачлы шәхес булганлыгын тагын бер тапкыр исбатлый. «Г.Рәхим, драма әсәрләре белән танылганнан соң, әдәби тәнкыйтькә, әдәбият фәненә килә. 1920 нче еллар башында тарихчы Газиз Гобәйдуллин белән берлектә «Татар әдәбияты тарихыннан материаллар» җыентыгын әзерли. Ул татар әдәбиятын яңача өйрәнү концепциясенә нигез салучыларның берсе булып танылa. Без бүген дә аның хезмәтләренә мөрәҗәгать итәбез», – диде китапка кереш мәкалә авторы Гөлназ Хөснетдинова.

Тел галиме, сәясәтче Г.Шәрәф – «Идел-Урал» штатын төзү омтылышы белән йөргән кешеләрнең берсе. «Бертуган Шәрәфләрнең мирасын кайтару мәсьәләсе тарихи-мәдәни мәйданда күптәннән актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бәлки киләсе елга бертуган Шәрәфләрнең «Җыен» нәшриятында тагын бер китабын эшләргә мөмкинлек булыр. Гомумән алганда, архивларда, кульязмаларда саклаган, әлегә кадәр билгесез материалларны туплап, шәхесләрне яңадан мәйданга чыгару, татарларның милли үзаңын ныгытучы бер фактор буларак күрсәтү ул зур әһәмияткә ия», – дип ачыклап үтте әдәбият галиме, Татарстан Фәннәр Академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина.

Китапларны укыганда, бөтенләй үзгә, без әлегә кадәр белгәннән күпкә аерылып торган Мәҗит Гафури, Гали Рәхим, Гали Чокрый, Галимҗан Шәрәф белән танышабыз. Җыентыклар әлеге әдипләрнең бүгенге мәдәни кырда яшәгән иҗат портретларын, аларга карашны үзгәртә.

Галимә мисалга Мәҗит Гафурины китерде. Без аның «Юктырсың ла, Алла, әгәр булсаң...» шигырен өйрәнеп үскән буын. Әмма китаптагы М.Гафури – бөтенләй башка шәхес. «Ул динне, исламны тирәнтен белүче, үзенең милләтенә хезмәт итеп әдәбиятка килгән милләтпәрвәр, гаять зур шагыйрь буларак ачыла», – диде Д.Заһидуллина. Галимә – китапның фәнни мөхәррире буларак язылган кереш сүз авторы да. Ул анда язучының иҗатына тирән анализ бирү белән бергә әдипне милләте буенча тарткалау мәсьәләсенә дә кагылып үтә. «М.Гафури иң билгеле шәхесләр рәтендә булса да, аның иҗатына карата берьяклы карашның да җуелып беткәне юк. Шиксез, совет чорының милли сәясәтендә М.Гафурины, милләтен күрсәтми генә, башкорт әдәбиятының классигы дип бәяләү иҗатка ниндидер саграк мөнәсәбәт китереп чыгара, – дип яза галимә. – 1924 елда гына үз рәсми язуын булдырган тугандаш халыкның әдәбият тарихын тудыру омтылышларына аңлап карау үз өлешен керткәндер: М.Гафуригa «татар-башкорт әдәбиятлары классигы» дигән бәя урнаша. Монда хилафлык юк. Хилафлык – аның шигырьләрен башкорт теленә әйләндереп тә, татарчадан күчерелгәнен күрсәтмәүдә, шагыйрьнең милләтен телгә алмауда, аның эшчәнлеген башкорт җәмәгать эшлеклеләре, зыялылары белән аралашуга басым ясап шәрехләүдә, инде килеп – бернинди нигезсез аны башкорт милләтенең улы итеп күрсәтергә омтылышларда». Мәҗит Гафури турындагы китапның фәнни мөхәррире Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлегенә өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Айгөл Ганиева М.Гафуриның беренчеләрдән булып милли темаларны күтәрүен искә алды, үзен татар милләтенә багышлаган шагыйрь буларак танытуын искәртте. Аннан соң миллият мәсьәләләрен Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев кебек шәхесләр югарырак үсешкә җиткерә. А.Ганиева шулай ук мирасханәдә М.Гафуриның кульязмалары саклануын билгеләрдә. Аларны язучының улы әтисенең васыяте белән алып килеп тапшырган.

«Гали Чокрыйга багышланган хезмәттә аны татар суфыйчылыгының яңа бер моделен төзегән, шуны башкарган һәм туктаусыз дингә, белем-мәгърифәткә хезмәт итеп, суфичылык идеяләрен үзе яшәгән яңа бер юнәлештә үстерә алган шәхес һәм зур язучы, шагыйрь буларак күрәбез. Төзүче тарафыннан басмага Г.Чокрыйның шигъри әсәрләре тулысынча әзерләнеп кертелсә, язучының фәнни-публицистик хезмәтләре бик аз өлеше генә тәкъдим ителгән. «Г.Чокрый буенча әле өченче, дүртенче китапларыбыз дөнья күрер, «Милли-мәдәни мирас» сериясеннән тагын бер хезмәт планлаштырабыз, бәлки аны киләсе елга ук тәкъдим итәрбез», – диде Д.Заһидуллина.

Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирасы үзәге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров Г.Чокрый тормышы һәм иҗаты белән таныштырды. Ул Г.Чокрыйның тулы исеме – Мөхәммәтгали Габдессалих улы Киеков булуын, әдәби тәхәллүсе туган авылы Иске Чокыр авылына нисбәтле алынуын искәртте. Татар-башкорт мәдәниятләре өчен шактый күп эш башкарган һәм әдәбиятлары үсешенә үзеннән зур өлеш керткән шагыйрь, үз чорының дини рухание, XIX гасырның күренекле мәгърифәтчесе. Аның татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында үз урыны бар.

«Г.Чокрый тумышы белән шактый күренекле нәсел вәкиле. Аның ата-бабалары нәсел-нәсәбенең башы Чыңгыз ханның гаскәр җитәкчеләреннән саналган Майкы би (Байкы би) дигән шәхескә барып тоташа. Ул бер әсәрендә үзеннән алып шушы Майкы бигә хәтле нәсел шәҗәрәсен китерә. Анда 20гә якын буын искә алынган», – ди И.Гомәров. Тарихи мәгълүматлар буенча Майкы би гаскәре Җучи белән берлектә Урал таулары аша Идел буйларына кадәр барып җитә, бүгенге Мөслим, Минзәлә якларына кадәр килеп урнаша. «Г.Чокрыйның иҗаты тулысынча татар телендә. Бүген без башкортныкы дип белгән телдә бер генә җөмләсе дә юк. Аерым бер башкорт белгечләре «татар телендә язган» дигән сүзне кулланмас өчен «хикмәтле» аңлатмаларга бара: татар телендә түгел, Идел буе төрки телендә язган, диләр. Шул ук вакытта «Идел буе төрки теле урта гасырлар яки XIX йөз әдәби татар теленнән кайсы ягы белән аерылып тора соң?» дигән сорауга беркемнең дә аңлаешлы җавап биргәнен әле очратканыбыз юк», – диде галим.

Гали Чокрый татар сүз сәнгате тарихында мул иҗатлы әдип санала. Аның барлык язганнарын туплаганда, берничә томлык китап хасил булыр иде.

Өч дистә еллар тирәсе элек оешкан, бернинди финансларга ия булмаган «Җыен» фонды башта «Таиф», соңрак «Татнефть» ярдәме белән бинһая олуг хезмәтне алып баруын да билгеләп үтәргә кирәктер. Хәзер инде фонд чыгарган китаплар 90 нан артып киткән. «Җыен» фондының элгәре еллардагы эшчәнлеге Миркасыйм Госманов, соңрак Туфан Миңнуллин исемнәре белән бәйле булса, хәзер исә мирасыбызны халыкка кайтару эшен фонд директоры Фоат Рәфыйков, Татарстан халык язучысы, фонд рәисе Разил Вәлиев алып бара.

Утырышта Башкортстаннан «Мәҗит Гафури – XXI гасыр» мәдәният фонды советы рәисе, язучының кече оныгы Халит Гафуриның җәмәгате Люция Камаева да катнашты. Ул җыенга фондлары чыгарган күп кенә китапларны да алып килгән иде. Люция ханым Р. Вәлиевкә М.Гафури медален тапшырды. Ул – фонд советы карары нигезендә бирелә торган иҗтимагый бүләк.

Сөембикә КАШАПОВА.

АЗНАКАЙДАГЫ ӘГЕРҖЕ

(Дәвамы. Башы 7 нче санда).

Авылның мөәзине – Габдерәүф Габдрахманов (50 яшь). Хатыны (51) һәм буй җиткән 3 улы белән яши. 3 эш аты, 2 колын асрый. Ике иманасында һәм арендага алган басуларында чәчүлекләре 7 дисәтинәдән арта. Хуҗалыкта барлык эшләрне үз көче белән башкара.

Әлеге дин әһелләре, башка авыллардагы кебек, балалар укыту белән дә шөгыльләнгәннәрме, билгесез. Ә менә Фәхриҗамал Галләмова (50 яшь) ел саен 6 ай буе балаларга сабак биргән. Хезмәте өчен ата-аналар түләгән. Мөгаллимә улы һәм 2 кызы белән яши. 2 имана җире, берничә баш малы була.

Авылда күптәннән 2 лавка эшләп килүе мәгълүм. Беренче лавканың хуҗасы – Гыймадетдин Галиуллин (42 яшь). Ул вак-төяк товарлар белән сәүдә итә. Моннан башка, су тегермәне дә була. Гаиләсе анасы (80 яшь), хатыны (40 яшь), 3 улы һәм кызыннан тора. Гыймадетдин бай күп терлек тота (4 эш аты, 3 сыер, 15 сарык һ.б. вак маллар) һәм зур мәйданда (20 дисәтинәдән артык) иген игә. 2 имана җире була, калган басуларны авылдашларыннан һәм читтән арендага алган. Хуҗалыктагы эшләрне, башлыча, хезмәтче башкара.

Икенче лавка – Мөхәммәтгали Мөхәммәтгәрәевнеке (40 яшь). Монысында да вак-төяк товарлар сатыла. Хуҗа хатыны (35 яшь), 3 улы һәм 2 кызы белән яши. Аның да мал-мөлкәте күп. 4 эш аты, 2 сыеры, 15 сарыгы, башка вак маллары була. 4 имана җирендә һәм арендага алган басуларында чәчүлекләре 28 дисәтинә тәшкил итә. Ул гадәттә кыска срокка гына, башлыча, җәй айларында эшче яллый.

Әгерҗедә Гыймадетдин белән Мөхәммәтгали байлар кебек күп эре мал асраган хуҗалыклар дистәгә якын. Тәхаутдин Сәйфетдиновның (аңа 75 яшь) дүртәр эш аты һәм сыеры, Садретдин Баһаутдиновның (35) 4 эш аты һәм 3 сыеры була. Мәһди Вәлиев (53), Баһаутдин Габидуллин (45), Баһман Галимов (28), Габделгалим Габделганиев (55), Мөхәммәтҗан Мөхәммәдиев (57), Хөснулла Нигъмәтуллиннарның (62) эш атлары – өчәр. Алар урта хәлләләрдән санала.

Җан башына бүленә торган җирнең күләме аз булу сәбәпле, Әгерҗедә урта хәлле хуҗалыклар күп түгел. Алар, иманалары күпме булуга карамастан, арендага җир алган. Соңрак кайберләре кулак хуҗалыкларына әверелә.

Әмма авылда күпчелекне очын-очка көчкә ялгап баручы хуҗалыклар тәшкил итә. Аларның мал-туары да, чәчүлекләре дә аз була. Тора-бара бер ишесе бөлгенлеккә төшә: иманасын арендага биреп, көнлекчелеккә йөри яисә ел буена батраклыктан кайтып керми.

Батраклар исемлегенә Вәлиулла Гайфуллин (63 яшь), Гафур Кәримов (45 яшь), Сәйфулла Ваһаповны (60 яшь) һәм тагын берничә хуҗалыкны кертергә мөмкин. Исемнәре аталганнар ел буена дворян Ильин имениесендә бил бөгә. Аңа һәм төбәкнең башка эре җир биләүчеләренә (Рязанов, Головинская) көнлекчелеккә йөрүчеләр тагын да күбрәк була.

1897 елгы корылык Әгерҗедәге күп кенә хуҗалыкларның хәлен тәмам начарайта. Шаһи Вәлиев (45 яшь) һәм Хәлим Ханнановлар (35 яшь) 1898 елда барлык мал-мөлкәтләрен сатып, читкә чыгып китәргә мәҗбүр була. Сәфәргали Корбангалиевнең (63 яшь) дә улы авылны ташлап китә, Чиләбегә барып эшкә керә.

Билгеләп үткәнчә, игенчелек һәм терлекчелек – авыл халкының төп шөгыле. Шул ук вакытта һөнәрчелек тә зур урын тота. Беренче чиратта, агач эше осталары. Алар арасында балта осталары (Хәлиулла Хәйбуллин, Госман Хәмидуллин, Шәрәфетдин Әхмәтшин) һәм тәгәрмәч ясаучылар (Әхмәди Вәлиев) була. Габделкәрим Гыйззәтуллин пыялачы буларак билгеле.

Әгерҗенең тегү эше осталары да була. Кием-салым тектерергә Шәрип Биктимеровка (68 яшь) яисә Шаһиәхмәт Әхмәтҗановның улына йөргәннәр. Соңгысы тегү машинасы сатып алгач, Азнакайда ширкәт оештыра һәм компаньоны белән күпләп тегә башлый.

Итекчеләр авылда икәү – Мөхәммәтсадыйк Шәрипов һәм Шәрәфетдин Садыйков, яшьтәшләр (40 яшь). Садыйк Кәримов (50 яшь), Мөхәммәтшакир Мөхәммәтҗанов (50 яшь) һәм соңгысының улы чабата үрә, Сәпәй базарына да илтеп сата.

Төбәктә сирәк очрый торган һөнәр иясе – кирпеч сугучы (Хөснетдин Хисаметдинов) була. Кирпеч күбесенчә мич чыгару өчен кулланылган.

Шулай итеп, Әгерҗедә авыл тормышы өчен кирәкле һөнәр төрләренең күпчелеге була. Югарыда телгә алынган кешеләрнең төп өлеше өчен һөнәрчелек өстәмә табыш чыганагы булып тора. Ә менә чәчүлексез хуҗалыкларда ул – яшәү чыганагы.

Авылда умартачылар күп түгел, берничә кеше генә – Шәйдулла Миңлеголов, Ибраһим Мөхәммәтҗанов, Нәбиулла Гыйззәтуллин, Миргариф Габделгалләмов һәм Садретдин Баһаутдинов. Соңгысының, башкалар белән чагыштырганда, умарталыгы зуррак (12 баш).

Кайбер хуҗалыклар кыш җитү белән чаналарын җигеп байларга һәм сәүдәгәрләргә икмәк ташырга ялланган. Мәсәлән, Вилдан Мотыйгуллин (31 яшь) сәүдәгәрләрнең йөген өязнең Сок Карамалысы авылына ташыган. Җәйләрен җидешәр көн Рязанов һәм Ильин имениеләрендә көнлекчелектә үткәргән.

1900 елда Әгерҗедә 174 хуҗалык исәпләнә. Аларның җидесе читтән күчеп килгән, бише – татар, икесе – рус. Русларның берсе – Никон Бобров – Бөгелмәдән килеп урнаша, авыл тегермәнен арендага ала. Монда 23 яшьлек улы белән чиратлашып эшли, көнлекчелеккә дә йөриләр.

Сугыш алды елларында Әгерҗедә байтак кына үзгәрешләр була. Шуларның берсе – авылның ике мәхәлләгә бүленүе. 302 ир-ат һәм 280 хатын-кыздан торган беренче мәхәлләдә мулла булып Хикмәтулла Нигъмәтуллин кала. Ул 1861 елның 12 июнендә туган, 1896 елның 4 апрелендә муллалыкка расланган. 1912 елның кышында Хикмәтулла мулла вафат була, аның урынына Шәрәфетдин Габделгалимовны куялар. Бу мәхәлләдәге җәмигъ мәчет бинасы 1791 елда төзелгән була.

Икенче мәхәллә 1905-1906 елларда, яңа мәчет салынган чорда барлыкка килә. Монда 184 ир-ат, 186 хатын-кыз исәпләнә. Имам-хатыйп итеп Фәхретдин Садретдин улы Ярмәков билгеләнә. 1879 елның 15 мартында туган, 1906 елның 15 маеннан әлеге вазыйфаны үти башлый. Шул ук елның 29 маенда мөәзин итеп 25 яшьлек Гайса Баһаветдиновны куялар. Берара Нурмөхәммәт Нургалиев та мөәзинлек итә.

1910 елда Әгерҗедә 194 хуҗалык, 504 ир-ат һәм 493 хатын-кыз исәпләнә. Авылның 1446 дисәтинә уңайлы, 52 дисәтинә уңайлы булмаган җирләре була. Икешәр мәчет, мәктәп һәм су тегермәне эшләгән.

Сугыш башланды дигән хәбәр тиз арада таралып, бөтен авыл халкын хафага сала. Озак та үтми, беренче мобилизацияләнүчеләр дә билгеле була. 1914 елда авыл күп кенә ир-егетләрен сугышка озата. Татарстан дәүләт архивында сакланучы документка таянып, аларның исемлеген китерәбез.

Әлеге исемлек 1915 елның 13 февралендә төзелгән. Аннан күренгәнчә, дәһшәтле сугыш җиле авылда күп кенә хуҗалыкларга кагыла. Берәүләрнең гаилә башлыклары – ирләре, калганнарның уллары мобилизациягә эләгә. Ирләре сугышка алынган хуҗалыкларда төп авырлык хатын-кызларга (алар исемлектә кыз чактагы фамилияләре белән күрсәтелә) төшә.

Беренче бөтендөнья сугышына алынган Әгерҗе ирләре (1914 ел)

№	Мобилизацияләнүчеләр	Хуҗалык башында калучылар
1	Гыйльман Игътисамов	Сорур Габитова (хатыны)
2	Шәрәф Шәяхмәтов	Шәмсеруй Әбүбәкерова
3	Хәйретдин Ихсанов	Ихсан Игътисамов (атасы)
4	Шәмсулла Хәлиуллин	Хәлиулла Хәбибуллин (атасы)
5	Мөхәммәтгали Мәһдиев	Мәлиха Хәмидуллина (хат.)
6	Әхмәтҗан Мәһдиев	Шаһидә Мөхәммәтсадыйкова
7	Шәкүр Шакиров	Кафия Фәхретдинова (хат.)
8	Хәбибулла Габделгафуров	Габделгафур Кәримов (ат.)
9	Мөхибрахман Габдрахманов	Мәхтүмә Габдрахманова
10	Әшрәфетдин Бикколов	Биккол Биктимеров (ат.)
11	Динмөхәммәт Бикмөхәммәтов	Бәдигылҗамал Шәмсиева
12	Гайнемөхәммәт Ильясов	Гайнижамал Ситдыйкова (хат)
13	Мөхәммәтгалим Мөхәммәтлатыйпов	Һәдия Хәйруллина
14	Нургали Ибраһимов	Фатыйма Гыйлажетдинова
15	Габделислам Габделгалимов	Шәмсенур Вәлиуллина
16	Мөхәммәтвәли Әхмәтов	Әхмәт Корбангалиев (ат.)
17	Хәбир Фәйзрахманов	Фәйзрахман Хәбибрахманов (ат.)
18	Вафиулла Рәхмәтуллин	Мәбрүрә Шәнгәрәева (ан.)
19	Габделхәким Корбангалиев	Зарифа Габделҗаббарова (хат.)
20	Шәйхулла Хөснуллин	Зәкия Хисаметдинова (хат.)
21	Сабир Әбүбәкеров	Мөгаллифә Галимова (хат.)
22	Зиннур Әбүбәкеров	Зөбәйдә Мөхәммәтвәлиева (хат.)
23	Сәлахетдин Шәрәфетдинов	Шәрәфетдин Садыйков (ат.)
24	Әхмәтҗан Зәйнуллин	Гыйльмиҗамал Шәрифуллина (хат.)
25	Латыйфулла Хәйруллин	Хәйрулла Вәлиев (ат.)
26	Нуретдин Шәйхетдинов	Ш. Игътисамова (ан.)
27	Нурмөхәммәт Нургалиев	Нургали Муллагалиев (ат.)
28	Шаһидулла Зәйнуллин	Шәмсеҗамал Шәрәфетдинова (хат.)
29	Габдерәкыйп Габдерәүфов	Габдерәүф Габдрахманов (ат.)
30	Хәбибулла Шаһидуллин	Шәйдулла Миңлеголов (ат.)
31	Зыятдин Фәхретдинов	Мәстүрә Шәрәфетдинова (хат.)
32	Гыйльфан Вилданов	Вилдан Гашимов (ат.)
33	Габделвәли Габделгалимов	Габделгалим Габделганиев (ат.)
34	Хәбир Кадыйров	Мәрҗәм Җәләлетдинова (хат.)
35	Газизҗан Әхмәров	Әхмәр Гайнуллин (ат.)
36	Җиһангир Фазуллин	Шәмсекамал Шаһимәрдәнова (хат.)
37	Әхмәтҗан Әхмәдиев	Миңлеҗамал Сәлимгәрәева (хат.)
38	Сәетгәрәй Асылгәрев	Асылгәрәй Мөхәммәдиев (ат.)
39	Мостафа Мөхәммәтҗанов	Шәмсенур Гәрәйшина (хат.)
40	Гомәр Хәмидуллин	Мөкәррәмә Шәрипова (хат.)
41	Миргалим Галләмов	Сорур Ногманова (хат.)
42	Нургасим (Мөхтәсим) Галләмов	Фәрхизадә Әхмәтсафина (хат.)
43	Фәхразый Фәхретдинов	Фәхретдин Гайнетдинов (ат.)
44	Сәлимгәрәй Ибраһимов	Шәмсениса Ибраһимова (?)
45	Нәбиулла Галиәскәров	Әсхәпҗамал Фәхрелисламова (хат.)
46	Бәдретдин Тәхаутдинов	Сабира Әхмәтшина (хат.)
47	Сәлимгәрәй Әхмәтшин	Сабира Гатауллина
48	Харис Галиуллин	Фатиха Гобәйдуллина (ан.)
49	Мөхәммәтсафа Мөхәммәтгалиев	Мөхәммәтгали Гәрәев (ат.)
50	Солтангәрәй Шәрәфетдинов	Шәрәфетдин Ситдыйков (ат.)
51	Мөхәммәтзакир Рәхимҗанов	Фәрхисорур Гобәйдуллина

(Дәвамы 19 нчы биттә).

Таһир КӘРИМОВ, тарих фәннәре кандидаты.

ФАСЫЛЛАР

1
Кыш белән яз әле бил алыша,
Алга чаба гомер атлары.
Кар астында гөрләвекләр шавы,
И язларның шушы чаклары!

Апрель кояшының җылысыннан
Эреп бетә кышын яуган кар.
Түбәдәге боз-сөңгедән тамган
Тамчыларда яшәү суты бар.

Ишетелә ерак-ераклардан
Сөенечле кошлар тавышы.
Сагышларын ташлап калдырганнар,
Сау кайтаргач илгә язмышы.

Яшь үләннәр майда борын төртә,
Болын чәчәкләре бөредә.
Яшел келәм өсләренә басып
Чык тамчысын җыеп йөре дә,
Шушы язның бөтен матурлыгын
Ничек инде күзең күрмәсен?!
Кояш белән бергә җитәкләшеп
Җәй аена атлап керәсең.

2
Июнь ае... дөнья шау чәчәктә.
Кошлар сайрый көнен, төнен дә.
Куанышып бала чыгаралар,
Оя корып туган җирендә.

Җиләк пешә, сусыл тәлгәшләре
Ымсындырып дәшә үзенә.
Дөньялыкның бөтен яме сыйган
Утлап йөргән колын күзенә.

Дулкын-дулкын бодай, арыш кыры,
Тургай күктә таган атына.
Ай-йолдызлар гашыйкларны күзли,
Эңгер төшеп кояш батуга.

Июльдә ут каба сулышыңа,
Чиллә җитә... кызу эш өсте.
Коенып чык, әйдә, чум инешкә,
Суы яңа сауган сөт төсле.

Август киче... алма агачыннан
Җиргә тып-тып алма коела.
Коянтәсен асып, ай юлыннан
Зөһрә суга килә коега.

3
Чуар күлмәк кигән сентябрьдә
Җилләр җиләс, төннәр салкынча.
Бәгырьләргә сагыш иңә күктән,
Үткән еллар җанда чаң суга.

Елга өсте шадраланып тора,
Суларның да төсе үзгәргән.
Таллар боек, боздай тамчы тама,
Күксел болыт, моңсу күзләрдән.

Октябрьнең кулы сыпырып алган
Яфракларны җилләр тарата.
Торналар һәм киек казлар моңы
Яңгырый күк һәрбер тарафта.

Оча кошлар, тезелешеп оча,
Саубуллашып китеп баралар.
Моңсу тавышлардан төсен җуеп,
Күкселләнеп кала һавалар.

Кырлар шәрәләнгән. Урманнар да
Кайгы күргән кебек каралган.
Кара сулар, көзге сулар ага,
Кырпак бозлар сырган ярлардан.

Кара көзнең күзе тома сукыр,
Кышлар әле килеп җитмәгән.
Карлар явар, өмет саклап йөртер:
«Яшәләсе гомер бетмәгән!»

4
Декабрьдә суык битне чеметер,
Бураннары юлга кар өяр.
Бар дөньяны аклык-сафлык сарыр,
Кар бабайга җиһан баш ияр.

Ак кичләрдә гомер йомгагының
Очын алып җитез кулына,
Бишинәгә элеп, әниләре
Йон оекбаш бәйләр улына.

Йә кызына, яки оныгына
Бәйләү серен ачар, өйрәтер.
Картлар, тезен чүгеп, мич алдында
Акрын гына махра көйрәтер.

Дөнья тыныч, илләр имин булса
Шулай дәвам итәр фасыллар.
Яшәр өчен туган һәр кешенең
Язы, җәе, көзе, кышы бар.

Үзгәрмәсен тормыш кануннары,
Яз да, җәй дә, көз һәм кыш булсын.
Җир күчәре читкә тайпылмасын,
Нурын сирпеп яңа көн тусын.

Гөлчәчәкләр керфек каксын язда,
Ямьле җәйдә пешсен җиләкләр.
Көз мул уңыш белән куандырсын,
Ак кышта да типсен йөрәкләр.

Әлфия СИТДЫЙКОВА

Ил авырган чакта без авырдык, Ил терелгән чакта без терелдек...

Еракларда мин дә орлык чәчтем.
Шытып, чәчәк атты гөлләрем.
Хәтерләтеп гүзәл яшьлектәге
Болыннарны гизгән көннәрем.

Тирәнәйде инде маңгайдагы
Еллар эзен салган буразнам.
Кичерегез мине, җир гөлләре!
Сагыш булып сезгә уралсам.

ЙӨРӘК ТАВЫШЫ

Любовь преображает нрав
любящего по образу любимого.
Франческо Петрарка

Тумыштан ук минем язмышыма
Язылгандыр чиксез ярату.
Каргыш түгел, якты табыш икән,
Ялгышны да татлы сагыш иткән
Кемдер өчен яшәп җан ату.

Синекенә охшаш минем холкым.
Мәхәббәтме шулай үзгәртте.
Күңелемә сүнмәс кояш сыйган,
Гел яхшырам һәм яшәрәм сыман,
Җанга баккач синең күзләрең.

Беләм, син дә шулай яратасың,
Ишетәсең йөрәк тавышым.
Хәбәреңне алдым искән җилдән.
«Син – бергенәм!» – дигән сүзең белән
Бизәдең син гомер агышым.

Арабызда безнең айлар гына,
Еллар гына түгел – бер гомер.
Аеры яшәп, бергә тибә сыман,
Сөю хисе сузган татлы сыйдан
Бәлки, безнең йөрәк тиледер.

Йөрәк тавышын йөрәк ишетсенгә
Киртә түгел чакрым арасы.
Өметләргә тотынып үр менәсең,
Йолдызларга хәтле үреләсең,
Яктырганда төннең карасы.

Сазлавыктан атлавы да җиңел.
Чынбарлыкка хыял тоташса.
Өндә түгел, төштә булсын килү.
Сагынырлык кеше барын белү
Алып чыга ут һәм су аша.

Күңел кошың канат кагынганда
Атлап түгел, очып йөрисең.
Язын кабат гөлләр шыта җирдә,
Өтеп ала алмый салкын җил дә
Җанымдагы сөю бөресен.

ТЫЙНАК БУЛЫЙК!

Без бик күпләр бер чор балалары,
Кичкәнбез без бер үк сынаулар.
Безнең күзләр күрде ил тәнендә
Нинди яра салды сырхаулар.

Ил авырган чакта без авырдык,
Ил терелгән чакта – терелдек.
Тик сынмадык, аякка нык басып,
Алга таба карап йөгердек.

Төшеп калмадык без беркайчан да –
Ил арбасы булды төп урын.
Кеше алдында да сынатмадык
Һәм шаһиты булдык ул чорның.

Бер гасырны яшәп бетердек тә,
Икенчесе ачты ишеген.
Артта калды бер катлаулы дәвер,
Дәвам итә тормыш, юк шигем.

Яңа гасыр китабының хәзер
Битләренә язып тарихны
Раслыйбыз исән икәнлекне,
Дәлиллибез ил-җир барлыкны.

Җир шарыбыз исән, илебез дә...
Без дә исән! Исән әлегә...
Без яшәрбез, илебез дә яшәр
Кәрә белсәк җирнең хәленә.

Берәү генә, бер генә Җир шары!
Ә язмышы кеше кулында!
Төшендерсен, һәрберебез шуны
Соңлаганчы кызы, улына.

Җир шары ул уенчык та түгел,
Туп та түгел тибеп уйнарга.
Бирелмәсен беркем: «Күчәреннән
Аерып алам!» – дигән уйларга.

Без – җирнеке, ә җир кешеләрнең
Изге йорты! Анда без кунак.
Һәр мизгелнең кадерен белеп яшик,
Кунак кына... булыйк без тыйнак!

КИРӘКМИ!

«Ничекләр мәхәббәт булмасын?!» –
Диясең кереп син төшемә.
Кирәкми, җил булып назлама,
Кош булып кунма син түшемә.

Уятма йокыдан вакытсыз,
Үтенәм, бүлмә син төшемне.
Кыен ул, күз ачкач, куеныңда
Күрмәгәч кадерле кешеңне.

Ялгыш та чакырма, кирәкми,
Янәдән мәхәббәт иленә.
Болай да сагынган чагында
Йөрәгем кырыкка теленә.

Салкын ай нурыннан сискәнеп,
Йөз кабат уянам һәр төндә.
Теләмим төшләре бүленгән
Йокысыз төннәрне беркемгә.

КИЧЕРЕГЕЗ МИНЕ!

Каргамагыз мине, гөл-чәчәкләр!
Һади Такташ

Каргамагыз мине, җир гөлләре!
Мин уяттым сезне таңнарда,
Кара төн пәрдәсе ачылып килгән,
Томан сарган чакта талларга.

Чык тамчысын былбыл эчкән мәлдә
Мин болында йөрдем хисләнеп.
Ялгыш кына кагылды да кулым,
Таҗ-керфекләр куйды сискәнеп.

Куркытырга теләмәдем сезне.
Сәер шул мин бала чагымнан.
«Ярата...» дип, балдай өмет өздем
Ромашканың нәфис чугыннан.

Болындагы куе үлән үсеп,
Узып киткән чакта билемнән,
Таң алдыннан сахраларга чыгып,
Узыштым мин җиләс җил белән.

Ә аннары саубуллашмый гына
Китеп бардым чит-ят якларга.
Ачуланып калмадыгыз микән?
Килмәде бит сездән хатлар да.

Тик шулай да бик еш төшләремдә
Күрдем сезне таңнар атканда.
Керфек кагып серле елмайдыгыз,
Сирәк-мирәк кайткан чакларда.

Назлап сыйпаганда башыгыздан
Йомылды ла никтер таҗыгыз.
Язгы җилләр генә пышылдады:
«Сагынсагыз ешрак кайтыгыз!»

БУЙСЫНДЫМ

(сонет)

Хушлаштың, ышанычым ташлады,
Калдым кабат үзем белән күзгә-күз,
Сагышланма, сызма димен, бераз түз,
Суга сал күңелдәге ташларны.

Йөрәгемә булган шундый якын
Серле күзләреңнең балкыш яктысы.
Сүнмәгән, юк, җанда сөю чаткысы,
Хәзер дөрләп кабынырлык ялкын.

Мин тоямын мәңгелек төн сулышын,
Күргән чакта синең утлы карашың,
Еракта эзләп тапса тылсымы,

Газабы да татлы яңа бал төсле –
Мәхәббәтнең уты яна, һай, көчле,
Гаҗизләнеп вакытка буйсындым.

Мәдәни җомга
3 март
№8, 2023

● Мисырда Толбийә төрбәсе һәм кабере. Э. Сәйфетдинова фотосы.

Мисырда татар эзләре

Вак кыйпылчыклардан җыелган Алтын Урда тарихы соңгы елларда яңа мәгълүматларга байый бара. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев һәм өлкән фәнни хезмәткәр Эльмира Сәйфетдинова 1320 елларда Мисыр солтанына кияүгә бирелгән татар кызы Толбийә турында сөйләде.

Тарих битләреннән күренгәнчә, патша династияләре союздаш илләр белән туганлык җепләре җәелдерергә тырышкан, бер хакимнең улы икенче хакимнең кызына өйләнгән. Андый никахлар Алтын Урда дәүләтенә дә хас. Гарәп илләре белән туганлык җепләре аеруча ислам дине кабул ителгәннән соң ныгый. Бигрәк тә мәмлүкләр идарә иткән Мисыр белән элемтәләр көчәя. Арада иң тантаналысы һәм серлесе – мәмлүкләр солтаны Мөхәммәд ән-Насыйр белән Алтын Урда династиясе гаиләсеннән булган кыз, Мөхәммәд Үзбәк ханның туганнан туган сеңлесе (двоюродная) Толбийә никахы була.

«Үзбәк хан идарә иткән чордагы бу никах гарәп елъязмаларында матур тасвирлана, – дип бәян итә И.Миргалиев. – Без Толбийәнең нәсел шәҗәрәсен тикшердек. Үзбәк ханның атасы Тогрул белән Толбийәнең атасы Тукаҗи бертуганнар була. Димәк, Толбийә – Үзбәк ханның туганнан туган сеңлесе.

Толбийәне ән-Насыйрга кодалау берничә елга сузыла, 1320 елда гына Мисыр башкаласы Каһирәдә никах укытыла. Анда татар кызына зур ихтирам һәм хөрмәт күрсәтелә. Елъязмаларда теркәлгәнчә, Мисырда мондый купшы туй аңарчы оештырылганы булмаган».

Толбийә ән-Насыйр белән 8 ел яшәгәннән соң, никах өзелә. Никахның уңышсыз тәмамлануына, яңадан 3 мәртәбә Мисыр әмирләренә кияүгә чыгуына карамастан, Толбийә үлгәнче солтан хатыны статусын саклый.

«Толбийә Каһирәдә иганәчелек итә, йортлар, биналар төзетә. Ул үзенә мәрмәрдән төрбә дә ясатып куя. Толбийәнең сарае XVII гасырга кадәр саклана. Мисыр тарихчысы әл-Мәкризи һәм испан шагыйре Алонсо де Эрсилья-и Суньига сарайга сокланулары турында белдереп, язмалар калдыра. Каһирәнең бер урамы бүген дә Толбийә исемен йөртә», – дип өсти Э. Сәйфетдинова.

2022 елның декабрендә бер төркем галимнәр Мисырга барып, 5 көн дәвамында данлыклы Каһирә каберлеге белән танышып, гарәп галимнәре белән хезмәттәшлек корып кайткан. Алар каберлектә Толбийә төрбәсен дә күргән.

«Толбийәнең төрбәсе җимерек түгел. Аның янында башка каберләр дә бар – алар да тозек. Бераз акча кертеп, аларны матурлап җибәрәсе иде. Кызганыч, Мисыр бюджетында аларны тәртиптә тоту өчен акча каралмаган. Илнең хәле мактанырлык түгел. Бу каберлекләр туризм маршрутына да кермәгән, шуңа күрә мәмлүкләр каберлегенә игътибар юк. Иң аянычы – каберлек тикшерелмәгән, ә тикшерсәң, бик күп мәгълүмат табылу мөмкин. Татарстан Толбийә төрбәсен үз канаты астына алсын иде. «Россотрудничество» оешмасы да ярдәм итәбез, диде. Бу фикерне гарәп галимнәре дә хуплады», – ди И. Миргалиев.

Тарихчы бу эшне Мисырда «Мәмлүк һәм Алтын Урда бәйләнешләре» дигән темага конференция үткәрүдән башлауны тәкъдим итә. «Россотрудничество» үз бинасында кунаклар кабул итүгә әзер, гарәп галимнәре белән дә элемтә корылган.

«Конференциядән соң берничә галим – язма чыганакларны, берничәсе кабер ташларын өйрәнсә, реставраторлар Толбийә төрбәсен яңартуны үз өстенә алса, Алтын Урда буенча яңа чыганаклар ачылыр иде. Мисыр белән элемтәләрне ныгыту Татарстан өчен сәяси яктан да отышлы. Традицион ислам дөньясы буларак та, Алтын Урда белән тыгыз бәйләнешләр булуы белән дә, Мисыр – үтә кызыклы ил. Толбийәнең төрбәсен яңарту зур чыгымнар таләп итми. Аның каравы, мәмлүк солтанының хатыны татар кызы булганын күрсәтеп, милли горурлыкны арттырырга, киләчәктә гарәпләр белән элемтәләрне ныгытырга ярдәм итәчәк», – ди И.Миргалиев.

Толбийә тарихын өйрәнгәндә, фәндә моңарчы беленмәгән яңа шәхесләр килеп чыгарга мөмкин. Фәнни хезмәткәр Э.Сәйфетдинова Толбийә белән бәйле тагын бер татар шәхесен ачыклаган. Ул – туй процессиясе составында Алтын Урдадан Мисырга килгән Кусун исемле ир-ат. Кусун, солтанның ышанычын яулап, Каһирәдә әмир дәрәҗәсенә ирешә. Соңыннан ул солтан ән-Насыйр кызына өйләнә.

«Гарәп чыганакларында татар әмиренең халык алдында купшы күренергә яратуы турында мәгълүмат бар. Сүз уңаеннан, Кусунның да төрбәсе саклана. Бәлки, Сәиф Сараиның да каберен таба алырбыз. Каһирәдә татар эзләре буйлап экскурсияләр маршруты да ясарга мөмкин. Урта гасырларда мәмлүкләр Мисыры үсешендә татарларның өлеше зур булган», – ди галимә.

Сәиф Сараи телгә алынгач, сүзебезне якынча 700 ел элек Алтын Урдада туган татар шагыйре турында дәвам иттек. Сәиф Сараиның галим, шагыйрь булып формалашкан вакыты дәүләтнең болганчык чорына туры килә. Башта чума афәте халыкны кайгыга салса, аннары Аксак Тимер Туктамыш ханга каршы сугыш башлый. 1380 елларда Сәиф Сараи Мисырга күченеп китә. Аның бәхетенә, Алтын Урданың чәчәк аткан чорында гарәп илләре, аеруча Мисыр мәмлүкләре белән илчелек мөнәсәбәтләре урнаша, илләр арасында сәүдә җайга салына. Тарихчылар Сәиф Сараины Мисырга йә илчеләр, йә сәүдәгәрләр ияртеп киткәндер, дип фаразлый, чөнки ул биредә Мисыр солтаны Заһир Сәйфетдин Бәркүкнең лаеклы хөрмәтенә ирешә, солтанның канцеляриясендә эшли. Сәиф Сараи фарсы, гарәп, төрки телләрне яхшы белә, күренекле галимнәр белән аралаша, бүгенге төрки һәм гарәп дөньясына мәгълүм булган «Гөлестан бит-төрки» әсәрен Мисырда яза. Шушында ук Туктамыш хан белән Аксак Тимер сугышларына турыдан-туры караган бөек әсәрен – «Сөһәил вә Гөлдерсен» не иҗат итә.

«Солтан Заһир Сәйфетдин Бәркүк үзенең хөрмәтле галимнәрен үзе янына күмүне васыять итеп калдырган. Бу турыда безгә Каһирә профессоры бәян итте. Сәиф Сараиның кабере солтан каберлегендә булырга мөмкин. Каберлек, андагы ташлар да ярыйсы хәлдә сакланган. Аларны Каһирәгә барып өйрәнергә кирәк. Мисыр архивларында һәм китапханәләрендә эзләнеп, Сәиф Сараи һәм, гомумән, Алтын Урда белән бәйле яңа ачышлар ясау мөмкин», – дип өсти И.Миргалиев.

Сәиф Сараины без урта гасыр татар шагыйре дип беләбез. Кыпчак телле башка халыклар да аны үзенеке дип таный. Татарлардан күреп, казахлар, үзбәкләр дә аны якын итә башлады. Шулай да, Сәиф Сараины өйрәнүгә татар галимнәре нигез салды. Аны танытуда тел галиме Хатыйп Миңнегуловның, тюрколог Әмир Нәҗиповнең, археолог Равил Фәхретдиновның өлеше зур.

Сәиф Сараиның туган урыны дип, Самара өлкәсе белән Татарстан чигендә урнашкан Камышлы авылы билгеләнде. Үзенең әсәрләрендә ул Идел-йортта, Камышлыда туганын күрсәтә, шуңа күрә Сәиф Сараины, шикләнмичә, татарныкы дип әйтә алабыз.

«Сәиф Сараины өйрәнеп, урта гасырларның сәяси тарихын күзалларга мөмкин. Туктамыш, Аксак Тимер, Бәркүк – болар барысы Сәиф Сараи чордашлары. Бу чорда Алтын Урда җимерелә. Безгә ул заманнан тарихи кыйпылчыклар гына килеп җиткән. Без шулардан тулы картина төзергә тырышабыз. Булган кыйпылчыклар илдә җитди сәяси процесслар барганын күрсәтә. Телне куллана белү, мәдәният, фән үсеше – бөтенесе булган. «Сөһәил вә Гөлдерсен» әсәрендә Туктамыш белән Аксак Тимер сугышы да, мәхәббәт тә, ватанпәрвәрлек тә бар. Ягъни, зур булмаган бер әсәрдә төрле темалар бик оста ачыла.

Бәркүк солтанның каберлеге исән. Ул шактый зур һәм яхшы сакланган. Бәркүк безгә ни өчен мөһим? Ул Туктамышның союзнигы була, Алтын Урда тарафдары буларак, Аксак Тимергә каршы сугыша. Аның янында Сәиф Сараи да эшли.

Без Мисырда Бәркүкнең ике комплексын күрдек. Беренчесе – сөт әнисенеке. Солтан ул урынны бик яраткан, анда еш кына барып, догалар укый торган булган. Икенчесе – үзе күмелгән урын. Ул бик зур. Сәиф Сараи да шунда күмелгән булырга мөмкин.

Алтын Урда тарихын тирәнрәк белү өчен Мисыр мәмлүкләрен дә өйрәнергә кирәк, чөнки Алтын Урдада ислам дине кабул ителгәннән бирле, ханнар белән мәмлүк солтаннарын дуслык кына түгел, туганлык җепләре дә үзара бәйләгән. Урта гасырларда ике ил җитәкчеләре арасында кыз алышу традицияләре булган. Алай гына да түгел, мәмлүкләрнең бер өлеше – безнең яклардан чыккан кыпчаклар икәне мәгълүм. Мәмлүкләр көчле, оста сугышчы булган. Алар хәтта «Тәре походы»н туктата алган. Мәмлүкләр хакимлек иткән чорда фән, мәдәният алга киткән. Безнең галимнәр аларга барып укыган, ә Мисыр үз мәдәниятен Алтын Урдада җәелдерергә тырышкан. Безгә туры килә торган традицион исламның чишмә башы Мисырдан. Бүген дә дин белгечләребезнең Мисырда укып кайтуы очраклы түгел», – ди И.Миргалиев.

Рифат КАЮМОВ.

intertat.tatar

ОСТАЗЫБЫЗНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Шагыйрь Риза Шәфиев 1923 елның 20 февралендә Башкортостанның Кыйгы районында, Үрге Кыйгы авылында гади крестьян гаиләсендә дөньяга килгән. Гаиләдә сәнгатькә, әдәбиятка игътибар зур булган, шуңа да әтиләре балаларын гыйлемле итеп күрәсе килгән.

Урта белем алган Риза Казанның педагогика институтына, татар теле һәм әдәбияты факультетына укырга керә. Тик аңа укытучы булырга язмый, сугыш башлана һәм аны Ульяновск хәрби училищесына укырга җибәрәләр. Соңрак, 1947 елда Р.Шәфиев Томск шәһәрендә хәрби академия дә тәмамлый.

Хәрби инженер эшен Р.Шәфиев Новосибирскиның фәнни-тикшеренү институтында, аннары Саратовның авиаприборлар заводында дәвам итә. Ә 1958 елда гаиләсе белән Воткинскига килеп урнаша һәм машиналар төзү заводында эшли башлый.

Риза Закир улының 30 ел гомере хәрби эштә уза. Воткинск машиналар төзү заводында эшләгән елларын язучы яратып, горурланып искә ала иде. Тик, ни әкәмәт, бергә эшләгән хезмәткәрләре ничә еллар яннарында язучы утыруын хәтта белмәгән дә...

Р.Шәфиевнең беренче шигырьләре 1950 елларда «Яшь Сталинчы» газетасында басылып чыга, кайбер язмалары «Үсү юлы», «Идел» альманахларында, «Чаян» журналында басыла. 1962 елда мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен язылган «Каен, Чыршы һәм Кисәү» исемле китабы дөнья күрә. Казан, Уфа, Ижау шәһәрләрендә бер-бер артлы шигъри әсәрләре, мәкаләләре, китаплары басыла. 2001 елда ул Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

Риза Шәфине язучы, шагыйрь, публицист буларак Удмуртиядә генә түгел, Башкортстан белән Татарстанда да яхшы беләләр иде. Ул гомер буе укучыларына лирик шигырьләрен, юмор-сатира үрнәкләре, мәкальләргә тиң икеюллыклар һәм хикмәтле сүзләр бүләк итеп яшәде.

Бервакытта Шәһинур Мостафин болай дигән иде: «Риза Шәфи кебек шәхесләр йөз елга бер генә туа. Аның һәр сүзеннән, һәр шигъри юлыннан күңел җылысы саркып чыга. Паганини кебек бер кылда уйный белә ул». Янә Вахит Имамов та Риза абыйның иҗатына карата: «Безнең татар элек-электән ат кебек эшләгән. Риза абый да гомер буе хәрби хезмәттә булган. 30 яшендә үк шигъриятькә килгән булса, бәлки, ул да үз исемен Мөдәррис Әгъләмнәр шикелле яңгырата алыр иде», – дип әйткән иде. Ә Риза абыйның якташы Рим Идиатуллин аның шигырьләрен укыгач: «Р.Шәфи иҗаты белән үзенә рухи һәйкәл коеп калдырган», – дип саный.

Аның иҗатына тагын бер тапкыр күз төшерик әле.

Кызыкмадым бу дөньяның алтынына,
Санамадым мәрҗәннәрен байлыгыма.
Күз салмадым, табынмадым
нахак малга,
Тир түккәнем җитә килде айдан-айга.
Комсызланып тупладым мин
фикерләрне –
Күңелләрдән-күңелләргә күперләрне.
Хикмәт биргән зиһенләләр
иң бай заттыр,
И күңелем, күперләрең санын арттыр.

Шагыйрь үзенең иҗатында укучыларны туган телне, туган илне яратырга, тынычлыкны, табигатьне, матурлыкны сакларга чакырып яшәде. Ул икеюллык, дүртьюллыкларында да күпне әйтә алган. Мәсәлән:

Җәйнең һәр гамәле изге:
Игеннәр серкә очырды....
– Ике әрем үскән каберенә...
– Ике кызы ятим калды.
Шагыйрь күңеле – кизләү комы:
Кайчан бакма – саркыр моңы.
Кичә бу гөлдә күбәләк иде...
Бүген – син дә юксың.
Килен килде: – Матурмы?
Кияү китте: – Кайтырмы?
– Ир икәнсең – иңеңә ал ил язмышын!

Сиксәненче елларда Р.Шәфи Башкортстанда яшәп иҗат итүче композитор Рим Хәсәнов белән таныша. Ул дуслыктан аларның матурдан матур җырлары туа: «Татар вальсы», «Чияләрең чәчәк атканда», «Әнкәй җылысы», «Елмай», «Сандугачлар тирәктә» һ.б.

Р.Шәфи Воткинскида гомер итсә дә, республиканың татар, башкорт җәмгыятьләре, «Яңарыш» газетасы белән тыгыз элемтәдә яшәде. Аның шигырьләрен, заводның уңган эшчеләре турындагы мәкаләләрен газета битләрендә еш күрергә була иде. Әле ул вакытта гөрләп эшләп килгән татар сыйныфлары, «Тургай» ансамбле үзешчәннәре белән дә еш очрашты. Шагыйрьнең юбилейлары һәрвакыт бәйрәм кебек, зур мәдәният йортларында узды. 2004 елны «Тауларым иңендә таулар» дип исемләнгән соңгы китабын халыкка тәкъдим итү кичәсенә шагыйрь авыру сәбәпле килә алмады, 3 декабрьдә Р.Шәфи вафат булды.

Шул ук елны Р.Шәфи яшәгән йорт диварына «Бу йортта 1976-2004 елларда татар шагыйре Риза Шәфиев яшәде» дигән мемориаль такта куелды. Һәр елны февраль аенда «Тургай» халык ансамбле үткәргән чараларда аның җырлары, шигырьләре яңгырамый калмый. Р.Шәфи «Тургай» дип исем кушкан коллектив та язучыны онытмый, ел саен каберен зиярәт кылалар, белгән догаларын укыйлар. Ижауда яшәп иҗат итүче татар язучылар бүлеге дә Р.Шәфи исемен йөртә. 2008 елда республикада иҗаттагы уңышлары өчен, язучыларга һәм журналистларга Р.Шәфи исемендәге премия булдырылды.

Шушы көннәрдә шагыйрьнең тууына 100 ел тулса да, аның иҗаты, шигырьләре һәм җырлары халык күңелендә яши.

Гөлфия ИСХАКОВА,
Воткинск шәһәре. Удмуртия.

«Марҗа кызлар»

Безнең зирәк укучы «марҗа» сүзенең һич тә кимсетү мәгънәсендә түгелен, ә бәлки бары Мария исеменең дини яктан да, көндәлек урыс тормышында киң таралуыннан икәнен, татар сөйләм үзенчәлегенә генә яраклаштырылуын, билгеле, күптән белә. Шушы урында янә дә алдан ук кисәтелә: түбәндәге язма бу кызларны хурлаудан түгел, ә халык иҗатының бер төре кушамат тагуга бәйле. Әйтик, Нәсихларның кайсы турында сүз баруын тиз генә тыңлаучыга җиткерим дисәң, Якыйныкы, Титак, Быдыр, Әхсән һ.б шундый билгеләмә кем турында сүз бару адресын бик тиз күрсәтә.

Сүзем кызлар турында лабаса. Әйе, урамыбызда күршеләр диярлек ике кыз буй алып килә. Дөрес, исемнәрен язмыйм, белмәссең, исән булулары ихтимал һәм инде мәңгелеккә тыныч кына китәргә өметләнгән җаннарын юк-бар белән борчу теләгем юк.

Әлеге ике кызның кайсы «атаман»рак, ягъни башлап йөрүен тәгаен әйтү кыен булыр. Икесенең дә әтиләре сугышта ятып калган. Авыр сугыш елларыннан җай гына тернәкләнеп килү чоры. Безнең өйдән уң ягындагы кызның әтисе, имеш, профессиональ хәрби булып, Ватан сугышына кадәр дә бик күп яу кырларын узган, җиңү яулаган зат була. Аеруча әтисенең данлы үткәне белән кызның 1940 елда туган энесе горурлана иде кебек. Шуңа да урам малайлары белән чынлап торып бәргәләшкәндә дә, ул үзенең салкын канлылыгы, аек тотышы белән кирәк урында йодрыгын тиешле җиргә бәреп, чапаланган, кызып ни эшләргә белмичә сугышкан көндәшен бик тиз әвәли иде.

Апасында да энесендәге холык чамалары булса кирәк. Аерма бары шунда: эне ир-егетләргә хас аз сүзле, ә апасының теле чамадан тыш чеметерлек дәрәҗәдә булган ахры. Әлеге фикергә түбәндәге тарих этәрә. Нигә тотынса, шуннан нәтиҗәле эшкә һәвәс эни сарык тиреләрен эшкәртеп, абыйга сары тун тегеп кидерде. Тун шундый ыспай булып, абыйга килешеп тора иде кебек. Менә көннәрнең берендә абый тунын кимәс булды. Моны ул уң як күрше кызының абыйга карата «сары тун сарыгы» кебек кимсетүле сүз ишеттергән булуы белән аңлата. Чыннан да тун кыйссасы шуның белән тәмамланып, сырма фуфайка рәвешендә дәвам итте.

Икенче кыз героебыз – каршы яктагы күрше. Беренчесеннән аермалы буларак, бу кызның туганнары бишәү була. Иң кече энесеннән өлкәнрәк булып, беренче кыз белән бер сыйныфта укыган булулары ихтимал. Бик гайрәтле аталарының рухы барлык балаларында да бер өлеш чагылыш алган: барысы да чибәр, физик яктан көчлеләр, эшкә сәләтлеләр.

Менә бер заман авыл мәктәбендә 6 яки 7 сыйныфны тәмамлагач, әлеге ике кыз 10-15 чакрым ераклыктагы урыс авылына йөреп укый башлады. Революциягә кадәр без Микулин авылына караган волостьта булганбыз (бүген ул авылның эзе дә калмаган инде). Аннан бераз арырак Павловка авылы булып, тагы да арырак Митрәй – кайсы авыл мәктәбен сайлап, ни дәрәҗәдә гыйлем туплаганнардыр, әйтүе кыен. Менә кайткан-киткән арада андагы укучы малайларның йогышсыз кыланмышларын, аннан үзләштергән йогышсыз сүзләр белән сөйләгәннәре бераз колакка кереп калган.

«Марҗа кызлар» кушаматлы булып киткән әлеге күршеләрнең язмышын күзәтү җае булмады. Алар өлкәнрәк булу сәбәпле, бик тиз зурлар тормышына тартылдылар. Истә аеруча калганы шул: бай Зәкинең уртанчы малае нефтьчеләр оешмасында эшләп, бик затлы аккордеон алган булган. Шул аккардеон тавышы уң күршенең тыкрык башында ук кыз янына килүен белгертеп тавыш бирә иде. Бөтен урам кемнең кем янына килүен, очраларның кайда дәвам итүен белеп торды. Тагы да соңрак хатын-кызлар күрше кызыбызның билен аеруча кысып бәйләвенә игътибар итәләр, ә аннары аның каядыр Казахстанга ук китеп баруы турында сөйләнделәр. Энесе институт бетереп, шактый уңышлы урында эшләгәнлектән, апасы турында сорашу уңайсыз тоелды.

Каршы як күрше кызыбызга почта аша биек үкчәле туфли кайтартулары истә. И-и-и аның куанулары! Шул туфлиен киеп, ул авыл клубында урысчалатып, «Барыня» көенә биергә дә өлгерде әле. Аннан Бөгелмә егетенә кияүгә чыккан дигән хәбәр таралды. Авылда туй ясап өйләнешкән булсалар (мулла чакырып никахлашу юк заман), яшьтәш энекәше ярдәмендә ничек тә күрергә тырышкан булыр идек. Ә болай хәтердә һәр ике кызның да бары гыйбрәтле кушаматлары гына сиздереп-калкып чыга. Сиздермәс иде дә, үтә чибәр, көр авазлы кыю кызларның чит оеткыга бирелүе бүген дә уйларга тынгылык бирми. Әле « марҗа әби» дә булып китмәделәр микән...

Нарим ИХСАНОВ.
Казан.

Мәдәни җомга
3 март
№8, 2023

Асия РӘХИМОВА

ЙОМШАК АГАЧ

Ул кешедән күләргә ярата иде. Берәр форсат чыкса, нинди төстә дип тә әйтеп булмый торган күзләре кинәт ялтырап китә, ияге өскә чөелә, авазлары исә, артыннан көчкә этеп җибәрелгән кебек, ерылган авызыннан өзелеп-өзелеп чыга иде. Шул мәлдә бер аягын артка-алга шудырып алырга да өлгерә иде. Йөргәндә озын буе җилдә тирбәлгәндәй була, аяклары исә, мари биюендәге шикелле, берсен-берсе куалап барадыр кебек иде. Озын, чандыр буй аңа кешеләргә өстән карарга да мөмкинлек бирә һәм ул бу мөмкинлекне кулланмый калмый торган иде.

Бәлки, ул аның һавалылыгы, кешедән көләргә яратуы да булмагандыр. Атасының ул бала чакта ук эчеп үлүе; арка сөякләре чатыр-чотыр килгәнче җилкәсендә алты балалы авыр тормышны ташыган анасының да, картайганчы ук урын-җир өстенә авып, озак та тормыйча, бу дөньядан китеп баруы; сеңлесенең җилдән бала табып йөзләрен каралтуы; олы туганнарының бу ике кечене ялгыз калдырып, дөньяның дүрт ягына китеп олагулары кебек хәлләрдән оешкан кара язмышына баш бирмәскә тырышуы; аяклары чатый-пытый килсә дә, дөнья белән бергә атларга маташуыннан туган ясалмалылык, битлек кенә булгандыр, бәлки. Әйтүе кыен: кеше карбыз түгел, урталай ярып карый алмыйсың.

Өйләнде. Кызның чибәрен, акыллысын алды.

Акыллы кыз аны танымый түгел, таный иде: «Бозау инде...»дигән уй күңеленә, хәтта теленә дә килеп китмәде. Ләкин гаиләдә олы бала – киңәш сорар, үрнәк алыр кешесе юк. Ә этисе-әнисе белән кыз бервакытта да ачылып китеп сөйләшә алмады. Шулай да, ул бер кешенең әйткәненә колак сала, санлый иде: мишәр җиңгәсе – әнисенең кече энесенең хатыны турында бара сүз. Менә беркөнне аның балачактан ук колагына тукып килгән сүзләрен тагын исенә төшерде. Беренче ишеткәндә, ул сүзләргә шаккаткан иде.

Җәйге бер шимбә көнне Казаннан мишәр җиңги үзе генә кайтып төште. Кулында зур, авыр бидоны да бар иде. Төзелештә, буяу эшендә эшләүче җиңги шулай сирәк-мирәк авылга «чумара» буяу алып кайтып сата торган иде. Кибеттә алырга әйбер юк вакытлар. Ә монда өеңә китереп бирәләр: кеше ала.

Бу юлы бик матур яшел буяу алып кайткан иде. Авылда бер-ике кеше беразын алды. Җиңги кемнәндер ишетеп кайтты: буяу кирәк кеше күрше авылда да бар икән. Авыл ерак түгел, ара ике чакрым гына. Инеш яры буйлап барасың-барасың да, күрше авылның чишмәле аскы урамына килеп тә керәсең. Җиңгигә иптәшкә дип, әнисе аны да ияртеп җибәрде.

Җиңги үзгә телендә, «к»һәм «ч» авазларын бик кызык итеп әйтеп, юл буе сөйләнеп барды. Әле кызчык кына, нәрсә дип сөйләшсен, ул тыңлап кына атлады. Сүз иярә сүз чыгып, җиңги хәләл җефете турында нидер сөйләгәндә, кинәт әйтеп куйды: «Үскәч, кияүгә ятим егеткә чык, сеңлем, ялгышмассың. Артында таяныр кешесе булмагач, кукраймый, сүз тыңлаучан була. Тормышыңа да берәү дә кысылмый. Мин кечкенә кызчык чагымнан ук, гел шулай дип теләдем, кабул булды. Абзыең бик әйбәт кеше бит, теле-теше дә, кул уйната торган гадәте дә юк. Артыгын эчми дә. Эчсә, бер гадәте бар барын: өстендәге күлмәген, якасының ике ягыннан тотып аерып төшерә. Анысы гына ни...».

Әйе, әнисеннән ишетеп белә: дәү әнисе белән дәү этисе бу дөньяны калдырып, бер-бер артлы китеп барганда, ул әле мүкәләп йөри торган сабый гына, ә абзые, сигез класс бетереп, Казанга төзелеш училищесына укырга киткән генә булган.

Мишәр җиңги үзе дә тыныч холыклы иде. «Метер» дип даны чыккан бабай, буяу өчен ул сораган акчаны киметеп биргәч тә, әллә ни сүзләнмәде. Кире кайтканда: «Һе, битун эчендә сыланып калды, барысы да төшмәде, имеш. Һе...», – дип сөйләнүеннән шактый хәтере калганы аңлашылды үзе.

Җиңгинең бу киңәше зиһененә кереп урнашкан иде, аннан соң инде бер дә чыкмады. Озын, чандыр егет белән танышып, бер-ике ел озатышып йөргәннән соң, ул аңа кияүгә чыкты. Егет ятим дә иде. Кызның үзенә дә шундый борып йөртә торганрак кеше кирәк иде. Акылы икесенә дә җитәр, дип уйлады.

Беренче балалары кыз булды, тик яшәмәде генә. Биш яшендә, сары ияртеп, үлеп китте. Икенчесе малай иде. Хатынның үзенә охшап чибәр, атасына охшап буйлы-сынлы булып үсеп җитте.

Хатынның төн йокылары качты: улының холкы да нәкъ атасыныкы кебек иде. Борып йөртергә кирәк. Борып йөртүчесе табылыр, тик менә аның үзе шикелле акыллы була, ире артында кала белерме? Заманасы заманамыни? Димләп өйләндереп буласы юк. Хатын җанын кая куярга белми, борчуыннан көннән-көн ябыга бара иде.

Ә беркөнне, бер карарга килеп, җиңел сулап куйды. Мәчеткә китте ул, Корьән уку дәресләренә язылды, намазга басты. «Аллага тапшырдык!» – ди иде. «Аллага тапшырдык!»

Йомшак агачны корт баса, ди. Улы янында гел күзләрендә ат тоягы эзләре ялтыраган кызлар йөри. Менә беркөнне тагын бер кыз ияреп кунакка килде, монысы чит илдән укырга килгән татар кызы. Дөрес, чит ил кешесе булгангадырмы, улы бу юлы алдан кисәтеп куйды. Хатын өйне ялт иттереп җыештырып, өчпочмак пешереп куйды ул көнне. Сөйләшә-сөйләшә, табын артында сыйланып утырдылар. Кыз чит тел акценты белән мәзәк итеп сөйләшә, олыларга «син»дип эндәшә. «Син бу өчпочмакны бик тәмле пешергәнең, әйе». Беренче күргән, үзеңнән шактый олы кешегә бездә болай эндәшү сәер булганга, ире дә, хатын үзе дә ирен чите белән генә елмаеп-елмаеп куялар иде.

Кызны озатырга дип, улы чыгып китте. Ире сораулы карашын хатынга төбәгән, көтә. Җавап урынына хатын иңбашларын гына сикертеп куйды: белмим, янәсе.

Журналда укыганнар иде бу кунак кыз турында, фоторәсеме дә бар иде. Үз илләрендә шактый бай сәүдәгәр нәселеннән икән. Асылынсаң асылын алмагачның асылына, диме әле безнең халык? Улы әллә шул якларга каерылырга йөриме?

Өстәлне, савыт-сабаларны җыештыргач, гөлләренә су сибәргә дип, хатын балконга чыкты. Ире табак-савытларны юарга тотынган иде инде. Җиденче каттагы фатирларының балконы йорт янындагы мәйданчыкка карый, урындыкта утырып торган улы белән кунак кызга күзе төште.

Кыз, бик килешен китереп, сигарет тартып утыра иде. Улы тартмый.

И бу безнең милләт, бик үк белеп бетермәсә дә, тәмләп сүз сөйләргә оста да инде. Журналда кызны үтә тәртипле, үтә милли җанлы дип мактаганнар иде, эчмәвенә-тартмавына да басым ясаганнар иде бит. Күрсенеп куйды...

Моннан соң догаларында: «Балама хәләл сөт имгән, хәләл ризык белән ризыкланган иманлы хәерле кыз насыйп ит», – дип соравын арттыра төште.

Уллары университетның чит телләр бүлеген укып бетереп, аспирантурага кергән иде. Инглизчәсе бик яхшы. Форсат чыкканда, телен шомартыр өчен, чит ил кешеләре белән дә аралашырга тырыша. Бу кыз белән аралашуы да шуның шаукымы гына булган икән...

Көннәр үтә торды. Ә беркөнне улы өйгә кунарга кайтмады. Кичтән, телефоннан шалтыратып, бер дустының туган көненә барасын әйткән иде үзе. Төнлә хатынның йокысы ачылып китте дә, урыныннан торып, коридорга чыкты. Улының бүлмәсенең ишеге ачык: димәк, әле дә кайтмаган. Кайтып яткан булса, ишеген яба. Аннары ишек төбендәге кечкенә келәмгә карады. Улының гадәте: кич кайткач, аяк киемен ишек катындагы келәмнең нәкъ уртасында калдыра. Аяк киеме дә юк иде.

Түр бүлмәгә узып, тәрәзәдән ишек алдына карады, бер читеннән урам күренә. Урамда берән-сәрән булса да яшьләр йөри. Ишек алдына, сирәк булса да, машина кайтып туктый. Әллә ничәсен улыныкына охшатып, ерактан ук карап кертте: юк, башка булып чыкты. Аннары кабат кереп ятты. Ул боргаланганга, ире дә йоклый алмый. Хатын, аны борчымас өчен, торып, өстенә халатын гына элде дә, тагын йокы бүлмәсеннән чыгып китте. Сәгать дүрт тулып киткән. Бу вакытта телефонына шалтырату бик акыллы эш булмас, сабыр итеп көтәргә кирәк.

Кухня өстәленә таянган терсәкләре оеп, башы куллары өстенә төшкән, йокыга куерып киткән икән. Ишектәге кыштырдауга уянып китте, шундук аңлап алды, урыныннан кымшанмады: кереп ятсын инде.

Җиткән егет анасы булуына ияләнә бара иде инде хатын.

Беркөнне уллары, ниһаять, бер кызны яратуын, киләчәктә аңа өйләнергә теләвен белдерде. Хатын белән ир бер-берсенә карашып алдылар. Бер таптыр да күргәннәре булмаган бу килен буласы кыз кем икән? «Наринә», – диде уллары. Катнаш гаиләдән икән. Әтисе Казанда туып үскән әрмән, әнисе – бик катлаулы рус, нәселендә поляк та, алман да, тагын әллә кемнәр бар, ди. Аспирантурада бергә укып, бергә бетерәчәкләр, тик кыз диссертациясен вакытыннан алдарак та яклаган икән инде. Егетнең яклавын көтеп тормаячаклар, Наринәнең әтисе һәм әнисе Ереванга күчеп китәргә җыеналар, яшьләр дә алар белән китәчәк.

Иренең йөзеннән каралык шуып үтте, ләкин ул эндәшмәде. Хатынның чигәләре кысып, йөрәге чәнчеп куйды да бөтен гәүдәсенә эссе һава килеп бәрелгәндәй булды. «Аллаһым! – диде ул пышылдап кына, – Йә, Аллаһым! Бер үзеңә сыенам!»

Кырым энҗесе

Октябрьгә кадәр татар кызларының югары белем алуда күргән кыенлыклары һәм, максатларына ирешкәч, милләтебезгә кылган игелекләре хакында язганда бу тиңдәшсез батырлыкны бәяләргә сүзләр табу читен. Тырышлыклары алдында бүген дә баш иярлек.

XIX гасыр үтеп барган чорда да (!), патша Александр II нең 1870 елның 26 мартында «Правила о мерах образования населяющих Россию инородцев»дигән указы чыккан һәм бу документта Төньяк халыклары, Себер, Урта Азия халкы, кавказлылар, татарлар һәм яһүдләр «неполноправные инородцы»дип бәяләнгән. Бу халыкларны кимлектә, хурлыкта тоту царизмның төп сәясәте булуы хакында сөйләмиме? Татарларның гасырлар дәвамында дөньяви мәктәп ачудан да мәхрүм ителеп яшәүләре шул сәясәт нигезе бит инде. Шул ук вакытта, дөньяви белем бирә торган урыс уку йортларының ишекләре татарлар өчен, аерым очракларны исәпкә алмаганда, гел ябык булуы да тарихи факт. Шуңа күрә дә «инородец»ларның фән һәм дөньяви белем йортларына кереп укый алулары – бәяләп бетерә алмаслык каһарманлык та ул. Шунысы куаныч, рус кызлары өчен генә башкалада югары уку йортлары ачыла башлап, 15-20 ел үтүгә үк, татар кызлары да аларга кереп укый алган, диплом да алып чыккан. Бу хакта «Ступени образования до Сорбонны»дигән китабымда яздым инде, шөкер. Ул хезмәтем шул каһарман кызларыбызның исемнәрен мәңгеләштерүдә бер адым иде. Мондый батыр йөрәкле кызларыбызның исемнәре билгеле булса да, тормыш юллары хакында бик аз язылды әле. Ә асылда, алар – безнең горурлыгыбыз, милли хәзинәбез, тормышыбызның матур мактанычы.

Шундый гүзәлләрнең берсе – Кырым татар кызы Диләрә Булгакова. Ул 1895 елда Ялтадан ерак түгел Дерекой (Дәрәкой) авылы дворяннарыннан саналган Али морза Булгаков һәм Зөһрә Солтан ханым гаиләсендә туа. Диләрәдән башка гаиләдә тагын өч бала – Бәхтияр, Котлыяр һәм Гөлнар үсеп килә. Гаиләнең токкасы Али морза – Таврия губернасы земство идарәсендә Евпатория өязеннән һәм берүк вакытта Таврия дворяннар җыелышында Ялта өязеннән депутат булып сайланган мөхтәбәр зат. Кырым татарлары арасында үзенең зыялылыгы белән хөрмәт казанган зат булуы өстенә, иганәчелек белән дә шөгыльләнеп, халкына күп игелекләр эшләгән. Шәфкатьлелек һәм мәгърифәтчелек сыйфатлары Али Булгаковның балаларына да күчкән икән.

Булгаковлар гаиләсенә һәм, гомумән, төрки халыкларда мәгариф тормышын үзгәртүгә зур өлеш керткән зыялы Исмәгыйль Мостафа улы Гаспралы һәм аның хатыны Зөһрә Әсфәндияр кызы Акчуринаны искә алмый булмый. Алар чыгарган «Тәрҗеман»газетасы битләрендә хатын-кызларга, аларның азатлыгына багышланган мәкаләләр даими чыгып тора. Бу ике гаиләнең дусларча аралашып яшәве шик тудырмый. Диләрә белән Шәфика Гаспралы яшьтәшләр диярлек. Һәр ике гаиләдә балалар матур тәрбия алып үсә. Гаиләләрдә нәзакәтле мөнәсәбәт урнашып, үз телләреннән тыш гарәп, фарсы, рус, француз телләрендә иркен сөйләшә алуларын әйтеп узу да урынлы. Диләрә белән Шәфиканың дуслыгы Октябрьдән соң да дәвам итүе – шулай ук сокландыргыч.

Диләрә 1910-1914 елларда Петербургта хатын-кызлар өчен махсус ачылган Югары педагогика курсларында укый. Бу елларда Диләрә белән укыган татар кызларының исемнәрен атыйк: Сәгадәт Еникеева (Ташкент), Гөлсем Камалова (Чистай), Тәнзилә Котлыярова (Касыйм). Мәхфүзә Максудова (Петербург), Рокыя Юнысова (Петербург), Хәят Баишева (Пенза), Мәймүнә Шәфигуллина (Троицк), Сәлимә Якубова (Баку), Гөлсем Әсфәндиярова (Ташкент), Мәрьям Акимбитева (Сәмәрканд) һәм Хәят Мәмлиева (Казан кызларының исемнәрә язылмауга күңелсезләнмик, алар Югары медицина курсларында укыган). Күпме киртәләрне үтеп, башкалада уку бәхетенә ирешкән кызларыбызның тормышлары, хыяллары әдәбиятыбызда да чагылыш тапты. XIX йөзнең соңгы елларында әдәбиятка килгән әдип һәм мөхәррир Фатих Кәриминең (1870-1937) «Хыялмы, хакыйкатьме?» хикәясе – моның ачык мисалы. Әсәрдә, укучы кызның Думадагы мөселман депутатлары белән кулга-кул тотынышып, халык, милләт файдасы өчен эшләргә ниятләве хакында языла. «Бәнем максудым – үз ватаныбыз булган Русиядә торып, милләттәшләремә хезмәт итмәк, – ди ул. – Петербургта укучы мөселман кызлары барымыз унсигез кадәрле. Үземезгә махсус бер милли кружок ясадык вә ошбу нәрсәләргә карар бирдек:

– Үз арамызда ана телемездән башка һичбер телдә сөйләшмәскә вә ана телемезне онытмаска; төрле татар гәзитләре вә яңа әдәбият милләия рисаләләре (милли әдәбият китаплары) алдырып, шуларны укырга; милләтемезнең әфкяре, әхвале вә истикъбале (киләчәге) хакында төшенергә вә тарих миллиямезне үгрәнергә.

– Без табибә, акушерка, мөгаллимә булып, мөселманнар күп булган йирләргә барачакмыз, үземезнең мөгаләмәбез вә әхлакымыз илә анларны мәктәпкә вә укырга мәхәббәт иттерәчәкмез...»

Кызларыбызның үз алларына шундый максатлар куюында XIX йөзнең ахырында әдәбиятка килеп, зур әдәби һәм публицистик мирас калдырган язучы, сәясәтче, милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, олы шәхесебез Гаяз Исхакыйның (1878-1954) тырышлыгы зур. Ул үзе чыгарган «Ил»газетасында «Хатын-кыз өстәле»дигән бүлек ачып, даими рәвештә хатын-кызларга багышланган язмаларны чыгарып тора. Югарыда исемнәре аталган кызларыбызның күбесе – «Өстәл»нең даими авторлары да.

Диләрәнең тормышка мөнәсәбәте менә шундый шартларда формалаша. Аны якыннан белүчеләр кыз баланың бәләкәй чагында ук фикерләү сәләте көчлелеген, тирә-якка, кешеләргә карата җитди, төптән уйлаган үз фикере булуын әйтә торган. Аның әдәбиятны, сәнгатьне теләсә кемне сокландырырлык нечкә сиземләвен, матур итеп сөйли белүен дә күрсәтәләр. Бу сыйфатлар аңа рухи затлылыгыннан, образлырак итеп әйтсәк, «аксөяклелегеннән»килгәндер.

Кырымга кайткач, Диләрә хыялларын тормышка ашырырга тели. Бигрәк тә хатын-кызларның мәгариф өлкәсенә, уку һәм укыту эшләренә тарту өчен җиң сызганып эшли башлый ул. Озакламый Ялтада аның җитәкчелегендә хатын-кызлар комитеты оеша. Комитетның исеме дә үз максатын ачыклап тора – «Ени аят» («Яңа хәят»). Менә шул яңача тормышка хәзерләү өчен махсус курслар оештырыла. Курсларда наданлыкны бетерү белән бергә хатын-кызларның тормышта тигез хокуклы булырга тиешлеге аңлатыла, укымышлы ханымнар белән очрашулар үткәрелә, төрле-төрле темаларга лекцияләр тыңлана. Әмма Россиянең башка төбәкләрендәге шундый хатын-кыз оешмаларының эш тәҗрибәләре белән танышу, фикерләр уртаклашу мөһимлеге көннән-көн үзен сиздерә.

Ниһаять, бөтен өметләрне балкытып, якты язның 24 се көнендә (1917 ел) Казанның «Новый клуб»бинасында Бөтенрәсәй мөслимәләренең беренче корылтае ачыла. Кызыл әләмнәр белән бизәлгән бина хөрриятькә, тигез хокук өчен көрәшкә, бөтендөнья хатын-кызларын берләшүгә өндәгән лозунглар белән тулы була. Корылтайда Эчке Россия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Польша сайлаган 71 вәкилә залда чиксез дулкынлану кичереп утыра. Алардан тыш дөньяда күрелмәгән бу хәлне «күрү, ишетү өчен тагын өч йөздән артык хатын-кыз килеп баштан-ахырга кадәр чын ихлас белән утырды», – дип яза «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Якуб Хәлили.

Диләрә Булгакова (басып тора).

Корылтай хатыннарның шәригатьтә хокуклары; аларның гаиләдә тоткан урыннары; сәяси хокуклары; иҗтимагый тормышта тоткан урыннары; Учредительное собраниягә катнашулары кебек көн кадагында торган мәсьәләләрне тикшерә. Сайланып килгән вәкиләләр арасында Кырымның мәшһүр кызлары Диләрә Булгакова белән Шәфика Гаспралы да утыра.

Корылтайның исеме хатын-кызлар соравы буенча съезд дип атала башлый. Съезда, алга куелган мәсьәләләрне тикшереп карарлар кабул иткәч, эшне оешкан төстә алып бару өчен биш кешедән Мәркәз бюро оештырыла. Аңа Сәлимә Якубова, Заһидә Бурнашева, Диләрә Булгакова, Өммегөлсем Әсфандиярова һәм Рауза Солтангалиевалар бертавыштан сайланып куела. (Мәркәз бюро башта Мәскәүдә эшләргә тиеш булса да, соңрак Казанга күчерелә). Мәркәз бюро әгъзалары һәм янә 3 кеше: Хәдичә Ямашева-Таначева, Илһамия Туктарова, Мәрьям Криницкаялар Мәскәүдә шушы 1917 елның 1 маенда ачылачак Бөтенроссия мөселманнары съездына да вәкилә итеп сайлана.

Россия мөселманнары съездында Төркестан, Кырым вәкилләре, урыннарда халык мәгарифен үстерүдә булышлык сорап, Казан вәкилләренә үтенеч белдерә. Кырым татарларына ярдәм итү йөзеннән Илһамия Туктарова белән Зәйнәп Әмирханова Симферополь шәһәренә юллама алып килә.

Съездларда алган тәэсирләр, өметләр белән коралланган яшьләр хатын-кызлар арасында колачлы эш җәелдерә. Бакчасарайда хатын-кызлар комитеты оештырыла. Аның эш планы Мәркәз бюро күрсәтмәләрен истә тотып төзелә һәм уңышлы гына эшләп тә китә. Симферополь шәһәрендә хатын-кызлар өчен И.Гаспралы исемендә укытучылар хәзерләү мәктәбе ачыла; кыз балаларны башлангыч мәктәпләргә тарту, укый-яза белмәгәннәр арасында эшләү, газеталарга мәкаләләр язу – алар башкарган эшләрнең бик азы гына әле. Алар яшь буынны туган халкына намус белән хезмәт итәргә, аның бай тарихын, мәдәниятен, казанышларын өйрәнергә, милләтнең өметле киләчәге өчен нәтиҗәле көрәшкә рухландыра.

Өметләре дә акланган кебек була. 1917 елның августында Кырымда мөселман хатын-кызлары Үзәк Комитеты оеша. Диләрә Булгакова аның әгъзасы, бүлек мөдире. 1918 елда Кырым милли парламентына Диләрәнең якын дусты Шәфика сайлана. Эшләрен хуплап, ярдәм итеп торучы дуслары да табыла.

Ләкин язмыш аларның изге омтылышларын тормышка ашыруга киртә сала. Большевиклар власте Кырымда, соңрак Кавказда нығып, илдә дәһшәтле вазгыять урнашканнан соң, һәрбер йогынтылы хәрәкәтләр, милли көчләр көрәш мәйданын берәмберәм калдырып китә. Мондый шартларда Диләрәгә дә туган җиреннән аерылудан башка чара калмый. Ул Бакуга күчеп китә.

Кыз баланың шәхси тормышы да бар бит. Ул өлкәдә дә язмышы – йөрәк ярасына тиң. Үзе кебек зыялы татар егетләре белән өч тапкыр тормыш корып карый ул. Сайлаганнары да зыялылардан, фикердәшләреннән була. Тик сәяси репрессияләрдән берсе генә дә котылып кала алмый. Төрле елларда төрле сәбәп белән фаҗигале язмышка дучар була.

Диләрә Бакуда, Азербайҗан авылларындагы мәктәпләрдә рус теленнән дәресләр бирә. Рус телен камил белгәнгә, дәресләре үрнәк итеп куела. Сугыш башлангач (1941-1945), мәктәпләрдә дәресләр кыскара, байтак мәктәпләр ябыла. Янында аның тәрбиясендә энисе, балалары да бар бит, матди хәле кискенләшә. 1943 елның 23 октябрендә Кырым татарының гүзәл шәхесе дөнья белән саубуллаша. Язмышның талантлы, юньле шәхесләргә ник болай рәхимсез икәнен кем белә?

Тәэминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

Аксыл-сары чәчләре иңнәренә сибелгән, нәфис кенә буй-сынлы шушы кыз баланың күңеле тулы милли моңнарыбызны киләчәккә илтүче икәненә беренче карашка ышанырлык та түгел. Андерсен әкиятләрендәге патша кызларын хәтерләтә ул. Ләкин сәхнәгә чыгып басуга, нәфис матурлыгы ниндидер кырыслык белән өретелгән ауропача туташ чыпчын татар кызына, юк, хан кызына әйләнә дә куя! «Әзифә»не, «Сәхралар»ны тыңлаганда, аның тавышыннан йөзләгән, меңләгән нәни кыңгыраучыклар чыңлавы, тау күкрәгеннән агып чыккан иң моңлы чишмәнең челтерәве агыладыр кебек. Ә «Кара пулат»тан Нәргизә ариясен җырлаганда, бу кадәр хәсрәтле гүзәллекнең ут эчендә калган манарадан күккә ашасына бөтен йөрәгең белән инанасың...

СӘХНӘБЕЗНЕҢ

Татарстанның атказанган артисты Муса Җәлил исемендәге бүләк иясе Илүсә Хуҗина – кайсы сәхнәдә, кайсы илдә генә җырласа да, милләтебезнең рухи куәтен күрсәтә алырлык, дәрәҗәсен күтәрерлек җырчы. Моңлы тавышлы, халкыбыз җырларын йөрәге аша үткәреп суза торган җырчылар авылда, табигатькә якын җирдә туып үсә. Ә менә Илүсә – шәһәр кызы, Чаллыда туган, аннары әти-әнисе Алабугага күченә. Илүсә шунда үсеп буй җиткерә. Әти-әнисе дә – гади эшчеләр, чыгышлары белән авылдан булган чын татар кешеләре. Гаиләдәге ике кыз бала туган телебездә сөйләшеп, шәһәргә гастрольләр белән килгән татар театрларының тамашаларын калдырмый карап үсә. Җәйләрне исә авылда уза – әнисе ягына Сарман районының Карашай-Саклау авылына, әтисе ягына – Алабуга районының Дөм-Дөм авылына кайталар. Исемнәре үк җыр кебек яңгыраган шушы авылларның чишмә суларын эчеп, һавасын сулап үс тә, җырламыйча түз, имеш. Җыр-биюгә әти-әниләре дә һәвәс, кызларының музыкага тартылуын да хуплыйлар. Әле музыка мәктәбенә кергәнче үк, Илүсәгә беренче музыка белемен әнисенең әбисе – дәү әбисе Әнвәрниса бирә: бәләкәй чагында, әниләре эштә вакытта ул оныгына көн саен бер яңа җыр өйрәтә. Баланың вакыты да заяга узмый, күңеле дә байый!.. Кичләрен исә әти-әнисенә өйрәнгән җырларын җырлап, кечкенә генә концерт куя. Әнвәрниса әбисен җырчы үзенең музыкадан беренче остазы дип саный. Аннары – музыка мәктәбе. Укытучылары да җыр күңелле кызчыкка хәерхаһлы булып кына калмый, ә анда татар халык җырларына мәхәббәт тә тәрбияли. Унберенче сыйныфны тәмамлагач, кайсы юлны сайлау хакында гаилә белән киңәшә Хуҗиннар. Әнисе – Алабуга педагогика институтын тәмамлаган татар теле укытучысы, кызын да шул юнәлештә үстермәкче дә бит, Илүсәнең күңеле музыка дөньясына ныграк чакыра. Аңа каршы төшмиләр, тик әтисе кисәтә: шушы юлдан китсәң икән, соңыннан зарланасы түгел, бу синең үзең сайлаган язмыш... Шул чакта кабул ителгән карары өчен беркайчан да үкенми туташ. Хәер, педагогикага киткән булса да, музыка, вокал белән бәйле белгечлек сайлар иде ул.

Шулай итеп, Илүсә Казан музыка көллияте шәкерте була. Дүрт уку елы бик тиз узып китә. Гомумән, барлык яшь башкаручыларга да ул нәкъ менә музыка көллиятенә барырга киңәш итә, чөнки анда укучы белән чын-чынлап шөгыльләнәләр, дип саный ул. Илүсә Клара ханым Хәйретдинова классында укый. Фольклор белгечлеге буенча Венера ханым Гәрәева белем бирә. Көллияттә ул академик вокалда түгел, ә халык музыкасы бүлегендә укый. «Яхшы укытучыга эләгү – отышлы билетка тап булу кебек ул, миңа бу мәсьәләдә бәхет елмайды» – дип көлемсери җырчы. Остазлары турында сөйләгәндә, яшькелт күзләре тагын да җылынып китә. Чыннан да, үз остазыңны табып, аның белән бер уйда булып белем алу җырчының һөнәри формалашуында бик мөһим. Ике укытучысы да үз эшләренә искиткеч бирелгән шәхесләр, һәр шәкертләре белән шулай бирелеп, аның үзенә генә хас талантын чарлау өчен максат куеп эшли. Соңгы курсны тәмамлаганда, кыз академик вокал белән кызыксынып, укуын консерваториядә дәвам итү хыялы белән яна башлый. Әлбәттә, бу карарны кабул итүдә остазы Клара ханымның өлеше зур була. Халык җырларын күңеленә сеңдереп үскән кыз балада ул саклык белән генә академик вокалга да мәхәббәт уята, дөрес репертуар сайларга ярдәм итә. Илүсә консерваториягә кергәч тә, Клара ханым классына туры килә – остаз алыштыру кебек четерекле мизгелләрне кичерергә туры килми аңа. «Клара апа – минем өчен әниемнән кала икенче кеше! Ул мине шулкадәр якын итә, гомумән, барлык шәкертләре өчен дә бертигез борчыла ул! Кайвакыт телевизордан чыгышымны күрә дә ачулана: нигә миңа килмәдең, бу әсәрне икәү әзерләсәк, тагын да яхшырак җырлый аласың бит, ди»... Илүсәдә остазлары хакында тик җылы, матур хисләр генә саклана. Икенче остазы Венера Хәсән кызын ул үзендә халык җырларын башкарырга зур мөмкинлекләр ачты, дип саный. Аның арабыздан китүе Илүсә өчен бик зур югалту була. Остазының ачыклыгы, олы йөрәкле булуы хакында, аны бик сагынуы хакында сөйләгәндә, күзләренә тирән сагыш тула...

Көллияттә алган нигезле белемнәре консерваториядә укыганда бик ярдәм итә. Биш ел опера студиясендәге проектлар, чыгышлар, конкурслар белән үрелеп үтә. Ә Илүсә үзенең һаман да укып туймаганын аңлый: аңа Ауропаның вокал мәктәбе кызык һәм ул, бәхетен сынап карар өчен, Германиягә китәргә була. Кёльн шәһәрендә урнашкан, Җыр һәм бию югары мәктәбе дип аталган университетка керергә җыена. Бирегә Азия, Кытай, Кореядән бик көчле яшьләр килә. Кыз кабул итәрләр дип әллә ни ышанмый да. «Гомумән, беркайчан да беркемнән дә берни көтмим мин. Кечкенәдән үк, төрле бәйгеләргә барганда, артымнан әнием ияреп йөрмәде, сумкамны тотырып бирә иде дә, вәссәлам, яхшы җырлап кайт, кызым, дип озатып кала иде». Монда да бары тик үз көченә, үз талантына гына таянып булганын аңлый ул. 86 кеше арасыннан нибары 6 кешене сайлап алалар. Алман укытучылары күңеленә аның экзотик тембры хуш килә, күрәсең. «Миндә – татар мәдәнияте, ул тавышта гына түгел, калебтә, интеллектта да, алар моны күрде, тойды һәм кызыклы дип тапты», – дип искә ала җырчы. Укырга кабул ителә, ә телне белми диярлек. Дөрес, 9 ел элек мәктәптә алман телен укыганнан нәрсәдер калган, тик кулланылмагач, онытылып беткән. Тиз арада искә төшерергә, өйрәнергә туры килә – остазы Фрау Кунц аны опера студиясенә кастингка җибәрә. Анда исә студентлар бездәге кебек тыйнак кына концерт вариантындагы опералар куймый, ә оркестр белән, костюмнар белән зур масштаблы проектлар чыгара. Кастингка бик теләп тә бармый кыз, ләкин аны рольгә алалар. Шушы проектта катнашу аңа телне тизрәк үзләштерергә

ХАН КЫЗЫ

ярдәм итә, чөнки өйрәнми хәлең юк, кеше белән аралашырга, режиссерны, дирижерны аңларга кирәк. Әсәр үзе алман телендә булу өстенә, матур көйле классик әсәр дә түгел, ә заманча композиторның ни көе, ни моңы юк дигәндәйрәк иҗат җимеше. Укуның беренче елында шушы барлык кыенлыкларны җиңеп чыгарга туры килә. Үз илендә, үз телендә җырлап күнеккән татар кызы өчен бер сынау була бу. Тик ул сынатмый. Укуның икенче елында инде Моцарт операсын куялар, анда Илүсәгә төп рольне үк бирәләр. Берьюлы ике составны әзерлиләр, аннары премьерада кем җырлаячагын сайлыйлар. Бәхет тагын татар кызына елмая. Алманиядә уку елларында төрле илләрдән килгән җырчылар белән аралашу, төрле ил режиссерлары, дирижерлар белән эшләү, әлбәттә, кыйммәтле тәҗрибә була. Төрле проектларга да чакырып торалар. Ләкин күңел дигәне гел Казанга тарта һәм Илүсә үзенең нәкъ менә шунда яшәргә теләвен таный. Аның өчен татарча җырлау мөһим! Европада яшәргә була, башка барлык телләрдә җырларга була, ләкин аның калебе, күңеле өчен татарча җырлау кирәк!

Магистратураны тәмамлаганда, чыгарылыш курсы сольный концерт бирергә тиеш. Анда ул Эльмир Низамовның «Кара пулат» операсыннан Нәргизә ариясен җырлый. Комиссиягә алдан тәрҗемәне тапшырасың. Әсәр аларга бик ошый. Син татарча үзгә хис-тойгылар белән башкарасың, бу аерылып тора, диләр.

Казанга кайткач та, Илүсә Европа белән араларны өзми, төрле проектларга барып җырлавын дәвам итә. Казанда исә Эльмир Низамов белән иҗади дуслыклары дәвам итә. Ун елга сузылган бу бәрәкәтле дуслыкның нәтиҗәсе булып узган ел ахырында «Сихри моңнар» дип аталган уртак альбомнары да чыкты. Анда кергән әсәрләрне хәзер барлык музыкаль платформалардан тыңларга була. Альбомны тәкъдим итү «камерный» рәвештә генә үтте. Әлбәттә, зур залга тамашачы җыеп, концерт рәвешендә дә оештырып булыр иде. Ләкин барысы да финансларга барып терәлә шул... «Гомумән, хәзер чын иҗат белән шөгыльләнү – бик кыйммәтле гамәл. Студия, аранжировкалар яздыру, авторларга түләү... Шуңа күрә дә бу альбомны эшләү озакка сузылды. Бу бер көнлек яисә бер еллык кына да эш түгел. Аның безгә кадере дә зур», – ди җырчы.

Үткән ел аның өчен бик тә тыгыз, вакыйгаларга, кичерешләргә бай булды. Җиде ел элек җырланган «Кара пулат» яңадан сәхнәгә кайтты. Бу – җырчы өчен дә зур вакыйга. Чөнки анда җырлаячагы нибары бер ай калгач мәгълүм булды. Бер айда опера куймыйлар, ул бит җыр гына түгел. Җитмәсә, партияләрне җырлаудан тыш, артистлар бөтен спектакль буена биергә тиеш. Һичнигә карамастан, Илүсә ризалашты һәм яңа состав белән, яңача караш белән операны сәхнәгә күтәрергә тотындылар. Беркайчан да биемәгән җырчыларны бер ай эчендә биергә дә өйрәттеләр. Ничек итеп бер ай эчендә моны башкарып чыкканнардыр, моңа ул хәзер үзе дә аптырый. Күрәсең, туган телебездә зур әсәр иҗат итәргә теләк, ихтыяҗ шулхәтле көчле булгандыр. Май аенда опера биш көн рәттән тамашачыга тәкъдим ителде. Бер җирдә дә, беркайчан да 5 көн премьера куймыйлар. Ә монда бер үк солистлар биш көн буе сәхнәдә яшәде һәм янды... Җәй көне исә спектакльне Болгарда күрсәттеләр. Авторның да, М.Шәймиевнең дә хыялы тормышка ашуы иде бу: сихри кич, кабатланмас мизгелләр... Кара Пулатның үзе янында әсәрне җырлау икеләтә хисләндерә, андагы энергетика! Спектакль көнне күктә тулган ай балкып, кара төнне яктыртты. Болгар кызы Нәргизә-Илүсәнең «Сүндермәгез кайтавазын мин җырлаган җырларның...» дип хәсрәтләнүе хәтер катламнарын уятты, онытылган кайгыларны, онытылган горур чакларны әрнетеп искә төшерде... Дошманнарга, имансызларга баш бирергә теләмичә, милләтемнең утларда янган барлык кызларының тавышы, дәшүе булып кабул ителде ул...

Илүсә бүген рәсми рәвештә Зур Концерт залында солист җырчы булып эшли. Төрле проектларда катнаша, яңа җырлар яздырырга да өлгерә. Барыбызның да хыялы – милли музыка театры хакында фикере белән кызыксынам.

– Бар эстрада, бар опера сәнгате. Тик аларның уртасында бүген чоңгыл, уртасы буш. Шушы ике ярны кушар өчен Музыка театры кирәк! Операны аңлау өчен аны тыңлап тәрбияләнергә кирәк. Элек бит Сәйдәшнең, Җ.Фәйзинең музыкаль спектакльләре гөрләп барган, аларны бүген дә сәхнәгә куярлык. Яшь композиторларыбыз да үсеп җитте: шушы көннәрдә Зур концерт залында Миләүшә Хәйруллинаның «Кави-Сәрвәр» операсының премерасы булды, искиткеч әсәр! Эльмир Низамовның «Алтын Казан» мюзиклы, «Кара пулат» операсы бар. Бик талантлы композитор, дирижер Ильяс Камал әсәрләре бар. Мондый талант ияләре булганда, безнең халыкның Музыка театрына ихтыяҗы бик зур. Ул театрга тамашачы да бик кызыксынып килер иде. Гомумән, милли репертуарыбыз Европа тамашачысына да кызык булыр иде, дип уйлыйм. Чөнки анда яңа сулышка ихтыяҗ зур. Европа илләрендә вокалистларның төрле конкурсларында катнашырга туры килде, һәрвакыт татар җырларын да башкара идем, чөнки үземнең мәдәни кодымны җиткерергә телим. Верди, Моцарт, Шуман әсәрләре белән беррәттән татар җыры да яңгырый. Нихәтле яхшы башкарсам да, тамашачы Моцарт әсәре турындагы фикерен әйтергә янына килми, ә «Бөдрә тал», «Әллүки»ләрне җырлап чыккач, ничек җанлану сизелә! «Бу нинди тел? Тәрҗемәсе ничек?» – дип кызыксыналар, хисләнәләр. Шушы тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: татар операсы Ауропада бик зур уңышка ирешер иде. «Кара пулат»мы, «Алтынчәч»ме – алар үзенчәлекле, аларның үз юлы бар. Бүген чын талант ияләре дөнья күләмендә дә күп түгел. Шундый берәмтекле талантларның Казаныбызда булуы – зур бәхет, республикабыз өчен зур казаныш...

Эльмира СИРАҖИ.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Рәссамнар берлегенең Санкт-Петербург бүлеге әгъзасы, югары һөнәри гыйлемнәргә ия скульпторыбыз Винера Абдуллина – заманыбызның иң актив татар иҗатчыларыннан. Ул 1965 елда Ленинградта туган һәм бүген дә төньяк башкалада яшәп иҗат итә.

АРУ БЕЛМӘС

Винераның әтисе Зәви Мәхмүтов чыгышы белән Башкортстанның Борай районы Шабай авылыннан. Әнисе Зәкия исә Горький өлкәсенең Сергач районы Семёновка авылында туып үскән. Алар Ленинградка эш эзләп килгәч танышканнар. «Семёновкада мин 5 яшемә кадәр әбием Бәдриҗан тәрбиясендә дә үстем. Ә минә дәү әтиемне күрергә насыйп булмады, ул Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган. Мин анда авыл рухын күзәттем, әбиләрнең ураза тотуларын, намаз укуларын да күрдем, татарча гына сөйләштем. Хәзер дә ана телемне беләм. Әти-әнием мине калага алып китеп бакчага биргәч, анда балалар мине күмәкләп рус теленә өйрәтте. Апам Наилә иҗат белән бәйле һөнәр сайламады, әмма ул да матурлык өлкәсендә хезмәт куя – чәчтараш. Ә мин балачактан ук бик фантазияле идем, күктәге болытларда да төрле образлар күрдем, комнан сарайлар төзедем һәм төсле каләмнәр, буяулар белән рәсемнәр ясадым, пластилиннан да әллә нәрсәләр әвәләдем...» – дип искә алды әңгәмәдәшем.

Винера Абдуллинаның иҗатка таба юлы әзлекле: башта ул алты сыйныф гадәти мәктәптә укыган, балалар сынлы сәнгать мәктәбендә 4 ел белем алган, аннары Сынлы сәнгать академиясе карамагындагы Б.В.Иогансон исемендәге урта сәнгать мәктәбенә кучкән, аны тәмамлагач, В.А.Серов исемендәге сынлы сәнгать-педагогика училищесын бетергән, И.Е.Репин исемендәге дәүләт академик сәнгать институтының скульптура факультетында белем алган һәм шушы югары уку йортының аспирантурасын да уңышлы тәмамлаган.

«...Рәсемнәремне папкага салып, Б.В.Иогансон исемендәге мәктәпкә консультациягә юнәлдем, кулыма агачтан уелган баһадир башын да тоттым. Кулларым буш булмасын әле, дидем үземчә. Андагы хөрмәтле укытучыларның рәсемнәремне карарга вакыт табуларын көтеп утырам. Сәләтле балалар каян гына килмәгәннәр, бик күбәүләр. Шулчак бер әфәнде яныма килде, кулымдагы агач сынчык белән кызыксынып: «Киңәш көтәсеңме? Үзең уйдыңмы?» – дип сорашты. «Әйе!» – мин әйтәм. Бу укытучы миңа шундук сынчылык юнәлешендә укырга тәкъдим итте. Рәссам булырга теләвемне шундук истән чыгардым һәм сынчылыкка укырга ризалаштым. Класста нибары 8 бала укыдык: 7 малай һәм мин. Аннары, училищедагы укуымны тәмамлагач, татар ир-егете белән тормыш кордым. Бердәнбер улыбыз Ринат туды. Улыма 10 ай тулгач, И.Е.Репин исемендәге институтка укырга кердем, аны тәмамлагач, аспирантурага юнәлдем... Миңа эш тәкъдим иткәндә: «Рус музеена барасыңмы яки академия остаханәсендә каласыңмы?» – дип сорадылар. Мин, тырыш иҗатчы буларак, музейны сайламадым», – ди Винера ханым.

Ул менә инде 20 ел дәвамында Россия Сынлы сәнгать академиясенең гипс эшләнмәләр ясау остаханәсе җитәкчесе булып эшли. Әлеге остаханәгә нинди генә уку йортлары, кемнәр генә мөрәҗәгать итми... Нигездә, анда сәнгати юнәлештәге уку йортлары өчен кирәкле әсбаплар – гипс сыннарны һәм анатомия рәсем дәресләре өчен кирәкле сынчыкларны җитештерәләр. 2001 елдан башлап, Винера Зәви кызы үз әсәрләре белән төрле дәрәҗәдәге гомуми күргәзмәләрдә дә катнашып килә. Үз шәхси күргәзмәләрен дә бик теләп ача. Ул кәче формадан алып монументаль эшләргә кадәр берничә дистә скульптура композицияләре иҗат иткән инде.

– Винера ханым, «сынчыларга һәрчак эш табылып кына тора, алар кесәләренә дә акчаны миллионлап кына сала», – дияргә яраталар. Сезнең һөнәр җиңелләрдән түгел бит, аның да үз авырлыклары бар...

– Болай фикер йөртүчеләр күп. Алар безнең һөнәрне җиңел дип күзаллый. Сын ясау өчен мин башта, билгеле, эскиз әзерлим. Шуннан соң каркас эшләп, үзле балчыктан (яки пластилиннан) сын әвәлим. Бу модель тимер пластинкалар белән ике: алгы һәм арткы кисәкләргә бүленә. Шуннан соң гипс форма ясыйм, аны нитролак һәм махсус май белән белән буягач, әлеге формага гипс агызам. Аннары форманы ватып, аннан гипс коелманы алам, аның җөйләрен җуям, берәр дефект булса, аларын да бетерәм.

Әгәр дә инде гипс модельдән бронза сын коярга кирәк икән, әлеге әзер гипс модельдән виксинт форма кучерелә. Виксинт формага сыек балавыз тутырыла. Виксинт форманы алгач, сынның балавыз моделе барлыкка килә. Аны да яхшылап эшкәртергә кирәк. Шуннан соң балавыз модельгә махсус җайланмалар (һава чыгаргычлар һәм литник) беркетелә. Әлеге конструкция керамик катнашмага батырыла. Аннан соң аны кайнар мичкә урнаштырып, керамик формадан балавызны эретеп чыгаралар. Керамик формага бронза агызыла. Аннары гына керамик форманы ватам һәм аның эчендәге бронза сынны барлыйм. Әзер сын тагы бер кат яхшыртыла һәм кирәкле төс килеп чыкканчы махсус кислоталар белән эшкәртелә. Күрәсезме, хезмәтебез никадәр катлаулы да, четерекле дә. Рәссам А.Бенуа иҗат юлы башында сынчы булырга теләгән, әмма бераздан бу өлкәнең күпме вакыт, чыгым таләп итүен аңлаган һәм киндерләргә сурәт ясауны үзе өчен җиңелрәк булыр дип тапкан. Аннары сын бит мохиткә туры килергә тиеш... Сыннарымны уя башлаганчы ук, аларны шул мохиттә «рухи эш башкаручы» сыннар итеп күзаллыйм.

– Күп кенә талантлы шәхесләрнең бюстларын иҗат иткәнсез. Мондыйларны ясаганда нинди кыенлыклар туа?

– Башта ул шәхеснең бар мәгълүм фотоларын карап чыгам. Кеше, гадәттә, аларның барсында да төрле була... Адәм баласы гомер барышында сизелерлек үзгәрә бит, ә шулай да иң мөһим күренгән фотоны сайлап алырга кирәк. Әйтик, М.Җәлилнең Бөек Ватан сугышы вакытында, хәрби киемнән, тоткынлыкка кадәр төшкән фотосына тукталдым. Илһам Шакиров бюсты өчен дә күп фотолар барладым. Аның йөз чалымнары да һәрчак диярлек үзгәрә барган. Җырчының бюсты да шулкадәр авырлык белән ясалды. Белүемчә, тормышында михнәтле көннәр бихисап булган. Ахры, барсы да ниндидер үзара энергетик бәйләнештә. Шуны искәртәм: авыр язмышлы кешенең сыны да авырлык белән ясала.

– Бәлкем, мөселманнар мондый сыннар ясауга каршыдыр? Илһам Шакиров әңгәмәләрендә, миңа һәйкәлләр куелса, яхшы булыр иде дип әйтмәгән бит, нигә кирәк соң инде алар, дигән...

– Нәрсә дияргә дә белмим... Эш шәхеснең вафатыннан соң да булмаска мөмкин. Әйтик, менә Мәскәү татарлары, талантлы дирижёрыбыз Фуат Мансуровның юбилее уңаеннан, аның бронза сынын ясарга тәкъдим иткән иде... Ярты еллык эшем авырлык белән барды. Мин иҗат объектының тормыш юлларын өйрәнеп чыгам, сәләтләренә сокланам! Фуат Шакир улы да нинди гомер кичкән зыялы! Альпинизм белән дә җитди шөгыльләнгән, тимераякта шуу буенча спорт мастеры да, шахматчы да, югары математиканы да укыткан, берничә чит телдә шулкадәр шәп сөйләшкән. Ә менә сынын ничек кенә ясасам да, канәгатьлек хисе кичерә алмадым. Шулай да күп



СЫНЧЫ ХАНЫМ

тырышлык куеп иҗат ителгән сынны ошаттылар.

– Сезнең иҗатта «Балет» сериягез бар, Р.Нуриев сынын уюны да максат итеп куйгансыз. Әлеге темага ничек алындыгыз?

– Мин, чыннан да, үзебездәге опера һәм балет театрына барып, андагы балет артистларының репетицияләрен күзәтеп утыргаладым. Менә алар эшләп тә карыйлар, ичмасам! Үз-үзләрен аямыйча, сәгатьләр буе репетицияләр ясаучы балет артистларының хезмәте бик авыр икән. Балериналарны хәрәкәттә тасвирладым, чөнки бии башласалар, алардан күз алып булмый. Сокландыргыч сәнгать! Araларында татар милләтле прима-балериналар да бар иде, әлбәттә. Ләкин җитди эшләр уяр өчен, балет театрына 2-3 ел рәттән йөрергә кирәк. Аларны бит курчаклар кебек итеп кенә ясап булмый.

В.Абдуллинаның иң беренче хезмәте – 1991 елда Н.К.Рерих исемендәге сәнгать училищесы янәшәсендә урнаштырылган сәнгати ваза. Студент чакта берничә яшьтәше белән бәйгедә җиңеп чыккач, аларга үз бетон эшләрен шушы территориядә урнаштырырга рөхсәт иткән булганнар. 2004 елда сынчы граф С.Ю.Витте бюстын Санкт-Петербургның дәүләт политехник университеты өчен ясаган. 2006 елда исә ул Махачкала каласы өчен Петр I бюстын иҗат иткән, шул елда ук аның тарихи шәхесләр сериясеннән гыйбарәт галереясы Франциянең Нанси каласында узган 72 нче Халыкара күргәзмәдә экспозицияләнгән. В.Абдуллина Россия мәдәниятен танытуга зур өлеш кертккәне өчен РФның Страсбургтагы Генераль илчелеге Почет грамотасына да ия.

«Шуннан соң инде татар шәхесләренең сыннарын да иҗат итә башладым. Күптәннән

ошаткан якты образ – Сөембикә образына алындым. Аны мөләем кыяфәтле итеп күрсәтеп бирергә омтылдым. Гомумән, иҗатымда хатын-кыз образлары җитәрлек дип саныйм. 2015 елны бронзадан коелып, Казан паркына урнаштырылган «Әбекәй» сыны да шуларның берсе», – ди әңгәмәдәшем (Без аның белән Лядской бакчасында утырабыз. Әлеге сын янына тукталучылар, фотога төшүчеләр шактый булуын күзәтәбез. Иҗатчы бу күренешкә дә шат!)

Скульптор 2011 елда Россиядә татар телендә беренче басма – «Нур» газетасына нигез салучы булган, калада беренче мәчет төзетүгә өлеш керткән А.Баязитов бюстын иҗат иткән, ул Санкт-Петербург дәүләт университетының көнчыгыш факультеты скверына урнаштырылган.

2012 елда Ленинград өлкәсенең Тосно каласында сынчы тарафыннан ясалган М.Җәлил бюсты да ачылды. 2015 елда Кама Тамагы үзәгенә – драматург Т.Миңнулин бюсты, Любаньдагы «Геройлар аллеясы»на Бөек Ватан сугышы афәтендә күкрәге белән дошман амбразурасын каплаган батыр Т.Эрдҗигитов бюсты да, Санкт-Петербург дәүләт университеты территориясенә тарихчы-этнолог Л.Гумилевка багышланган хезмәте тә куелды. 2015 елда Винера Зәви кызы Бөтендөнья татар конгрессының иң югары бүләге – «Татар халкы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнде.

2016 елда Казахстанның Семей каласына аның тагы бер хезмәте – Тукай бюсты куелды. Шул ук елның 2 апрелендә Төньяк флотның Щ-423 су асты көймәсе командиры Измаил Зәйдуллинның бюсты Санкт-Петербургның Үзәк Хәрби-Диңгез музеена бүләк ителде. 2020 елның көзендә Илһам Шакировның туган авылы Якты Юлда даһи җырчыбызның бюсты урын алды.

«Татар мохитендә үскәнгә күрә, кече сынчыклар сериясендәге образларымның барсы да диярлек әлеге еллардагы истәлекләрем, гади халык тормышына карата ихтирамым белән бәйле, алар, нигездә, шул хатирәләрем аша тудылар: абыстай, колхозчы, күрше, көтүче, кәләш, тракторчы, ана образлары... Минем «Сабантуй», «Балачак», «Чегәннәр», «Илһам», «Ислам мотивлары» һ.б. серияләрем бар. Сынчыкларны өслекләргә япмалар ягып кына ясыйм, шомартып бетермим, ул очракта алар җанлырак та, әле һаман иҗади процесс дәвамында кебек булып та кабул ителә. Кыскасы, иҗат ысулым классик түгел, бераз импрессионизм ысулына тартым», – дип тә искәртте ул. Бүгенге көндә сынчы татар сәнгать эшлеклеләре бюстларын иҗат итү белән мәшгуль. «Алдагы көннәрдә, иншаллаһ, С. Сәйдәшев сынына алынacакмын», – ди оста.

В.Абдуллинаның 1999, 2000, 2002 елларда Санкт-Петербургның «Петербург музалары» дип аталган грант бәйгесендә җиңеп чыгуын да искә алу урынлы.

Аның реализм мәктәбе традицияләрен дәвам иттерүче күпкырлы иҗатын барлаганда, батырлык темасына игътибар бирелүен күрербез. Әйтик, 2007 елда, Үзәк федераль округының Дәүләт резервлары буенча Федераль агентлык янәшәсенә стела-рельеф куелды. Ул Бөек Ватан сугышы елларында күп батырлыклар кылган Росрезерв хезмәткәрләренә багышланган. 2010 елда Иваново каласында Советлар Союзы Герое, армия генералы В.Маргеловка, сугышчы-десантчыларга һәм спецназга багышланган хезмәт, Л.М.Мациевич музей-скверындагы Россиянең беренче авиаторларына багышланган бюстлар, Псковның 6 нчы һава-десант дивизиясе десантчыларына, РФ Геройларына багышланган сыннар һ.б. да – В. Абдуллина иҗаты.

Винера Зәви кызы китап графикасын да үз итә. Мәсәлән, «Мөхәммәд Пәйгамбәр – бөек кеше, һәрчак һәм бүген» китабы бизәлеше өчен ул матур чәчәкләр сурәтләгән. «Әбием Бәдриҗан Ленинградка килгәч, мәчеткә барганда, мине дә үзе белән иярттеп бара иде. Андагы гарәпчә язмаларны беренче тапкыр күрү белән аларны укып чыгасым килде. Болар бизәкләр түгел, чыннан да хәреф микәнни дип тә уйладым әле. Аллаһ Тәгалә ихлас теләгемне кабул иткәндер, чөнки VIII сыйныфта укыганда мәчеткә кердем дә үтенечемне әйттем: «Гарәпчә укырга-язарга өйрәнергә телим!» Андагы мөселман кешесе миңа ике атна гына дип үзлектән өйрәнү дәреслеген бирде. Шул вакыт эчендә гарәпчә укырга-язарга өйрәндем. Гарәп теле минем өчен бик җиңел тел тоелды. Аннары ике ел буе Мөхлисә Зарипова алып барган курсларда укыдым. Тора-бара үз шәмаилләремне дә иҗат иттем. Аларда Аллаһ Тәгаләнең 99 күркәм исемнәре язылды...» – диде сынчы.

РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе Дамир Мөхетдинов һәм аның беренче урынбасары Равил Сәйфетдинов сынчыбызга татар мәгърифәтчеләре бюстларын ясарга тәкъдим иткән. Шулай итеп, 2016 елда Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, казыя М. Бубый, М.Бигиев һәм Р.Фәхретдинов бюстлары гаять дәрәҗәдә төгәллектә гипстан ясалган. Аларны Винера ханым Диния нәзарәтенә бүләк иткән инде. Бөтендөнья татар конгрессының съездында делегат буларак катнашкан иҗатчыбыз узган җәйдә дә Казанга буш кул белән килмәде. Скульптор җитди иҗат җимешен – Муса Җәлилнең яңа бюстын тәкъдим итте. Ул тиздән Якутиядә урнаштырылачак. «Мондый съездлар, конференцияләр Татарстаннан читтә яшәүчеләргә рухи куәт, илһам өсти! – диде Винера Зәви кызы әңгәмәбез ахырында. – Бар ватанпәрвәрләрне бергә җыйган мондый бәйрәмчә зур чаралардан соң Санкт-Петербурга әйләнеп кайткач ук, үз мәдәниятебезгә кагылышлы иҗади эшләргә генә алынасы килә!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Л.НИКОЛАШКИНА фотолары файдаланылды

Атананың сәяси мизгелләре

«ТЫНЫЧЛЫК» ӨЯНӘГЕ

Соңгы вакытларда «тынычлык» төшенчәсе белән бәйле шаукым кинәт көчәеп китте һәм узган атнада мәгълүмат чараларында инде ул чын өянәк дәрәҗәсенә дә җитте кебек. Һәрхәлдә, яңалыкларда тынычлык акцияләре турындагы хәбәрне сәгать саен тәүлек буе кабатлап тордылар. Әлбәттә, сүз иң элек Европаның кайбер илләрендә (бигрәк тә Алманиядә) тынычлыкны яклап үткәрелгән протест акцияләре турында бара. Салкын сугыш елларында андый акцияләрдә төп лозунг, гадәттә, «Вьетнамнан кулларыгызны алыгыз!» шәкелендә була иде. Бүген исә сүз Украинадагы хәлләр турында баруын аңлаганга, үзем башта бераз шөбһәгә дә төшкән идем. Бактың исә, анда катнашучылар тынычлыкны бу илгә корал белән ярдәмне туктатып, Россия белән сөйләшүләр үткәрү аша урнаштырмакчылар икән. Россиянең БМО дагы даими вәкиле В.Небензяның КШ утырышында ясаган чыгышын тыңлаганнар, күрәсең. Ә ул анда әгәр Украинада хәрби хәрәкәтләрне без туктатсак, анда рус теллеләрне эзәрлекләү башланачак, әгәр дә Украина туктатса, ул тыныч яшәү мөмкинлеге алачак, дип сөйләгән иде.

Ә узган атнада тынычлык урнаштыру буенча төрле тәкъдимнәр күп булды. Алар арасында киң яңгырашны бигрәк тә «Кытай планы» алды. Ул шактый озак әзерләнде кебек. Кытай сәясәте демиургы Ван И аның белән якларны әле Мюнхен конференциясендә үк өлешчә таныштырган иде. Киев әлеге планны кире какты. Чөнки анда Кытайның үзе өчен дә бик мөһим булган территориаль бөтенлек принцибы чагылыш тапмаган. Дөрес, Украина президенты В.Зеленский үзендә Кытай лидеры Си Цзиньпин белән очрашып сөйләшү теләге барлыкка килүе турында да белдерде. Әмма әлеге план АКШ, ЕС һәм НАТО да оптимизм уятмады кебек. Әйе, аны өйрәнергә вәгъдә иттеләр. Әмма, гомумән алганда, дөнья җәмәгатьчелегендә ул төп проблемага Кытайның карашы буларак кына кабул ителде.

Узган атнада Алмания, Британия һәм Франциянең, Украина белән ниндидер оборона пакты төзеп, аның Мәскәү белән тыныч сөйләшүләр башлавына ярдәм итәргә җыенулары турында да хәбәрләр булды. А.Лукашенко хәтта Пекинга да юл тотты. Күренә ки, тынычлык темасы отыры актуальләшә бара. Икенче яктан, болар һәммәсе дә Көнбатыш һәм Россиянең, капма-каршы яктан, әмма уртак мәкатларда эш итүе турында сөйли. Инде атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. Молдова Мәскәүдән үз хәрбиләрен Приднестровьедан чыгаруын таләп итте. Мәскәүнең, Украинада Приднестровьега каршы хәрби провокация әзерләнә, дигән хәбәрен Кишиневта да, Киевтә дә кире кактылар. Украинада үткәрелә торган махсус хәрби операциянең берьеллыгы уңаеннан АКШ, Бөекбритания, ЕС, Канада, Япония һәм кайбер башка илләр Россиягә каршы өстәмә санкцияләр кертте. Алмания канцлеры О.Шольц Россия Президенты В.Путин белән диалогка юлны алга таба да эзләячәге турында әйткән. Бөтендөнья банкы Украинага грант рәвешендә 2,5 миллиард доллар бүлеп биргән. АКШ 10 марттан Россиядән чыгарыла торган алюминийга 200% күләмендә пошлина кертә.

Фоат УРАЗАЙ.

Сәүдәгәр

Элиты почти нет. Великаны ушли.

Светлана АЛЕКСИЕВИЧ – белорус язучысы, Нобель премиясе лауреаты



Гайнелхәят, Шәмсекамәр.

Татар хатын-кызлары хәрәкәтен өйрәнгәндә, нинди генә язмышларга юлыкмыйсың да, кемнәргә генә сокланмыйсың. Нәкъ җырдагыча:

Кемнәрең бар, кемне уйлыйсың,
Кемнәрең сагындыра...

Әйе, тормыш юлларын өйрәнгәндә, кылган гамәлләренә сокланган затлы, зыялы хатын-кызларыбызны сагынам. Үзләрен күреп белмәсәм дә сагынам. Күңелемнән алар янәшәсенә үземне, замандашларымны куеп карыйм, тик... туры килмибез. Юк, XIX-XX гасыр алиһәләре бөеклегенә җитеп булмый. Бу аерманы күбебез аңлап җиткерә алмыйбыз әле. Ни кызганыч, аларның күбесе тарихыбызга кереп, тиешле урыннарын ала алмаса да, кайберләре «безне дә онытмагыз» – дигән кебек һич көтмәгәндә үзләрен белгертеп куя. Баишевлар нәселендәге кызлар белән дә шулай булды.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында эшләгән чакта Мәскәүдән килгән тарихчы галимебез Шамил Фатих улы Мөхәммәдьяров белән сөйләшеп алырга мөмкин булган иде.

– Шамил ага, әтиегезне хөрмәт белән искә алабыз, тормыш юлын бераз беләбез дип уйлыйбыз, ә әниегез кем булган? – дип сорадым мин аннан.

– Әниемнең кыз фамилиясе Баишева, ул атаклы Баишевлар нәселеннән, Өммегөлсем исемле иде. Ул да, тагын биш кыз туганы да заманында югары белем ала алган, тормышларында яхшысын да, яманын да күргән кешеләр – диде ул.

Шул урында сүз өзелде, башка сөйләшә алмадык. Ә күңелем кубып, җилкенеп калды. Чөнки 2003 елда басылып чыккан «Ступени образования до Сорбонны» дигән китабымда Октябрьгә кадәр рус кызлары өчен ачылган төрле-төрле уку йортларында белем алган Баишева фамилиясендә 6 кыз искә алына. Эзли торгач, кайберләре хакында мәгълүматлар таптым. Тормыш юллары гыйбрәтле тоелгач, укучыларга да тәкъдим иттем, чөнки мәгърифәтчелек тарихында якты эзләре бар.

Пензада яшәгән сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Баишев гаиләсендә алты кыз – Гайнелхәят, Өммегөлсем, Шәмсекамәр, Мәрьям, Гөләндәм һәм Зәйнәб исемле кызлар үсә. Мөхәммәтҗан ага кызларының язмышлары чит җирләр, ягъни Азәрбайҗан, Төркестан, Казан губернасы белән бәйләнер дип уйлагандырмы, юктырмы – анысы билгесез. Әмма кызлары ничек тә гыйлем-мәгърифәт иияләре булсын, дип зур тырышлык куйган ул игелекле җан.

Сүзне Гайнелхәяттән башлыйк. 1905 елда Пенза гимназиясен алтын медальгә тәмамлап, Петербургта хатын-кызлар өчен ачылган Югары педагогия курсларына (институт программасы белән университет галимнәре укыткан уку йорты) укырга керә бу кыз бала. Бу вакытта биредә Казаннан килгән татар кызлары Әхмәрова (ире буенча Дәүләткилдеева) Маһинпәрвәз һәм Суфия Коләхмәтова да укый. Алар таныш булмагандыр дип уйларга һич нигез юк. Курсларны тәмамлагач, Гайнелхәят Пулководагы сәнгать мәктәбендә эшли башлый. Кыз баласының уңышларына сөенгән Мөхәммәтҗан ага куанычыннан корбан чалырга була, әмма бармагына ялгыш кына пычак тиеп китә. Киселгән урынга ниндидер үлән ябып караса да, файдасы булмый. Бармакка инфекция керү сәбәпле бик тиз генә үлеп тә китә.

Әтисенең шундый вакытсыз үлеме Гайнелхәятнең тормышына да кискен үзгәрешләр кертә. Ул – гаиләдә иң өлкән бала, төрле уку йортларында, төрле шәһәрләрдә укып йөрүче сеңелләре өчен дә үзен җаваплы сизә. Әнисе Казан шәһәренә күчеп яши башлый. Бәлки, башка сәбәп тә булгандыр. Шулвакыт Азәрбайҗанның Ганҗә шәһәрендәге кызлар мәктәбенә яхшы хезмәт хакы белән чакыру килә аңа. Гайнелхәят риза була һәм бу җыелы якка килүенә һич үкенми.

Тарихи мәгълүматларга караганда, бу чорда Азәрбайҗанда татар гаиләләре күп була. Күбесе нефть чыгару, балык тоту эшендә булса да, татарның гомер-гомергә мәгарифкә булган мәхәббәте аларны тирә-якта яшәүчеләрдән аерып торган. Яшәгән һәрбер урында татар мәктәпләре ачылган, һәрберсе баласын укытырга тырышкан. Яхшы, тырышып эшләгәч, бәлки ул кадәр көчле мохтаҗлык та кичермәгәннәрдер, тормышлары иркенрәк булгандыр дияргә дә җирлек бар. XX гасыр башында ук бу гаиләләрдә ислам хорафатлары кими башлап, татарларның кыз балалары да үзләренең фикер хөрлеге, яңа тормышка омтылышлары белән башкаларга үрнәк булган. Укымышлы, эш сөючән, тыйнак, күркәм ана булырдай татар кызларын азәрбайҗан егетләре үзләренә алырга тырышулары һич тә гаҗәп түгел. Шуңа күрә Азәрбайҗанның зыялы егет Нәсиб бәй Усуббәев (Насиб бәк Юсуфбәйли) тә Гайнелхәятне бер күрүдә ошатып, тормышта мәңге бергә булырлык яр итеп сайлый. Алар өйләнешә, әмма бәхетләре генә озакка бармый.

Мәгълүм булганча, Октябрьдән соң Азәрбайҗанда да төрле-төрле үзгәрешләр куба. Азатлыкка омтылган халык үз идарәсен төзи. Тик Россия хөкүмәте моңа юл куймый. Азатлык хәрәкәте җитәкчеләренең күбесе юк ителә, Азәрбайҗан хөкүмәтенең мәгариф министры Нәсиб бәй Усуббәев тә атып үтерелә. Гайнелхәятне кайгылы чагында ялгыз калдырмаска теләп, янына кайбер сеңелләре килеп яши башлый.

Азәрбайҗан Совет республикасы төзелгәч, югары белемле Гайнелхәятне Бакуга чакыралар. Чөнки белемле кадрлар кайда да җитешми, аларга кытлык заман. Ул Мәгариф комиссариатында инспектор вазыйфаларын башкара, бер ук вакытта кызлар гимназиясендә математика фәнен укыта.

Соңрак аның педагогик һәм фәнни эшчәнлеге Баку университеты белән бәйле. Анда ул эшчеләр факультетын (рабфакны) оештыручы, аның җитәкчесе, югары математика кафедрасы доценты булып хезмәт итә. Хезмәттәшләре арасында үзенең белеме, югары әхлагы һәм искиткеч акылы, сәләте белән зур хөрмәт казана. Тик кайгы ялгыз йөрми, кешегә бер килсә, тиз генә җибәрер димә, озакламый Гәйнелхәят бердәнбер кызын да җир куенына сала...

Кайгы хәсрәтләреннән, ялгызлыгыннан алҗып, ул Ташкентта табибә булып эшләгән сеңлесе Зәйнәб янына күчеп яши башлый, бераз хәлен җиңеләйтүгә өметләнә. Финанс-экономика институтына эшкә урнаша. Тик кызының кабере, Усуббәев белән бергә узган яшьлеге, Бакуның истәлекле кадерле урыннары үзенә тарткандыр, 1944 елда ул яңадан Бакуга күчә. Монда кайткач, шөкер, педагогика институтына үзе яраткан педагоглык эшенә урнаша алган, студентларга әлеге шул югары математика фәнен укыта башлаган. Тик «халык дошманы» хатынының югары белеме, эш тәҗрибәсе, осталыгы күпләрнең көнчелегенә сәбәп була. Аның өстеннән әләкләр язу күбәя, аны эштән чыгаралар. Моның өстенә, вакытлы матбугатта аңа янаган мәкаләләр күренә, шундыйларның берсе «Баку эшчесе» дигән татар газетасында басыла. Анда Әбүбәкиров атлы мескен җан «Аларны фаш итәргә

Баишев кызлары

● Гөләндәм.

кирәк, нишләп аның сеңлесе, ягъни Гөләндәм Баишева да мединститут тә-

● Шәмсекамәр укучылары белән.

мамлагач, шул ук институтта эшләргә калдырылган. Наркомсобес үз аралары чистартырга тиеш» дигән өндәү белән чыга. («Баку эшчесе», 18 ноябрь, 1937 ел).

Мондый вәзгыятьтә Гайнелхәят элек үзендә укыган укучысы Берияне искә төшергәндер дип уйлыйм. Ул, чыннан да дөреслек эзләп, Мәскәүгә барган, тик юкка. Үзе өметләнгән дөреслекне таба алмаган ул. Аптырагач, Казанга килә. Биредә аның табибә сеңлесе Өммегөлсем яши. Аның ире Фатих Гариф улы Мөхәммәдъяров – Татарстанның беренче сәламәтлек саклау министры. Тик үзе дә Солтангалиевчелектә гаепләнеп, Мәскәүнең Бутырка төрмәсендә утырып чыккан. Бу вакытта Казаннан читкәрәк китеп яшәргә мәҗбүр булган (Шамил абый сөйләгәннән).

Татарстанның мәгариф министры Гайнелхәятне Мамадыш районында укытучы итеп эшкә урнаштыра алган. Пенсия ала башларга да ярдәм иткән. 22 ел педагогик стажы булган, Петербургта укып белем алган укытучыга У.Т. Кантюков шулай ярдәм итә алган. Сүзебез аның рухына дога булып барсын.

Мамадыштан Гайнелхәят янә Ташкентка күчеп китә. Әмма бер җирдә дә җанына тынычлык таба алмый. 1952 елда гүзәл яшьлеге, бәхетле еллары узган, сөекле ире, бердәнбер кызының каберләре урнашкан Баку каласына әйләнеп кайта. Әмма гомере чикләнгән булган икән. Шулай итеп татар халкының талантлы кызы, мактаулы хезмәтләре белән азәрбайҗан халкының да хөрмәтен казанган, үз баласына әйләнгән Гайнелхәят Баишева 1955 елда бакыйлыкка күчә.

«Татарстанда яшәгән булса» дип уйлыйм да, куркып китәм. Никадәр талантлы кызларыбыз юк ителде бит ул елларда.

Сүз башында Мөхәммәтҗан гаиләсендә алты кыз булганын әйтеп үткән идек. Кайберләрен искә алыйк. Бүген алар исән түгел, тик дәвамчылары – балалары бар. Шулар Баишевлар данына тап төшермәсен.

Гайнелхәят белән Шәмсекамәр – педагоглар. Гайнелхәят хакында аз гына мәгълүмат булды кебек. Шәмсекамәр математиканы төптән белүе, яратып укытуы өстенә, Көнбатыш һәм Шәрык мәдәнияте өлкәсендә яхшы мәгълүматлы булуы белән сокландырган. Коллегалары аны «аяклы энциклопедия» дип йөрткән.

Гөләндәм, Зәйнәб, Мәрьям, Өммегөлсем – барысы да табибә. Кызларның мәдрәсәдән соң, рус кызлары өчен генә ачылган гимназияләрдә укып, университетларга имтиханнар тотып керә алуларына сокланмый мөмкин түгел. Үз телләрен бервакытта да онытмыйча, татар булып яшәгәннәр, барысы да җәмәгать эшләрендә катнашып, татар дөньясы эчендә кайнаган. Аларга карап сокланганнар, аларны үзләренә хатынлыкка алуны төрки дөнья егетләре бәхет итеп санаган. Өйрәнергә иде кызларыбызның тормыш юлларын. Әле дөньяга чыгуны көтеп яткан мактаулы җаннарыбыз күпме?!

Тәминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

4 март (шимбә). ***Шәгъбән аеның 12нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 14.03 сәгатьтә калка, 7.04 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 10.53 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Глицеринлы лимон

Ютәлдән иң нәтиҗәле чараларның берсе бу. Лимонны (кабыгы белән) суга салып, сүрән утта 5 минут пешерәләр. Урталай кисеп, стаканга согын сыгалар. 2 аш кашыгы глицерин кушып, бик әйбәтләп болгаталар, стакан тулганчы сыек бал өстиләр. Көнгә 3 тапкыр (ашар алдыннан) һәм төнгелеккә 2 шәр чәй кашыгы кабалар.

5 март (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 13нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 15.21 сәгатьтә калка, 7.19 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 10.58 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Суганлы шикәр ширбәте

Чиста табаны сүрән утта җылытып, шуңа 2 аш кашыгы шикәр салалар да, гел болгатып торып, эретәләр. Көрәнсу төскә кергәч, уттан алып, 1 стакан кайнар су өстиләр. Болгатып, суыталар, ярты лимон согы, 1 баш суган согы кушалар. Ярты сәгать саен 1әр йотым эчеп торсаң, мондый ширбәт ютәлне бик тиз баса. Балага эчертергә кирәк булса, суган суын кушмасаң да була.

6 март (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 14нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 16.35 сәгатьтә калка, 7.23 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.02 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бирәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Эвкалипт төнәтмәсе

Салкын тиюдән саклану өчен, тамакны көн саен эвкалипт төнәтмәсе белән чайкау файдалы. Моның өчен 1 аш кашыгы яфракны 1 стакан суда төнәтәләр. Яисә 1 аш кашыгы ромашка, 2 чәй кашыгы бөтнек, 1 чәй кашыгы тырнак гөл чәчәген яки нарат бөресен 1 стакан кайнар суда 20 минут пешерәләр дә, шуны сөзеп, 1 аш кашыгын ярты стакан җылы суга кушып, тамакны чайкыйлар.

7 март (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 15нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 17.57 сәгатьтә калка, 7.36 сәгатьтә бата. 15 сәгать 40 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 11.07 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кисkенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

8 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 16 нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 19.15 сәгатьтә калка, 7.43 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.11 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Сарымсак согы

Артрит, артроз кискенләшкәндә, башка сәбәптән буыннар сызлаганда, сарымсак булыша. Аны вак угычта кырып, согын сыгып алалар. Көненә 4 тапкыр 10 ар тамчы кабалар, артыннан җылы сөт эчәләр. Төнгелеккә авырткан буыннарга сарымсак согында чылатылган марля бәйләп яталар. Әмма тирегә башта нинди дә булса май сөртергә кирәк, югыйсә сарымсак согы пешерергә мөмкин.

9 март (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 20.35 сәгатьтә калка, 7.47 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.16 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Чәч коелса

1 әр аш кашыгы бал һәм алоэ согы, 1 чәй кашыгы сарымсак согы, 1 йомырка сарысын кушып, яхшылап болгаталар, баш тиресенә сөртеп, өстеннән полиэтилен башлык киялә, 20 минуттан соң шампунь белән юып, кычыткан төнәтмәсе белән чайкыйлар. Мондый компрессны атнасына 2-3 тапкыр ай буена ясау бик файдалы.

10 март (җомга). ***Шәгъбән аеның 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 21.58 сәгатьтә калка, 7.54 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.21 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Шоколадлы кекс

200 г атланмайны эретеп, 1,5 стакан шикәр, ярты стакан сөт, 1 аш кашыгы какао кушып болгаталар, кайнатып чыгара язалар. Ярты чынаягын соңыннан бизәү-ялтырату өчен калдыралар. Калган өлешенә, суынгач, күпертелгән 4 йомырка, ярты чәй кашыгы сода яки 1 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч, йөзем, 2 стакан он, ванилин кушып туглыйлар. Махсус формага агызып, 220 градуслы газ мичендә 40 минут пешерәләр, бераз суынгач, өстенә аерып калдырылган ширбәтне сылыйлар, ул кекска искермичә озаграк саклану мөмкинлеге бирә.

Милли гөлнең былбылы

Башкортстан ягының уңдырышлы туфрагы халкыбызның рухи дөньясына кабатланмас, канатлы талантлар бирә: Әнгам Атнабай, Айдар Хәлим, Әмирхан Еники, агалы-энеле Илдар һәм Нил Юзеевлар, Нурихан Фәттах, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Хәсән Сарьян... Хатын-кызларыбыздан Саҗидә Сөләйманова, Нәҗибә Сафина, Ләйсән Кәшфи… Татар дөньясын югарыга күтәргән җырчыларыбыз да шактый.

Һәм... инде ничә еллар буена, милләтпәрвәр моң иясе, халкыбызның аңын да, җанын да, һәрбер күзәнәген дә уянырга, хөрлек өчен көрәшүгә өндәүче җырчы-композитор Флүрә Коләхмәтова-Талипова.

Ул Башкортстанның таң калырлык гүзәллеккә ия булган Салават районындагы Урманчы авылында туган. Авылга нигез салучы – Коләхмәт (Флүрә аның нәсел шәҗәрәсеннән). Флүрә Лаклы авылында, кечкенәдән җырга-моңга гашыйк булып, ятимлектә үсә... Бертуганнары – барысы да кызлар. Авыл җирендә эш, йөз тавык чүпләсә дә, бетә торган түгел. Флүрә кирәк чакта утынын да ярып, печәнен дә чабып, язмышын баш имәслек, чигенмәслек, фикерен кистереп әйтерлек дәрәҗәдә камилләшеп буйга җитә. Киртәләр, вакытлы каршылыклар да иҗат кешесе өчен – илһам чыганагы. Аның кыйбласы – гаделлек, тигезлек, тиң хокуклылыкны яклап, туган халкының бөеклеген раслап, аңа хезмәт итү. Гомер буена ул ошбу туры юлдан тайпылмый, яңа-яңа яшьни, өммәтебез язмышын кайгыртып, аның мәнфәгате хакына яши. Аның илһамы да табигый, садә, ихлас һәм эчкерсез!..

Стәрлетамакта 1985-1990 елларда педагогика институтын тәмамлаганнан соң, ул бер ел авылда укытучы булып эшли. 1990 елларда язгы ташкындай күтәрелгән милли хәрәкәт анны да үзенә бөтереп ала. Флүрә 1992 елда гаиләсе белән Чаллы каласына күчеп килә. 1993-1998 елларда 24 нче мәктәптә татар телен укыта. Хәзер ул шәһәрнең «Эврика» мәдәни үзәгендә ялкынланып эшли.

Флүрәне беренче кат Чаллының «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә 2004 елда очраттым. Ул тыңлаучыларның да йөрәкләрен дулкынландырып, шагыйрә Әлфия Ситдыйкованың «Язмышлар» җырын баянда өздереп, үзе җырлап башкарды. Көен дә үзе язган! Җыр озын гомерле булды. Флүрәнең иҗат башлангычына тәэсир ясаган Серафима Сафинаны да онытырга мөмкин түгел. Ул язган «Мин яшәргә тиеш», «Бу дөньялар якты икән», «Җавапсыз сорау» шигырьләре нигезендә Флүрә җырлары озак еллар буе яңгырады. Серафима үзе бакыйлыкка күчте, ә җырлары яши! Аннары Флүрә минем шигырьләргә дә мәгънәле җырлар язды: «Хәтер», «Әйтмә миңа», «Усман авылы», «Әнкәемә», «Мәхәббәт күпере», «Мәхәббәтем – төнге абага», «Кыр казлары», «Кайттым туган ягыма». Мин фәкыйрегезнең «Йөрәкләргә шакыйм», Айдар Хәлимнең «Татар язмышы» җырлары белән хит-парадта катнашып, беренче урынны да яулады ул! Башка шагыйрьләрнең сүзләренә дә кабатланмас көйләр тудырды. Гомумән, Флүрә күп иҗат әһелләре белән бәйләнештә тора.

Флүрә үзе белән хезмәттәшлек иткән иҗат әһелләренең кичәләрендә дә катнаша. Өстәвенә, ул тирән мәгънәле, хис-тойгыга гаҗәеп бай шигырьләр дә яза. Аларда милләт гаме, тормыш яме, ачы-төче чынбарлык тәме... Иҗатка күп вакыты китсә дә, ул милли рухлы, инсафлы, итагатьле ике малай үстерде. Улы Илгиз дә сокланырлык итеп баянда уйный, эштән бушаган арада әнисе язган көйләрне нотага сала. Флүрә фидакяр, горур рәвештә халык мәхәббәтен яулады, әмма дан-шөһрәтне әрсезләнеп, даулап йөрмәде. Хәлбуки, һәрбер иҗатчы да хезмәтенә күрә хөрмәт тә көтеп яши...

Флүрә беркемнән дә, бернәрсә дә таләп итми. Аның өчен иң зур, кадерле бүләк – халык мәхәббәте. Ә татарны түбәннән югарыга чөярга тырышкан, җаны-тәне белән аны сөйгән, фидаи, олы талантны күрми-бәяләми калу мөмкин түгел!

Айрат СУФИЯНОВ.

«Күчтәнәч»ле кичә

Якташ язучыбыз Фатих Хөсни шагыйрьләргә илһам бирерлек гүзәл табигате, уңган халкы, челтерәгән чишмәләре, алтын башаклы басулары белән дан тоткан Теләче районы Мәтәскә авылында туган. Аның тууына 115 ел тулу уңаеннан Күкчә авыл китапханәсендә мәдәният хезмәткәрләре белән берлектә «Фатих ага Хөснидән кыйммәтле күчтәнәч» дип исемләнгән әдәби кичә үткәрелде.

«Кунаклар» бик күп килде. Ф.Хөснинең «Татар карчыклары» хикәясеннән Җәүһәр (Фирдания Газизова), «Кабак» хикәясеннән Мәһи белән Мәлихә (Рәйхана Антонова һәм Илсөяр Сәлаховалар), Ниса белән Зиннур (Илзирә Шәйхетдинова, Әмир Антоновлар), «Сөйләнмәгән хикәя»дән Биктимер (Сәид Кәримов) дә булды кичәбездә. Ә Рүмия Кәримова «Кабак» хикәясендә автор ролен башкарды.

«...Аның геройлары – гади кешеләр. Үз теле белән әйтсәк,«кечкенә кешеләр». Ләкин бу кечкенә кешеләрнең аяклары җирдә йөрсә дә, башлары күккә тиеп йөри. Фатихның «кечкенә кешеләре» җиргә хуҗаларча кыю басып йөрүчеләр...» – дип яза Ибраһим Гази. Чыннан да Ф.Хөснидән иң күңелле күчтәнәч – кичәбезнең геройлары, җиргә кыю басып өйрүчеләр. Аның хикәяләрен җиңел генә укып, матур уйлардар белән янабыз. Укып чыгу белән күңелебез белән Фатих абыйның яшьлегенә кайтып килгән шикелле булабыз.

Төбәгебездән бик күп талантлы әдипләр, шагыйрьләр чыккан. Әдәби кичәдә аларның иҗат җимешләрен Асилә Кәримова укыды.

Кичәбез ахырында, Теләче төбәге киләчәктә дә татар халкына яңа Фатих Хөсниләр тудырыр, үстерер дигән ышаныч белән, композитор Хөснул Вәлиуллинның Фатих Хөсни сүзләренә иҗат ителгән «Кошлар тынды» җырын яңгыраттык.

Күкчә авылы.

АЗНАКАЙДАГЫ ӘГЕРҖЕ

(Ахыры. Башы 6 нчы биттә).

1915 елда авыл тагын 37 ир-атны сугышка озата.

Беренче бөтендөнья сугышына алынган Әгерҗе ирләре (1915 ел)

№	Мобилизацияләнүчеләр	Хуҗалык башында калучылар
1	Гасыйм Латыйпов	Газия Хәйруллина (хатыны)
2	Мөхәммәтгали Галимов	Галим Вәлиев (атасы)
3	Таһиркол Бикколов	Мәгърифә Габдерәхимова (хат.)
4	Җиһангир Ибраһимов	Зәкия Галимҗанова (хат.)
5	Габдеракыйп Кадыйров	Йөзлеҗан Шәрәфетдинова (хат.)
6	Закир Мөхәммәтҗанов	Халидә Ильясова (хат.)
7	Закир Кадыйров	Миңлекамал Муллагалиева (хат.)
8	Миңлерахман Хәбибрахманов	Миңлегаян Шакирова (хат.)
9	Нәгыймулла Кәлимуллин	Мөшәрәфә Фазуллина (хат.)
10	Гали Гомәров	Миңлеҗиһан Шиһабетдинова (хат.)
11	Кашшафетдин Фәттахетдинов	Фәттахетдин Мифтахетдинов (ат.)
12	Шаһиморат Шаһиәхмәтов	Фаидә Сәлимгәрәева (хат.)
13	Сабирҗан Гомәров	Гомәр Галиуллин (ат.)
14	Шаһидулла Хәлиуллин	Гашия Нәфыйкова (хат.)
15	Мостафа Гәрәев	Камилә Әхмәтҗанова (хат.)
16	Багис Гарифуллин	Гөлбану Хәйруллина (ан.)
17	Фатыйх Габдерәхимов	Таифә Сәфәргалиева (хат.)
18	Насыйр Кадыйров	Мәүлиха Әхмәткәримова (хат.)
19	Әхмәт Мәүлетов	Маһибәдәр Хәбирова (хат.)
20	Гасыйм Мәгъсүмов	Мәгъсүм Галләмов (ат.)
21	Солтангәрәй Зарифуллин	Зарифулла Сафиуллин (ат.)
22	Мөхәммәтгали Миндубаев	Камилә Госмангалиева (хат.)
23	Каюм Галләмов	Галләм Ганиев (ат.)
24	Хәсән Ибраһимов	Ибраһим Галиуллин (ат.)
25	Хәйретдин Хәсәнов	Хәсән Исхаков (ат.)
26	Сәхәбетдин Хәбибуллин	Хәбибулла Сафиуллин (ат.)
27	Муса Латыйпов	Гайниҗамал Миңлекәева (ан.)
28	Габдрахман Кәримов	Кәрим Гыйззәтуллин (ат.)
29	Латыйфетдин Фәхретдинов	Шәмселбанат Батыршина (хат.)
30	Хөсәен Госманов	Шәмсениса Кәлимуллина (хат.)
31	Сәхәбетдин Хөснуллин	Хөснулла Хәмидуллин (ат.)
32	Харис Шәйхетдинов	Шәйхетдин Шәмсетдинов (ат.)
33	Миңлегали Зарипов	Мөкәррәмә Исламова (хат.)
34	Мөхәммәтгариф Баһаутдинов	Баһаутдин Галиуллин (ат.)
35	Солтангир Әхмәткәримов	Маһисорур Шәрипова (хат.)
36	Мөхәммәтсафа Гәрәев	Камилә Гарифуллина (хат.)
37	Насретдин Сәгъдетдинов	Сәгъдетдин Нәфыйков (ат.)

Шулай итеп, ике ел эчендә авылдан 88 кеше мобилизацияләнгән. 1916 һәм 1917 еллар буенча мәгълүматлар юк, әмма бу чорда да иллдән артык кеше хәрби хезмәткә чакырылган булса, ир-улларын сугышка озатмаган гаиләләр бик аз кала түгелме?

Сугыш авылның социаль хәлен начарайта. Бу беркадәр 1916 елда үткәрелгән авыл хуҗалыклары исәбен алу материалларыннан да күренә. Әгерҗедә 212 хуҗалыкта 746 ир-ат һәм 962 хатын-кыз теркәлә. Саннар арасында аерма зур булуның сәбәбе мәгълүм – сугыш.

Бу чорда төбәктә качаклар да күренә башлый. Алар Әгерҗедән (3 кеше) башка, волостьның Азнакай (18), Уразай (15), Балтач (4), Сәпәй (2), Әсәй (3) авылларына килеп утыра. Әгерҗедә качакларның берсе – ир-ат, икесе – хатын-кыз.

Авыр сугыш елларында да терлекчелеккә һәм игенчелеккә игътибар кимеми. Әгерҗедә 420 ат (шул исәптән 355 эш аты), 511 мөгезле эре терлек (250 сыер), 1135 сарык һәм 264 кәҗә исәпләнә. Чәчүлек мәйданы 824,45 дисәтинә тәшкил итә. Шуның яртысыннан артыгын арыш (438 дисәтинә), калган өлешен солы (146,25), карабодай (78,5), борай (57,30), тары (48,15), бодай (37,5), борчак (18,25) һәм ясмык (0,5) алып тора.

Октябрь инкыйлабыннан соң авылларда, шул исәптән Әгерҗедә, җирле хакимияткә сайлаулар үткәрелә. Авыл башкарма комитетына Габделгани Корбангалиев – комиссар, Әшрәфетдин Бикколов, Садретдин Баһаутдиновлар комитет әгъзасы итеп сайлана. Барлык сайлаучылар 600 кеше исәпләнә. Әлеге мәгълүматлар 1918 елның декабрендә алына.

Ике елдан халык санын алу үткәрелә. Әгерҗедә 294 хуҗалык һәм 1103 кеше теркәлә. Әмма 1921 елгы ачлыктан күп гаиләләр кырыла. Шуңа күрә чираттагы халык санын алуга (1926 ел) әлеге күрсәткечләр шактый кимрәк – 203 һәм 913. Авыл Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә.

1930 елга караган бер документта Гәрәев Мөхәммәтнең икенче категория белән раскулачивать ителүе хакында әйтелә. Мал-мөлкәтен тартып алып, үзен авылдан сөрергә карар чыгарыла. Репрессиягә, билгеле, кайбер башка кешеләр дә дучар була, архивларны өйрәнеп, аларның да исемнәрен ачыклау таләп ителә.

1931 елда Әгерҗе авыл советы җирләрендә «Берек» һәм «Ирек» күмәк хуҗалыклары оеша, соңыннан алар кушыла, 1967 елдан «Октябрьнең 50 еллыгы» дип атала. Авылда атаклы бакчачы Шәйморат Әхмәтов яшәгән, Мичурин белән хат алышкан, колхоз бакчасында төрле сорт яшелчә-җимешләр, кавын һәм карбызлар үстергән.

Бүген авылда биш йөзгә якын кеше яши. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты бар. Халыкның күпчелеге күмәк хуҗалыкта, бер өлеше нефть тармагында эшли.

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

3 март – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
4 март – 12.00, 12.30 – «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
5 март – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
7 март – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
8 март – Зур залда – «Бию пәрие» (И.Зәйниев). Кече залда «Исәнме, улым!» (Б.Абдуразззоков).
9 март – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
10 март – Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдиновның иҗат кичәсе.

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

4,5 март – «Тщетная предосторожность» (Л.Герольд).
8,9 март – «Анюта» (В.Гаврилин).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

4 март – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
6 март – Буа Татар дәүләт драма театрының «Дәрвиш» спектакле (Р.Садриев).
7 март – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
8 март – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
9 март – «Идегәй» (Т.Имаметдинов инсценировкасы буенча).
10 март – 12.00 «Татар теле – сәхнә теле» спектакль-дәрес (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Ашина» (Р.Зәйдулла).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

7,8 март – Премьера. «Җырлап ишик» (Р.Латыйпов).
10 март – «Тимур һәм комета» (П.Коротыч).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

3 март – 13.00 – «Золушка» (Е.Шварц). 19.00 – «Ханума» (А.Цагарели).
4 март – Зур залда – «Новые приключения трех поросят» (Б.Вайнер). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
5 март – Зур залда – «Аленький цветочек» (С.Аксаков). Кече залда – «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш).
7 март – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина).
8 март – Зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән).
Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
9 март – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән).
10 март – 11.00 – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән). 19.00 – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

3 март – Композитор П.И.Чайковскийның ария һәм романсларына багышланган кичә.
4 март – Вадим Эйленкриг һәм «Eilenkrig Crew»нең «Pier 39» дип исемләнгән альбомын тамашачыга тәкъдим итү.
5 март – Рок концерты.
6 март – «Собачье сердце» спектакле.
7 март – Бәйрәм концерты. Катнашалар – А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор музыкасы ансамбле, җырчылар Р.Низамов, В.Усманов, Р.Насыйбуллин, И.Шәйхразиев, Р.Җәләлиев, И.Дмитриев, Б.Бикчәнтәев, А.Хөсәенов, В.Адилов, пародия остасы Ә.Хәбриев.
9 март – Романслар кичәсе.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

3 март – Татарстан Республикасының М.Тәминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хоры концерты.
5 март – 12.00 – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркесты башкаруында популяр классика, кинофильм һәм мультфильмнардан музыкаль әсәрләр яңгыраячак. Дирижер – Алина Яконина. 17.00 – Татарстан дәүләт кыллы квартетына Илдар Нигъмәтуллин кушылып фортепианода уйный, Ирек Фәттахов һәм Илгиз Мөхетдинов кушылып җырлый.

Иң озын тоннель

Дөньяда иң озын, иң тирән һәм иң кыйбатлы тоннель Швейцариядә урнашкан. Барлыгы 11 миллиард долларга төшкән Сен-Готард тимер юл тоннеле Альп таулары астыннан 57 чакрымга сузылган, җир өслегеннән иң ерак урыны 2,3 чакрым тирәнлектә үтә. Пассажир поездлары аның аша сәгатенә 250 километр, йөк составлары исә сәгатенә 160 километр тизлек белән уза, сәяхәтчеләр 20 минут эчендә үтә. Сен-Готард тоннелен 1947 елда ук төзергә карар кылган булалар, әмма ярты гасырдан соң гына сала башлыйлар. Эш, тәүлек буе туктамыйча, 18 ел тоташ бара, төзелештә 2,5 меңнән артык белгеч катнаша. Җир асты юлы 2016 елда гына файдалануга тапшырыла. Сен-Готардка кадәр Япониядәге 23 чакрымы су астыннан үтә торган, барлыгы 54 чакрымлы Сэйкан җиһанда иң озын тоннель саналган.

(“Интересно.cc”).

Агарта да, агулый да

Дөньяда иң күп кулланыла торган азык өстәмәләреннән берсе – титан диоксиды Е171 – сәламәтлек өчен бик зыянлы. Ул идеаль агарткыч санала, аны икмәккә, сөт һәм кондитер ризыкларына, сагызга, теш пастасына кушалар. Ә иң куркынычы – титан коры сөт җитештерүдә кулланыла, аңардан исә бик күп сөт ризыгы әзерләнә. Мондый ризыклар составында титан диоксиды хәтта күрсәтелми дә. Галимнәр ачыклаганча, Е171 ашказаны һәм эчәклек күзәнәкләре структурасын җимерә, бу исә куркыныч бактерияләргә ашкайнату системасына үтеп керергә мөмкинлек бирә, шул ук вакытта цинк, тимер, май кислоталары кебек мөһим матдәләрнең үзләштерелүенә комачаулый. Француз галимнәре әйтүенчә, сынау барышында титан диоксидын даими кулланган хайваннарның 40 процентының ашказанында яман шеш пәйда булган. Россиядә Е171 өстәмәсен ашамлык җитештерүдә куллану рөхсәт ителгән, сәламәтлеккә зыян китермәслек тәүәкәллек норма исә ачыкланмаган. Шунлыктан коры сөт җитештерүче үз продуктына теләсә күпме титан диоксиды куша ала.

(“МедНовости.ру”).

Нәселдән килә

Вашингтон университетында айсарлыкның (лунатиклык) генетик тайпылыш булуын дәлилләгән теорияне тикшереп караганнар. Галимнәр ДНКның сомнамбулачылык үсешенә китерә торган өлешен тапкан. Тикшеренүдә бер гаиләнең дүрт буыны – барлыгы 22 кеше катнашкан, шулардан тугызы айсарлыктан интегә. Алар барысы да төнлә йоклаган килеш торып йөри һәм еш кына кул-аякларын сындыра. Бер ир-ат исә, йокысыннан уянмыйча, төн саен аягына сигез пар оекбаш эзләп кия. Сомнамбулаларның һәм аларның туганнарының ДНКсына анализ ясап, белгечләр 20 нче хромосомада үзенчәлекле урын тапкан, әгәр геномда шуның бердәнбер күчермәсе булса, кеше айсарга әйләнә икән. Хәзер галимнәр әлеге урындагы 28 генның кайсының бу чир өчен “гаепле” булуын ачыкламакчы. Алар, сәбәп аденозиндеаминаза гениндадыр, дип фаразлый, чөнки ясалуы өчен ул җаваплы булган фермент әкрен йокы фазасы өчен җавап бирә, ә айсарлар нәкъ менә шул фазада йөри дә инде.

(“Neurology”).

Йолдыздан яктырак



Гонконгтагы Sotheby’s аукционында моннан биш ел элек сатылган бриллиант дөньяда иң кыйммәтле санала. 60 каратлы “Алсу йолдыз” өчен 71,2 миллион доллар биргәннәр. Зәркәнчеләр фикеренчә, ул шундый кыйммәт бәягә лаек, чөнки составында азот кушылмалары булмаган әлеге бриллиантның төсе искиткеч матур. 2013 елда “Алсу йолдыз”ны элек саткан булганнар инде. Ул чакта Нью-Йорк зәркәнчесе Исаак Вольф аны 83 миллион долларга алган. Әмма тиздән бөлгән һәм асылташтан баш тарткан. Бу юлы бриллиант Гонконгта калган, аны асылташ сәүдәсе белән шөгыльләнә торган җирле компания 5 минут эчендә сатып алган. Әлеге уникаль җәүһәр ташны 1999 елда Көньяк Африка Республикасында тапканнар. Кырлап шомартуга ел ярым вакыт киткән. Шомартканчы, ул хәзергедән ике тапкыр диярлек авыррак булган. Асылташ, эрерәк булган саен, сыйфатлырак һәм кыйбатрак санала. Аның бәясе, үлчәменә карап, геометрик прогрессия буенча арта бара.

(“Goldengod.ru”).



Ахырзаман сәгате

Мәхшәр көне сәгате 1947 елда кешелекнең үз-үзен юк итүгә никадәр якынлашуын күрсәтү өчен ясалган. Аны Американың “Атомчы галимнәр бюллетене” журналы кешелек игътибарын атом-төш коралы куркынычына җәлеп итү өчен эшләтеп җибәргән. Ул чакта сәгать төнге уникe туларга җиде минутны күрсәткән. Башта сәгать укларын журнал мөхәррире Юджин Рабинович күчерә торган булган. Ул 1973 елда җан тәслим кылгач, укларны алга яки артка күчерү карарын белгечләр советы кабул итә башлаган, алар башка галим һәм экспертлар, шул исәптән 13 Нобель бүләге иясе белән киңәшләшә. 1953 елда, АКШ һәм СССРда атом-төш коралын сынаулар үткәрелгәч, XX гасырдагы иң куркыныч күрсәткеч теркәлгән – ахырзаман сәгатендә уникe туларга ике минут кына калган. 1960 елда, СССР һәм АКШ арасында мөнәсәбәтләрнең яхшыруы нәтиҗәсендә, ук биш минутка артка күчерелгән. 1962 елгы Америка ракеталарының - Төркиядә, Советлар Берлеге коралларының Кубада урнаштырылуына бәйле Кариб кризисы исә Кыямәт көне сәгатенә берничә дә йогынты ясамаган. 1963 елда, СССР һәм АКШ атом-төш коралын һавада, космоста һәм су астында сынауны тыю турында килешүне имзалагач, вакыт 12 минутка кадәр озынайтылган. 1983 елда, ике ил мөнәсәбәтләрендәге “иң салкын” чор вакытында, ук уникe туларга өч минут кына калдырып туктаган. Салкын сугыш тәмамланган 1991 елда ахырзаманга кадәр вакыт 17 минутка кадәр озайтылган. Шул вакыттан бирле ул һаман кими барган һәм 2017 елга кадәр уникe туларга 5-6 минутны күрсәтеп торган. 2018 елда исә ике минутка гына калдырылган. 2020 елда экспертлар советы мәхшәргә кадәр 100 секунд кына калуны теркәгән, 2021 елда да ул үзгәртелмәгән.

Ә менә 2023 елда ахырзаманга кадәр калган вакыт 90 секундка кадәр кимелгән. Шулай да, кешелек акылга килер һәм үз-үзен юкка чыгарудан тыелыр, дигән өмет белән яшибез.

(“Hi-news.ru”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

6 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 16+
10.00, 23.00 «ДЕВУШКА СРЕДНИХ ЛЕТ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00 «БИЧАРАКАЙ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Моң чишмәсе». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Гаилә учагы». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 Выставка «ТатАгроЭкспо-2023». 12+
21.05 «Соотечественники». 16+
22.10 «БИЧАРАКАЙ». 12+
23.50 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.40, 19.30 «Калеб». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «Муза... Музыка... Мозаффаров...» 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Моң чишмәсе». 16+
17.30, 0.40 «Гаилә учагы». 16+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
0.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КАК РАЗВЕСТИ МИЛЛИОНЕРА». 12+
14.35 «Великие женщины России». 12+
14.50 «Не женское дело». 12+
15.00 «Коллекция». 12+
15.30 «Мой первый Жванецкий». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Век СССР». «Запад». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...» Крым античный.
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Шарымов.
7.35, 18.35 «Загадка древнего захоронения: гендерная революция».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.55, 16.30 «БАЛ В «САВОЙЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Любимые женщины. Алексей Покровский».
12.25, 22.10 «СЁГУН».
14.00 «Первые в мире».
14.15 «Игра в бисер» «Эдуард Успенский. «Крокодил Гена и его друзья».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
17.35 Оперные дивы. Мария Гулегина.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Хранители жизни. Склифосовский».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00, 0.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Сишәмбе

7 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 16+
10.00, 23.00 «ДЕВУШКА СРЕДНИХ ЛЕТ». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «БИЧАРАКАЙ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Моң чишмәсе». 16+
15.15 «Теймә».
16.00 «О спорте, о семье, о счастье». К юбилею Шамиля Тарпищева. 12+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
18.20 Выставка «ТатАгроЭкспо-2023». 12+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина. «Нефтехимик» - «Ак Барс».
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Ватандашлар». 16+
12.05, 18.20, 21.25 «Күңелем назлары җырымда чагыла». Флера Сөләйманова турында телеочерк. 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». 6+
17.00 «Моң чишмәсе». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КАК РАЗВЕСТИ МИЛЛИОНЕРА». 12+
14.35 «Великие женщины России». 12+
14.50 «Коллекция». 12+
15.20 «АГАФЬЯ». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Век СССР». «Запад». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.25 «Увидеть Древний Египет глазами фараонов».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.55, 16.30 «БАЛ В «САВОЙЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Вечер памяти Андрея Миронова. Придут друзья...»
12.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
12.25, 22.10 «СЁГУН».
13.55 65 лет Александру Ф. Скляру. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Валентин Серов».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.40 Оперные дивы. Хибла Герзмава.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Чәршәмбе

8 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «УЕННАН УЙМАК». 16+
10.00, 22.10 «ДЕВУШКА СРЕДНИХ ЛЕТ». 12+
11.00 «Мәхәббәт хакына». 16+
16.30 «Татарлар». 12+
17.00 «Женщина года. Мужчина года. женский взгляд». 16+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
20.00 «Синең өчен сөюләрем». Азат һәм Алсу Фазлыевлар концерты. 12+
21.00 «Спортивная среда». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ВЕК АДАЛИН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
9.15 Спектакль «Килә ява, килә ява». 16+
11.30, 17.30, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 23.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
15.00 Спектакль «Ява карлар, ява карлар». 16+
18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
18.20 «Женщина года. Мужчина года. женский взгляд». 16+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Гаилә учагы». 16+
21.25 Спектакль «Алты кызга бер кияү». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00 «МИСС ПОЛИЦИЯ». 12+
16.15 «Праздничное шок Валентина Юдашкина». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.00 «КРАСОТКА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.30 «ГУСАРСКАЯ БАЛЛАДА». 12+
8.15 «ВЕСНА НА ЗАРЕЧНОЙ УЛИЦЕ». 12+
10.00, 12.00 Новости.
10.15, 12.15 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН».
13.35 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ». 12+
16.25 «КРАСОТКА». 16+
18.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
21.30 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.30 Творческий вечер Алексея Рыбникова. «Через тернии к звездам». 12+

«РОССИЯ»

5.05 «ЛЮБОВЬ НЕЖДАННАЯ НАГРЯНЕТ». 12+
8.55, 11.30 «ИРОНИЯ СУДЬБЫ, ИЛИ С ЛЁГКИМ ПАРОМ!» 12+
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
13.15 «О чём поют 8 Марта».
14.50 «Петросян и женщины». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.45 Вести. Местное время.
21.00 «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ». 12+
23.00 «ПАРА ИЗ БУДУЩЕГО». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 Мультфильмы.
7.55 «ШОФЕР НА ОДИН РЕЙС».
10.15 Исторические курорты России. Ессентуки.
10.45 «СВАТОВСТВО ГУСАРА».
11.55 «Забытое ремесло».
12.10 «Мама - жираф».
13.05 «Красота по-русски».
14.00 «ЗОЛУШКА».
15.20 XXXI церемония вручения премии «Хрустальная Турандот». «За честь, достоинство и служение зрителю».
16.45 «Пешком...» Москва весёлая.
17.10 «Первое, второе и компот. Истории и рецепты советского общепита».
17.55 «Романтика романса».
18.50 «ВЕСНА».
20.35 «ШЕРБУРСКИЕ ЗОНТИКИ».
22.05 Балет Ц. Пуни «Катарина, или Дочь разбойника».

«НТВ»

5.20 «Таинственная Россия. Москва. Матрона - заступница столицы?» 16+
6.05, 8.25 «МАМА В ЗАКОНЕ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
10.25, 16.25, 19.40 «ФЕМИДА ВИДИТ». 16+
21.00 «ПАПЫ». 6+
23.10 Праздничный концерт Юсифа Эйвазова и Кирилла Туриченко. 12+

Пәнҗешәмбе

9 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК 2». 16+
10.00, 23.00 «ДЕВУШКА СРЕДНИХ ЛЕТ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
14.30, 0.15 «Соотечественники». 16+
15.00 «Моң чишмәсе». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00, 21.10 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «БИЧАРАКАЙ». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 11.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 16+
15.00 «Ватандашлар». 16+
15.30 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Моң чишмәсе». 16+
18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ!» 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 0.30 «РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО». 12+
14.35 «Великие женщины России». 12+
14.50 «Не женское дело». 12+
15.00 «Коллекция». 12+
15.30 «На крыло». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.

7.35, 18.35 «Ватикан - город, который хотел стать вечным».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «Забытое ремесло».
9.05, 16.40 «ТАЙНЫ СЕМЬИ ДЕ ГРАНШАН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Танцует Людмила Семеняка».
12.15 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
12.20 Больше, чем любовь.
13.05 «ШОФЕР НА ОДИН РЕЙС».
14.15 «Я из тёмной провинции странник...»
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Беломорские узоры».
15.45 90 лет со Дня рождения Николая Дмитриева. Острова.
16.25 «Первые в мире».
17.35 Оперные дивы. Динара Алиева.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Валерия Пустовая. «Ода радости».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 «Лютики-цветочки «Женитьбы Бальзаминова».
21.30 «Энигма. Оле Бэкхой».
22.15 «СЫГРАЙ ЭТО ЕЩЕ РАЗ, СЭМ».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00, 0.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
0.50 «Поздняков». 16+

Җомга

10 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «УЕННАН УЙМАК 2». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Моң чишмәсе». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Гаилә учагы». 16+
22.10 «СУДЬБА НАПРОКАТ». 12+
23.45 «ЖИЗНЬ И ПРИКЛЮЧЕНИЯ РОБИНЗОНА КРУЗО».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 16+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Казаннан казанга». 16+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Моң чишмәсе». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «РАГИН». 12+
15.00 «Коллекция». 12+
15.30 «Следствие по делу поручика Лермонтова». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.40 «Я СОЗДАН ДЛЯ ТЕБЯ». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.40 Торжественная церемония вручения музыкальной премии «Виктория».

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.25, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Хранители жизни. Склифосовский».
8.15 Цвет времени. Карандаш.
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 14.15 «Забытое ремесло».
9.05, 16.45 «ТАЙНЫ СЕМЬИ ДЕ ГРАНШАН».
10.20 «ДЕТИ КАПИТАНА ГРАНТА».
11.45 Больше, чем любовь.
12.25 Цвет времени. Павел Федотов.
12.40 Открытая книга. Валерия Пустовая. «Ода радости».
13.05 «ШОФЕР НА ОДИН РЕЙС».
14.30 «Война Жозефа Котина».
15.05 Письма из провинции. Таманский полуостров.
15.35 «Энигма. Оле Бэкхой».
16.20 «Екатеринбург. Особняк Тупиковых».
17.45 Оперные дивы. Марина Ребека.
19.45 К 65-летию Максима Кронгауза. Линия жизни.
20.40 «Я шагаю по Москве». Летний дождь и его последствия».
21.20 «Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ».
22.35 «2 Верник 2».
23.50 «СТРАННИКИ ТЕРПЕНЬЯ».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Шимбә

11 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 Гала-концерт Республиканского конкурса творчества работающей молодёжи «Безнең заман - Наше время». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит шоу». 16+
23.00 «КАНИКУЛЫ МЕЧТЫ». 16+
0.40 «Спортивная среда». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Галимҗан Ибраһимов турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кайнар хит». 16+
10.00 «Кәмит Җәвит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 Зөфәр Хәйретдиновның юбилей кичәсе. 16+
23.20 Спектакль «Соңгы риваять. Сөембикә». 16+

«ЭФИР»

5.00, 8.30 «Великие женщины России». 12+
5.15, 14.45 «Не женское дело». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.45 «КОСТЕР НА СНЕГУ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КРАСОТКА». 12+
15.00 «Вильям Похлебкин. Рецепты нашей жизни». 16+
15.45 «ПРИНЦЕССА С СЕВЕРА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СЕМЬ УЖИНОВ». 12+
22.30 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Проуют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
13.05 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
17.10 Праздничный концерт «Объяснение в любви». 12+
18.20 «Объяснение в любви». 12+
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 «НЕ ВСЕ ДОМА». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.30, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «АКУШЕРКА. СЧАСТЬЕ НА ЗАКАЗ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «МАМА МОЖЕТ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.55 «Я шагаю по Москве». Летний дождь и его последствия».
8.35 «Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ».
9.55 «Мы - грамотеи!»
10.40 «SOS» НАД ТАЙГОЙ».
11.45 Человеческий фактор. «Дом белого аиста».
12.15 Черные дыры. Белые пятна.
12.55 «Эффект бабочки».
13.25 «Шотландия - сказочный мир дикой природы».
14.20 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.35 Мастера оперной сцены. Екатерина Семенчук и Академический симфонический оркестр Московской филармонии.
17.05 «Тамбов. Дворец Асеевых».
17.30 «БЛАГОЧЕСТИВАЯ МАРТА».
19.50 «Эрнест Бо. Император русской парфюмерии».
20.45 «ТРИ ТОПОЛЯ НА ПЛЮЩИХЕ».
22.00 «Агора».
23.05 Клуб шаболовка 37.

«НТВ»

5.05 «Жди меня». 12+
5.50 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Основано на реальных событиях». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

12 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Гомер - татлы мизгел». Раяз Фасихов концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Моң чишмәсе». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «КРАСАВИЦА И ЧУДОВИЩЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30, 22.00 «Күңел эретерлек сүзләр бар». Гөлүсә Шаһбанның иҗат кичәсе. 16+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Газинур Фаркушин турында телеочерк. 16+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Саф күңелле каласы иде». Вил Усманов концерты. 16+
15.50 «Ватандашлар». 16+
16.20, 21.10 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+

«ЭФИР»

5.00, 8.30 «Великие женщины России». 12+
5.15, 14.45 «Не женское дело». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.45 «ПРИНЦЕССА С СЕВЕРА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БЕДНАЯ ЛИZ». 12+
15.00 «Правда о лжи». 12+
15.45 «КОСТЕР НА СНЕГУ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВАЛЕРИЙ ХАРЛАМОВ. ДОПОЛНИТЕЛЬНОЕ ВРЕМЯ». 12+
22.40 «КОМАНДА МЕЧТЫ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 0.00 Подкаст.лаб. 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.05 «БЛАГОСЛОВИТЕ ЖЕНЩИНУ». 12+
16.30 «Век СССР». «Восток». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «КОНТЕЙНЕР». 16+
23.30 «На футболе с Денисом Казанским». 18+

«РОССИЯ»

5.55 «ПРЯНИКИ ИЗ КАРТОШКИ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.30 Вести.
11.30 «Большие перемены».
12.35 «АКУШЕРКА. СЧАСТЬЕ НА ЗАКАЗ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.45 «БЛАГОЧЕСТИВАЯ МАРТА».
10.05 Диалоги о животных.
10.45 «ТРИ ТОПОЛЯ НА ПЛЮЩИХЕ».
12.00 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Дранков.
12.30 «Игра в бисер» «И.С. Тургенев. «Муму».
13.15 «Бессмертнова».
14.10 Наталия Бессмертнова и Михаил Лавровский в балете С. Прокофьева «Ромео и Джульетта».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Сергей Михалков. Что такое счастье».
18.20 «Романтика романса». Песни Александра Зацепина.
19.30 Новости культуры.
20.10 «ТРАКТИР НА ПЯТНИЦКОЙ».
21.35 «Немного тишины...» Вечер-посвящение Олегу Ефремову.
22.50 «ДЕРЕВЕНСКАЯ ДЕВУШКА».

«НТВ»

5.00 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.50 «Звезды сошлись». 16+

Хәмер өзә гомерне

Буа районындагы Лащи станциясе бистәсендә яшәүче Галина Мешкова, күрше Бикмураздагы кечкенә оныгының өйдә үзе генә икәнен белгәч тә, шунда китә. Кичкә таба салмыш килен Гүзәл дә кайтып керә анда. Әни кеше улы Александр турында сораша, хатын-кыз аның Буада калуын, әрләшүләрен әйтә. Әлбәттә, ир-атның исерек икәне дә аңлашыла.

Ул көнне Гүзәл иртән эшкә киткәндә, иренә баш төзәтү өчен 165 сум акча калдыра, соңрак банк картасына акча күчерүен сорап шалтыратуларын санга сукмый, үзе төштән соң эш урыныннан китеп, элегрәк Буада яшәгәндәге күршесе Эльвира янына бара. Шешәдәш хатыннар соңгысы эшли торган суши-барда да, фатирында да сыйланалар, көн кичкә авышып, тәмәке тартырга урамга чыккач, подъезд төбендәге урындыкта яткан исерек Александр Мешковны күрәләр. Сәрхүш алдан шул тирәдәге яшүсмер егетләргә сүгенеп утыра, Бикмуразга таба парлашып тәпиләгәндә, ирле-хатынлылар арасында низаг чыга, шул рәвешле, А. Мешков Буадагы Р. Люксембург урамында кала.

Өлкән яшьтәге Галина велосипедка атланып Бикмураздан килгәч, улын эзләп бу якларны әйләнеп чыга, Яшьләр паркында да була, ләкин юньсез ирне очрата алмый. Икенче көнне полициягә шалтырата, ябып куймадылармы дип сораша, тискәре җавап алына. Шул көнне, ягъни 23 сентябрь кичендә өйләренә полиция хезмәткәре килеп парк артындагы ташландык балалар бакчасы ишегалдында Александрның үле килеш табылуы турында аяныч хәбәр җиткерә.

Аның кыйнап үтерелүе аермачык була. Моны башлыча йөз-бит тирәсендәге җәрәхәтләр күрсәтеп тора. Оперативниклар Р. Люксембург урамындагы почта бинасына куелган видеокүзәтү җайланмасы язмасын карагач, А.Мешковны алдагы кичтә бер ир-ат белән үтеп китүен ачыклыйлар, ә иртәнге сәгать дүртенчедә ошбу кешенең «Илфат» дигән кибеткә үзе генә кереп, сигарет алып чыгуы видеокамерага эләккән була.

Кечкенә калада ошбу затның шәхесен ачыклау өчен күп вакыт китми. Өстәвенә, полициядә мәгълүм кеше була ул. 1985 елгы Марат Фатыйхов 2004 елда кеше үтергән өчен Буада 14 елга ирегеннән мәхрүм ителә, Татарстан Югары судына мөрәҗәгать итеп, әлеге кырыс җәзасын берникадәр йомшартуга ирешә, шулай да 11 елдан артык гомерен япкынлыкта уздыра. 2020 елда полиция хезмәткәренә каршылык күрсәткән өчен ел ярымга утыртыла.

М.Фатыйхов, чынлыкта, гаебен таный, бары тик үтерү нияте булуын кире кага һәм, әлбәттә, сугыш А.Мешков аркасында килеп чыкты дип бара. Әйтүенчә, 22 сентябрьдә тән температурасы югары булу сәбәпле, аңа өч көнлек ял бирәләр. Һәм, әлбәттә, ошбу мөмкинлектән файдаланып М.Фатыйхов «дәваланырга», димәк ки, эчәргә керешә, кичкә таба почта бинасы стенасына сөялеп чүгәләгән

ир-атны күрә, имеш, аңа ярдәм кирәк дип уйлый, аның «Тагро»да бергә эшләгән А. Мешков икәнен белгәч, уртак тел тиз табыла. Ягъни ирләр аракы, сыра, пицца алып кеше йөрми торган тыныч урында чирәмгә утырып эчәргә керешә. Төннең икенче яртысында үзара низаг чыга. Кыскача гына әйткәндә, М.Фатыйхов кул астына эләккән таш белән шешәдәшенең күбрәк башын дөмбәсли, аңсыз калгач, өстерәп читкәрәк алып китә, әйтүенчә, салкынча сентябрь төнендә туңмасын дип өстенә үлән йолкып сала, уянып өенә кайтып китәр дип уйлый.

М.Фатыйховның гаебе шик уятмый, шуңа күрә Буа шәһәр суды аны сак астына алырга карар кыла. Ләкин тиздән аны кеше үтергән өчен җавапка тартып булмавы ачыклана. Эш шунда, суд-медицина экспертизасы А.Мешковның энцефалопатия дигән баш чиреннән җан бирүен күрсәтә, ә борын, берничә җирдән яңак сөякләре сыну, хәтта баш миенә азрак кан саву аның сәламәтлегенә уртача дәрәҗәдәге зыян китергән дип белдерә. Тикшеренү нәтиҗәләрендә әлеге биниһая күп җәрәхәтләрнең кеше язмышын хәл иткән авырунең көчәюенә китерүе әйтелә.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Айрат Мөхәммәдуллин аның гамәлләренә үтерергә омтылыш ясау дигән җитди бәя бирә. Гадиләштереп әйтсәк, М.Фатыйхов үтерәм дип кыйнаган, үлде дип белеп китеп барган булып чыга. Әлеге эшкә судта нокта куелачак, әлбәттә.

* * *

Буадагы фаҗига төрмә юлын таптаган эчкечеләр арасында килеп чыкса, Чистайда юньле генә күренгән агайнеләр очрашуы берсен гүргә, икенчесен төрмәгә озату белән тәмамлана. Монда да төп сәбәпне исереклектән күрергә кирәк.

Шул калада туып үскән Нияз Ризванов Түбән Камадагы көллияттә укып чыккач, алдан «Танеко» җәмгыятендә, соңрак, КамАЗда цех мастеры булып эшли, язылышмыйча бер хатын-кыз белән Чаллыда яши. Төп нигездә гомер итүче әтисе һәм әбисе янына еш кайтып йөри ул. Узган елның 26 сентябрендә дә өендә була. Күрәсең, аталы-уллы алар хәмергә хирыс, юкса, ул көнне өйлә вакытында ук эчә башламаслар иде.

Ниязның ике генә яшькә өлкәнрәк туганнан туганы Илфат Ризванов та Ленар исемле дусты белән эчеп йөри ул чакта. Алар төштән соң очрашырга була, кызмача дуслар аталы-уллы Ризвановларга кунакка килә, хәмерле мәҗлес дәвам итә, димәк. Һәм өч сәгатьтән соң сырхауханәгә Привалов урамындагы әлеге өйдә «ножевое ранение» дигән шомлы хәбәр килә. Табибләр барып җиткәч тә шәхси йорт ишегалдында ятучы канга баткан Илфатны шунда ук алып китәләр. Ашыгыч рәвештә операция ясалса да коткара алмыйлар аны, 1995 елгы егет касык өлкәсендә бер тапкыр чәнчү нәтиҗәсендә артерия һәм венасы киселеп күп кан югалту сәбәпле җан бирә.

Илфат Ризванов әти-әнисе белән күрше урамда гына яшәгән. Җинаять эшендә зарар күрүче итеп билгеләнгән абыйсы Марат һәм башка туганнары мәрхүм турында начар сөйләми, ләкин кайчак эчә иде дип әйтүчеләр бар. Фаҗигале көндә Нияз белән мунча ягып юынып та чыгарга өлгерә алар. Күрәсең, дүрт кешелек шау-шулы төркем өйдәге бик өлкән яшьтәге әбине ялыктыра башлый, кичке бишенчедә ризасызлык белдерә, кунакларга өйләренә кайтып китәргә куша ул. Аталы-уллы хуҗаларның әйтүенчә, шуннан соң Илфат тупаслана, кычкырырга керешә, шул рәвешле, Ниязның ачуын китерә, нәтиҗәдә, ишегалдында тәмәке тартып торганда, үзе белән алып чыккан пычакны эшкә җигә ул.

Нияз беренче күрсәтмәсендә кай җиргә һәм ничек итеп кадавын хәтерләмим дисә дә, җинаять урынына чыккач, моны ни рәвешле эшләвен күрсәтеп бирә, димәк, гаебен таный һәм үкенүен белдерә, шулай да үтерергә теләмәдем, ди. Тикшерү комитетының Чистай районара бүлегенең өлкән тикшерүчесе Рамил Исмәгыйлев аның явызлыгына аңлы рәвештә кеше үтерү дигән бәя бирә. РФ Җинаять кодексының 105 нче маддәсендә моның өчен 15 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган.

* * *

Әлмәт районындагы Түбән Мактама бистәсендә булган хәвефле хәлне көтелмәгән дип булмас. Чөнки җинаять корбаны юньсез тормыш рәвеше алып барган. Шул ук вакытта кеше һәлак иткән ир-ат эшләп яшәүче тәртипле кеше булганга, аны сәрхүшләр арасында килеп чыккан «гадәти» җинаятьләр рәтенә куярлык та түгел.

1995 елгы Антон Акимов шул районадагы Кичү авылында яши, «Мехсервис-НПО» җәмгыятендә эретеп ябыштыручы булып эшли, инде 7 елга якын хәзер 23 яшендәге Виктория белән тора һәм өч бала тәрбияли. Тәртипсез гаиләдә үскән ханымның балачагы михнәтле уза, әйтүенә караганда, 1982 елгы әнисе эчү генә түгел, наркотик матдәләр кулланучы буларак та исәптә тора, хәзер күбрәк эчкечелек белән мавыга, күрәсең, башкасына акча таба алмый, ВИЧ һәм гепатит чирләре дә бар. Аяныч ки, шушы ана белән аның 5 нче сыйныфта укучы улы яши. Рәсим (исеме үзгәртелә) зарланырга яратмый: «Хәзер миңа 11 яшь инде, үземне үзем карыйм, әнинең эчкече икәнен мәктәптә әйткәнем юк», – ди.

Малайның әйтүенчә, соңгы вакытта әнисе тагын да артыграк эчә. Моны өйләрендә Олег атлы ир-ат пәйда булуга сылтый ул. Былтыр март аенда Татьяна үзе кебекләр рәтендәге О. Зәйнетуллинны йортка кертә. Бусы – кеше үтергән өчен 9 ел ярым утырып, яңа иреккә чыккан бәндә. Күршеләр дә элекке ире белән тынычрак яшиләр иде, хәзер шаулашалар, сугышалар, сәрхүшләр җыялар, диләр. Шактый ерактагы төбәктә яшәсә дә, Виктория өйдәге вәзгыятьне күзәтеп торырга тырыша, энесе язмышы өчен борчыла.

15 октябрьдә дә ике бүлмәле фатирда хәмерне күпләп чөмерәләр. Бер арада өлкән яшьтәге күршеләре Альбина белән сыйланалар, анысы махмырдан интегүче иренә дип шешә төбендә калган аракыны алып чыгып киткәч, О.Зәйнәтуллин тагын кибеткә барып кайта. Кичкә таба Рыба кушаматлы дуслары Дмитрий килеп керә һәм бик озаклап кунак була. Шул арада Рәсимгә апасы шалтырата, малай өйдәге мәҗлесне яшереп, йоклыйбыз дигән булса да, Виктория шау-шуны ишетеп, телефонны әнисенә бирергә куша, аның белән әрләшкәннән соң, полициягә хәбәр итә. Участок инспекторы килеп кергәч, исерек кунак табан ялтырата, өйдәгеләрдән аңлатмалар алгач, погонлылар китеп бара, алар артыннан ук Кичүдән такси яллап, Виктория белән Антон килеп җитә.

Ул чакта О.Зәйнәтуллин ишегалдында була, А.Акимов та шунда кала, димәк, өйгә Виктория үзе генә керә. Тиздән әлеге очрашу аналы-кызлыларның әрләшү-талашуы гына түгел, күрәшүенә дә китерә, чөнки Виктория энесен алып китәргә уйлап, аңа әйберләрен җыярга куша, «мәрхәмәтле» ана каршылык күрсәтә. Бераздан килеп кергән Антон якалашучыларны аерырга, малайны алып чыгарга ярдәм итә, улын өйдә калырга үгетли-үгетли, Татьяна да аларга ияртә, ләкин файдасы тими.

Кире подъездга таба килгәндә, читтәрәк яткан сөйгәнен күреп ала ул. Үзе генә торгызa алмагач, күршеләрен чакырып чыгара, бергәләп, чынлыкта, аңсыз хәлдәге ир-атны фатирга кертеп идәнгә салалар. Шул арада, күрәсең, артыгын кыланып ташлавын аңлаган Антон кияү, шалтыратып, ашыгыч ярдәм чакырырга кушып карый, әмма аны тыңламый кайнана, әйтүенчә, гырлап яткан Олег айнып, аңына килер дип уйлый, ә икенче көнне иртә белән аның суынган икәнен белеп, күршеләренә керә.

Эксперт 38 яшьлек ир кешенең баш җәрәхәтләре, ин беренче чиратта, мигә кан саву нәтиҗәсендә үлүен белдерә. Моның А.Акимов эше икәнен бәхәссез була, Татьяна да башка кеше булмады ди, Антон үзе дә «явка с повинной» дигән тәүбәле беркетмә төзи.

Тикшерү Комитетының Әлмәт бүлегеннән Э.Солтанов А.Акимовка, аңлы рәвештә сәламәтлеккә авыр зыян салып, саксызлык белән үтерү дигән рәсми гаепләү белдерә. Ул гаебен өлешчә генә таный, үтерермен дип уйлап та карамадым дип, үз гамәлләрен саксызлык белән үтерү хакындагы 109 нче матдә кысаларына элегә дип саный. Әгәр Әлмәт шәһәр суды аны яклау ягының бу фикере белән килешсә, 3- 6 яшьләрендә өч бала атасы җинел җәза белән котылачак. Ләкин хөкем практикасында бик сирәк була торган хәл бу.

Наил ВАХИТОВ.

Мәдәни җомга
3 март
№8, 2023

Заманча сәнгатькә мөкиббән



Казан каласында туып үскән, Н.И.Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлаган рәссам ул – Аделина АКБИРОВА. Алты ел эчендә картиналар сату белән шөгыльләнә торган иҗат студиясен һәм «Акбирова-Арт» дип исемләнгән онлайн-мәктәбен дә ачырга җитешкән җитәкче дә әле.

Аделина Акбирова Казанның 4 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбен тәмамлап, училищеның дизайн бүлегендә белем ала. «Бер көн дус кызым мине Эрик Гайфетдинов белән таныштырды. Ә аның инде үз студиясе бар иде һәм ул мин ясаган поп-арт ысулындагы портретларны сатарга кереште. Бераздан бергәләп интерьер бизәү белән шөгыльләнә башладык. Эрик Илдар улының, күп идеяләрне тормышка ашыручы шәхес буларак, миңа булышлыгы чиксез! Ярты елдан соң без бер кызның мөрәҗәгатен кабул итеп, аның туган көне уңаеннан тәүге осталык дәресен үткәрдек. Аннары икенчесен... шулай осталык дәресләребез башланып китте. Аларны ошатучылар күбәйгәннән күбәйде. Эрик белән үз рәсем ясау мәктәбебезне булдырдык. Берничә елдан Мәскәүдә дә мәктәпнең филиалын ачуыбызны үтенделәр. Тик пандемия башланыр алдыннан башкаладагы филиал ябылды, әмма Казандагы «АртЛаб» мәктәбебез эшен дәвам итте! Соңрак без инде белемнәребезне франшиза аша тарата башладык, шулай итеп, ни шатлык, БДБ илләрендә һәм чит илләрдә безнең иллегә якын партнерыбыз барлыкка килде, – дип искә алды яшь иҗатчы. – 2018 елда онлайн мәктәп оештырдык. бик күп курслар яздырылды, бу хезмәт хәзер дә дәвам итә.

Укытучы буларак мин бик таләпчән, һәрвакыт җитди, укучыларымның хаталарын да төгәл итеп турыдан әйтәм. Чөнки кыска гына вакыт эчендә аларга файда китерерлек һөнәри киңәшләремне бирергә тиешмен, бу – минем өчен зур җаваплылык», – ди әңгәмәдәшем.

А.Акбирова Э.Гайфетдинов белән берлектә абстракт импрессионизм юнәлешендәге картиналар сату белән бәйле проект та ачып җибәргән.

«Укытуга килгәндә, бер максатым – үз шөгыльләрен тапкан хатын-кызлар санын арттыру. Укучыларыбызның кайберләре миңа: «Биредә рәсем ясап, күңел төшенкелегеннән дә арына алдык!» – ди. Кайберләре: «Рәсем ясаган вакытта кандагы шикәр микъдары түбәнәйгән!» – дип тә сөенә. Аларга кушылып, үзем дә куанам».

«Ә сез ни өчен заманча сәнгать алымнарын гына өйрәтергә булдыгыз соң?» – дим сәләт иясенә (Сүз уңаеннан, рәссамның берничә йөздән артык үз интерьер картиналары да Россия һәм чит дәүләт коллекционерларының шәхси тупланмаларында саклана). «Мин заманча сәнгать әсәрләрен генә өстен күрәм. Мәсәлән, Флюид Арт – төсләрнең киндер буйлап агып, бер-берсе белән кушылып, кабатланмас бизәкләр тудыруыннан гыйбарәт аерым бер абстракция төре. Резин-Арт – ул эпоксид сумала техникасындагы эшләнмәләр. Сумала эш ахырында бик нык, шома һәм ялтыравык өслек хасил итә, аның ярдәмендә үзенчәлекле таш кисемен, диңгез сюжетларын да иҗат итеп була. Алкогольле каралар белән ясау техникасы да бар, мондый картиналар күп катлы, нәфис килеп чыга... Шуңа күрә укытуым да рельефлы картиналарны, сыек акрил белән иҗат ителгән, спиртлы каралар белән ясалган, эпоксид сумалалы, алтынлау ысулындагы, текстуралы паста кулланып ясалган картиналарны ничек итеп иҗат итүгә төшендерүдән гыйбарәт...

Заманча техникалардагы әсәрләр теләсә кайсы мохитне дә җанландырып җибәрә. «Гомумән алганда, мин – күчермә ясарга түгел, ә техника нигезләренә өйрәтүче, – дип аңлата Аделина. – Укучыларыма: «Төсләр аша – үз күңел халәтегезне, ә детальләр аша – эчке дөньягызны ачыгыз! Буяулар – алар сүзләр кебек... Палитра аша уйларыгызның тирәнлеген күрсәтеп, сез күбрәк тә әйтә аласыз әле!», – дим.

Әлбәттә, рәссамлыкта иҗат кризисы да булмый калмый, мин дә бервакыт гел портретлар ясадым, нәтиҗәдә, алардан тәмам туеп, сәнгатьнең башка, заманча юнәлешләрен сайладым. Тәҗрибәләр уздыру рәсем ясау техникаларының күбрәк төрен белергә, аларны үзара берләштереп иҗат итәргә булыша, шуңа күрә дә мин кылкаләм хөрлеге яклы!»

А.Акбированың рәссам булып китүендә әнисенең өлеше дә бар. Аделина моны болай дип аңлатты: «Әнием үзе дә рәсемнәр ясап үскән. Тик аңа банк хезмәткәре булырга туры килде. Ул минем аша үз хыялын тормышка ашырды. Ә мин әниемә аның хыялын тормышка ашырырлык иң яхшы бүләгемне тапшырдым да кебек инде! Чөнки бер көнне әниемә үзем төзегән «Заманча рәссам» курсымны бүләк иттем!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 3.03.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2607

16+